
МӘГАРИФ
education
mәğәrif
просвещение
№4/ 2023
ТАТАР ТЕЛЕ

Оештыручысы:
**«ТАТМЕДИА»
АКЦИОНЕРЛЫК ҖӘМГЫЯТЕ**

*Яңа 2024 ел белән!*

МӘГАРИФ education
mağərif просвещение
ТАТАР ТЕЛЕ

14 ДЕКАБРЬ, 2023 ел

№ 4

12+

УЧРЕДИТЕЛЬ: **АО «ТАТМЕДИА».**
Телефон редакции: (843) 222-06-09

Адрес издателя:
420097, г.Казань,
ул. Академическая, 2

www.magarif-uku.ru

Создано при поддержке Республиканского агентства по печати и массовым коммуникациям.

Зарегистрирован в Федеральной службе по надзору в сфере связи, информационных технологий и массовых коммуникаций 04.09.2014 г.

**Эл № ФС 77 – 59204**

Периодичность выхода –
1 раз в квартал.

Мнение редакции не всегда совпадает с мнением авторов. Редакция не располагает возможностью выступать ходатаем в официальных организациях. За достоверность рекламных объявлений ответственность несёт рекламодатель.

Почтовый адрес:
**420066, г.Казань, а/я 47**
**e-mail:** magarif@bk.ru

**Адрес:** 420066, Казан,
Декабристлар ур., 2.
«Мәгариф» журналы редакциясе,
а/т 47
**E-mail:** magarif@bk.ru
**Сайт:** magarif-uku.ru
«Мәгариф», 2023 ел

Баш мөхәррир: **Таишева С.Н.**
Чыгаручы мөхәррирләр:
**Фаизова Р. Г., Сабирҗанов Т. А.**
Әдәби редактор: **Газизова И.М.**
Корректор: **Фәйзуллина Р.Ә.**
Вёрстка: **Халитова Э.И.**

*Беренче тышлыкта:*
*«Авыл укытучысы – 2023» бәйгесе җиңүчеләре*
*Юлия КАЛИНИНА фотосы*

*11, 20, 24, 29, 34, 44, 49, 55, 60, 64, 66, 69, 72, 76 нчы битләрдә Сөмбел Таишева фотолары*

Журналда кулланылган фотосурәтләр «Мәгариф» редакциясе архивыннан алынды.

*Журнал распространяется бесплатно.*

**Таңсылу ГАБИДУЛЛИНА.**
«ДӘРЕСКӘ БАРМАСАМ, УКЫТУЧЫМ МИНЕ САГЫНАЧАК...»........3

**ФӘРЗИЯ САФИУЛЛИНА, ХАЛИДӘ ГАФУРОВА.**
Әдәби уку дәресләрендә кейс-метод куллану........8

**РҮЗӘЛ ЮСУПОВ.**
Буш бәхәсләр вакыты узды........11

**МИЛӘҮШӘ ШӘЙХУЛЛОВА.**
УКЫТУЧЫМ – ОЛЫ ЮЛ БАШЫМ... ........14

**АЛЬБИНА ФӘТХЕТДИНОВА.**
ӘДӘП-ӘХЛАККА ӨНДӘҮЧЕ ӘСӘРЛӘРНЕҢ ЙОГЫНТЫСЫ........20

**РИММА ГОБӘЕВА.**
КИЕМНӘР КИБЕТЕНДӘ........24

**ИЛСИНӘ ГАРИФУЛЛИНА.**
ТАТАР ТЕЛЕНЕҢ КИЛЕП ЧЫГЫШЫ ЯГЫННАН СҮЗЛЕК СОСТАВЫ........29

**ӘЛФИЯ ИСРАФИЛОВА.**
СЫЙФАТ ДӘРӘҖӘЛӘРЕН РӘСЕМ СӘНГАТЕ АША ӨЙРӘНҮ........34

**ФИРДӘВЕС ГЫЙБАДУЛЛИНА.**
ТЕАТР ЯКТЫЛЫККА, НУРГА ИЛТӘ........40

**ГӨЛШАТ ЗАРИПОВА.**
МОНОЛОГИК ҺӘМ ДИАЛОГИК СӨЙЛӘМ ҮСТЕРҮ БИРЕМНӘРЕ........44

**РЕЗЕДА САБИРОВА.**
СИНГАРМОНИЗМ ЗАКОНЫ........49

**РАНИЯ ГОМӘРОВА.**
ЯЛГЫЗЛЫК ҺӘМ УРТАКЛЫК ИСЕМНӘР........55

**ГӨЛНАЗ КАМАЛОВА.**
ДӘРЕСЛӘРДӘ ИННОВАЦИОН ТЕХНОЛОГИЯЛӘР КУЛЛАНУ........59

**ЛӘЙСӘН ИБРАЕВА.**
ТАТАР ТЕЛЕНДӘ ҺӨНӘР АТАМАЛАРЫ........63

**ЛӘЙСӘН БАҺАВИЕВА.**
ӘМИРХАН ЕНИКИНЕҢ «ӘЙТЕЛМӘГӘН ВАСЫЯТЬ» ХИКӘЯСЕН ӨЙРӘНҮ...65

**ВАЛЕНТИНА САЛИКИЕВА, ЛЮЦИЯ КОРБАНОВА.**
ӘНГАМ АТНАБАЕВ ӘСӘРЛӘРЕНДӘ ТУГАНЛЫК ХИСЛӘРЕ, ГАИЛӘ КЫЙММӘТЛӘРЕ........68

**ГҮЗӘЛ ЗИННӘТУЛЛИНА.**
Татар телен өйрәтүдә коммуникатив технологияләрне куллану ........71

**АЛСУ ҖИҺАНГИРОВА.**
СӘЛӘТЛЕ БАЛАЛАР БЕЛӘН ЭШ АЛЫМНАРЫ........75

1




# «ДӘРЕСКӘ БАРМАСАМ, УКЫТУЧЫМ МИНЕ САГЫНАЧАК...»

*Лениногорск шәһәренең 11 нче гимназиясендә башлангыч сыйныфларда татар теле дәресе укыткан Зөлфия Гәрәеваның районда уникаль укытучы дигән икенче «исеме» бар. Ул бүген башлангыч сыйныфларда белем алучы балаларга шахмат фигуралары ярдәмендә санарга, язарга, хәреф танырга өйрәтә. Әлегә мондый тәҗрибә Татарстанның башка мәктәпләрендә күренми. Шахмат элементлары белән укыту балаларның белем үсешендә нинди нәтиҗәләр бирә? Стандарт булмаган укыту алымын ата-аналар, хезмәттәшләре ничек кабул итә? Шушы сорауларга ачыклык кертер өчен Зөлфия Мәгъсүмовна белән очраштык.*

## ПИОНЕРВОЖАТЫЙ ИТЕП КУЙМАГАН БУЛСАЛАР...

Бишенче сыйныфта укыганда, сыйныф җитәкчесе Зөлфия Гәрәеваны пионервожатый итеп билгеләп куя. Ул, һәркөн дәресләрдән соң калып, укытучысына ярдәм итә, әйтерсең лә үзен дә укытучы итеп хис итәсе килгән. Укытучы янәшәсендә бөтерелеп, балалар белән мавыгып, аралашып, уйнап йөргәндә, аның күңеленә «укытучы булам» дигән уй-хыял бик тиз кереп оялый.

Бөгелмә педагогия училищесын тәмамлап, Мөэмин-Каратай авылында башлангыч сыйныф укытучысына ул вакытта ихтыяҗ булмаганлыктан, Зөлфия физика-математика фәннәрен укытырга алына. Ләкин республикада кечкенә авыл мәктәпләрен яба башлагач, аңа гаиләсе белән Лениногорск шәһәренә кайтырга туры килә. Аны педагогия колледжына тәрбияче итеп алалар. Шулай да мәктәптә укыту теләге беркайчан да күңеленнән китми: шәһәрнең 1 нче мәктәбендә ике ел эшләгәннән соң, үз белгечлеге буенча 11 нче гимназиядә эшли башлый һәм параллель рәвештә рус төркемендә укучы балаларга татар телен дә өйрәтә.

Җиде ел элек якташлары, Мәскәү шәһәрендә «Интеллектуаль мәдәният һәм спорт үзәге» коммерцияле булмаган автоном оешмасы директоры Эльвира Усманская инициативасы белән районда шахмат буенча ресурс үзәге оеша. Әмма фәннәрне шахмат белән «дуслаштыру», бәйләү мәсьәләсе килеп баскач, укытучылар бераз югалып кала: математика, язу дәресләре, табигать белеме һәм башка дәресләргә шахмат элементларын кертү кебек яңалыкка алар әзер булмый. Шул ук вакытта шахматны дәресләргә кертү өчен методик әсбапларның булмавы да үзен сиздерә. Мәсьәләне уңай чишү максатыннан, районда мәгариф учреждениеләрендә шахмат мәгарифен үстерү буенча Координация советы төзү турында карар кылына. Советны район мәгариф идарәсе методисты Гөлнара Гаделшина, Эльвира Усманская җитәкли. Укытучылар шахмат мәктәбендә белемнәрен чарлагач, Э. Э. Уманская Е.И. Волкованың «Мәктәптә шахмат. Укытуның беренче елы» программасы нигезендә балаларны укытуга керешә. Эзләнүчән Зөлфия Гәрәева бу укыту программасы белән генә канәгатьләнми, үзенең методик әсбабын уйлап таба.

– Үз программамны төзегәндә, мин икенче тапкыр «велосипед уйлап табарга» тырышмадым, нәтиҗә турында азрак уйладым. Миңа күбрәк эш процессы ошый, – ди Зөлфия Мәгъсүмовна.

– Балаларны шахмат мәктәбендә өйрәтү отышлырак булмас идеме соң? – дип сорау бирәм укытучыга.

– Беренчедән, шахмат тренеры ул

укытучы түгел. Гадәттә, тренерларга кискенлек хас була. Ә кечкенә балалар йомшаклык ярата. Алар белән уртак тел таба белергә кирәк бит. Шахмат мәктәбенә балаларны җыялар да, икенче елга балалар калмый. Калса бер-икесе кала, – ди Зөлфия Мәгъсүм кызы.

Укытучы аңлатканча, балаларга математика, рәсем һәм технология дәресләрендә шахмат фигурасының үзенчәлекләренә төшендерү авыр түгел: укучылар шахмат тактасын ясыйлар һәм төзиләр, аны өстәлдә дөрес урнаштырырга өйрәнәләр. Мисал өчен, математика дәресендә бер санын өйрәнгәндә, пешка фигурасын укытучы куллана. Чөнки шахматта пешка берәмлеккә тигез икән. Фил белән ат фигурасы өч берәмлеккә тигез булып чыга. Шулай итеп, өч санын өйрәнгәндә, фил һәм ат фигуралары ярдәмгә килә. Тугыз санын үткәндә, ферзь фигурасы эшкә җигелә. Шахмат фигуралары ярдәмендә балалар мәсьәләләр чишәргә, уйлау сәләтенә тиз өйрәнә, дәрес тә мавыктыргыч уза.

Физкультура дәресендә балалар скакалкада сикермиләр, ә махсус шахмат кырында «шахмат фигураларын чакыру», «шахматта мөһим саннар һәм хәрефләр», «тиз пешкалар» кебек уеннарда катнашалар. Балалар бер дәрестән берьюлы ике файда ала: беренчесе – хәрәкәт булса, икенчесе – башны эшләтү. Ә үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен, шахмат этикетын, шахмат уены барлыкка килү тарихын әдәби уку һәм әйләнә-тирә дөнья дәресләрендә үтәләр.

## РОССИЯДӘ – БЕРДӘНБЕР

– Бу тырышлыгыгыз, хезмәтегез нинди нәтиҗәләр бирде? – дип кызыксынам Зөлфия Мәгъсүмовнадан.

– Безгә, иң мөһиме, балалар күңелендә шахматка башлангыч юл салу, шахмат культурасына өйрәтү, кызыксынуны арттыру иде. Ышанычым акланды дияргә була. Дөресен әйткәндә, бу проектны курку хисе белән, өметләр акланырмы дигән шикле уйлар белән генә башлап җибәргән идек. Бүген шахмат мәктәбендә буш урыннар юк. Район администрациясе ярдәме белән башлангыч сыйныфта укучы балалар өчен шахмат мәктәбендә сәгатьләр бүленеп, бушлай уку мөмкинлеге бирелде. Дәрестән соң балалар белән тренерлар шөгыльләнә. Быел 60 процент укучым шахмат мәктәбенә йөри башлады. Мәктәп предметлары буенча укучыларның өлгерү сыйфаты 80 процентка кадәр артты. 2020 елның апрелендә гимназия командасы «Ак пешка» Бөтенроссия шахмат олимпиадасында җиңүче булды. Ике ел элек Мәскәүдә башлангыч сыйныф укучылары һәм педагоглар өчен шахмат буенча фестиваль узган иде. Россиянең төрле почмакларыннан килгән барлык командалар арасында без икенче урынны алдык. Хәзер без елына ике тапкыр Мәскәүгә Россия укытучыларына үз тәҗрибәбезне күрсәтергә барабыз. 2017 елдан башлап мәктәпләрдә, башка төбәкләрдә халыкара фәнни-гамәли конференцияләрдә катнашам, ачык дәресләр үткәрәм, мәктәп программасына шахмат дәресләрен кертү буенча үз тәҗрибәм белән уртаклашам. Быел Краснодар шәһәрендә булып кайттым. Анда ел саен иң яхшы шахмат уенчыларын, тренерларны чакыралар. Профессионаллар арасында башлангыч сыйныф укытучысы буларак берүзем катнаштым, үз тәҗрибәм турында, ничек мин

балаларга шахматка кызыксыну уятам – шулар хакында сөйләдем. Әле күптән түгел генә Чабаксарда булдым.

Укытучы ассызыклаганча, Россиянең бер генә белем оешмасында да шахмат ысулы белән балаларга белем бирелми.Татарстан мәктәпләрендә шахмат аша белем бирүгә ник омтылмыйлар икән? «Укытучылар әлегә шахматның балага йогынтысын аңлап җиткермиләр, бәлкем, шуңа да якын итмиләрдер», –дигән фикердә педагог.

«Балаларның шахматка мәхәббәте артса, белем сыйфаты яхшырса, минем тәҗрибәм, категориям үсә. Мин – иң оста шахматчы түгел, балаларга шахматка фәннәр аша юнәлеш кенә бирүче. Россиядә мондый укытучы юк дияргә була», – ди Зөлфия Мәгъсүм кызы елмаеп.

Шахмат уйный белмәгән бала белән уйный белүче арасында аерма бармы? «Шахмат уйнаган балада стратегик фикерләү, иҗади уйлау сәләте барлыкка килә. Әйтик, балага каядыр барырга кушасың һәм ул каршылыкка, берәр нинди капкага юлыга. Шахматны аңламаган бала, мин анда керә алмыйм, дип туктап кала. Ә шахматта уйнаучы бала, бу капка аша ничек үтәргә була, дип фикерли башлый һәм юлын да таба», – диде шахмат белән дус мөгаллимә.

## РУС БАЛАЛАРЫ ТАТАР ТЕЛЕН ЯРАТА...

Зөлфия Гәрәева башлангыч сыйныфларның рус төркемендәге балаларга татар телен дә укыта. Бүген татар балаларында туган теленә карата мәхәббәт тәрбияләү катлаулана барган заманда, рус балаларына татар телен өйрәтү икеләтә җиңел түгелдер? Бу сорауга, беләсезме, Зөлфия Мәгъсүм кызының җавабы нинди?

– Минем балалар –татармы, русмы – барысы да татар теле дәресен көтеп ала, ярата. Физкультура дәресен дә шул дәрәҗәдә яратмыйлардыр алар. Моның сере юк... Татар телен уеннар, җырлар ярдәмендә яраттырам. Соңгы елларда дәресләремдә «Шаян ТВ»ның шәп видеоларыннан файдаланам. Аннан соң Мещерякованың методикасы да дәресләремне кызыклы итеп үткәрергә ярдәм итә. Сөйләм телендә рус балаларының татар сүзләрен әйтергә телләре әйләнми, ә җыр аша сүзләрне акцентсыз әйтәләр. Мозаика, пазллар, фишкалар, сөт шешәләре капкачлары, туңдырма таякчыклары белән дидактик уеннар ясап, балаларны татар теле белән кызыксындырам. Дәрескә кергәч, алар миннән: «Зөлфия Мәгъсүмовна, бүген нәрсә эшлибез, нәрсә ясыйбыз?» – дип сорыйлар. Шундый сораулар белән алар минем мотивациямне күтәрәләр, тагын да тырышып эшләргә көч өстиләр.Төн йокламасаң йокламыйсың, ләкин балалар теләген ничек тә үтисең.

## ИКЕНЧЕ ӘНИ...

Әгәр дә сыйныфта парта артында өлгереш буенча башкалардан арттарак баручы яисә башка проблемасы булган берәр бала утырса һәм ул аңа ярдәм итмәсә – ул Зөлфия Гәрәева түгел инде. Ихлас кешегә хисен йөгәнләве авыр шул: балалар турында сөйләшкәндә дә, аның күзләре бер яшьләнде, бер елмайды.

Сөйләшә торгач, укытучы үзен борчыган кайбер мәсьәләләргә дә тукталды. Соңгы елларда беренче сыйныфка килүчеләр арасында сөйләм үсешләре тоткарланган, сакау телле, тиз кызып китүчән, укый

алмаучы балалар да бар. Билгеле, мондыйлар укытучы ярдәменнән тыш логопед, дефектолог, невролог ярдәменә дә мохтаҗ. Тынгысыз укытучы, психология буенча алган белемнәрен, утыз бер ел буе туплаган тәҗрибәсен эшкә җигеп, бу мәсьәләне да чишәргә алына.

«Сыйныфымда 30 бала укый. Дәрес вакытында проблемалы балалар белән индивидуаль шөгыльләнергә мөмкинлек юк. Өч ел дәвамында балаларны дәрестән соң алып калып, алар белән эшли башладым. Логопедия, психология буенча белемемне арттыру турында хыялланам. Моннан тыш, сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән ике бала белән дә шөгыльләнәм. Аларны Подлесная совхозыннан әниләре махсус алып килә. Ата-аналарның миңа ышанычы, балаларның миңа тартылуы, укытучы һөнәрен дөрес сайлавымны кат-кат раслый», – ди укытучы.

Подлесная авылында яшәүче Рамилә Мингалимовага сәламәтлек мөмкинлеге чикләнгән улын Зөлфия Гәрәева сыйныфына бирергә киңәш итәләр. Ул бер тамчы да икеләнеп тормыйча ризалаша, баласын һәркөн аның дәресләренә машина белән йөртә.

– Зөлфия Мәгъсүмовна – бик тырыш, белемгә омтылучан, һәрвакыт елмаюлы шәхес. Мин баламның ни өчен укытучыга бик тиз ияләшүен аңладым. Ул укучыларны аермый, аларның барысын да бер, дус күрә. Балалар шул сыйфатны тоеп, аңа тартылалар, дәресләренә теләп баралар. Балама карата җылы игътибары, әниләрчә кайгыртып белем бирүе мине бик бәхетле итә. Аның сыйныфында укый башлаганнан соң, улым бик нык үзгәрде. Ул баламда иң мөһим сыйфат – үз-үзенә ышаныч тәрбияләде. Җыелышларда һәрбер ата-ананы аерым тыңлый, тынгысыз ана йөрәгенә өмет сала белгән игелекле укытучы ул, – дип, укытучы турында фикерләрен җиткерде Рамилә ханым.

Һәрбер ата-анага нарасыен кайсы мәктәпкә бирүе, беренче укытучысы кем булуы мөһим. Сәламәтлек мөмкинлекләре чикле баласын Зөлфия Гәрәева сыйныфына биреп, Александра Хафизова да ялгышмаган. Улы Марсельне беренче сыйныфка биргәч, гомуми программа буенча материалны ничек үзләштерер, дип бик нык борчылган ул. Ләкин укытучының сабырлыгы, тырышлыгы һәм бала белән эшләүдә төрле ысуллар һәм алымнар таба белүе нәтиҗәсендә Марсель бүген уңышлы укый.

– Башта авыр булды, өметләр өзелгән, күңел төшкән вакытларны да уздык. Зөлфия Мәгъсүмовна: «Әйдәгез көтик, өметләник», – дип, безнең күңелгә ачкыч таба белде. Хәзер Марсель мәктәпкә ашкынып бара. «Әни, мин мәктәпкә килмәсәм, укытучым мине сагыныр бит», – ди ул. Башка балалардан аерылып торган улымда белемгә омтылыш уятты, – дип сөйли Александра, педагогка хөрмәт хисләре белән.

Сүз дә юк, укытучы нинди генә дәрәҗәләргә ирешмәсен, нинди генә мәртәбәле исемнәр алмасын, кайсы гына конкурсларда җиңү яулап зур уңышлар казанмасын, иң олы бәяне укучылар һәм ата-аналар бирә дигән фикер белән һәркем килешер. «Тумыштан укытучы булып туган, уникаль кеше» дигән олы мактауга һәр укытучы да лаек булса иде.

**Таңсылу ГАБИДУЛЛИНА**
*Фото Зөлфия Гәрәева архивыннан*



2

# ӘДӘБИ УКУ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ КЕЙС-МЕТОД КУЛЛАНУ

*(Г. Тукайның «Умарта корты һәм чебеннәр» мәсәлен өйрәнү мисалында)*

**Фәрзия САФИУЛЛИНА,**

Казандагы 183 нче гимназиянең
югары квалификация категорияле
башлангыч сыйныфлар укытучысы

**Халидә ГАФУРОВА,**

Казандагы 183 нче гимназиянең югары
квалификация категорияле башлангыч
сыйныфлар укытучысы

Соңгы вакытта дәресләрдә традицион булмаган төрле метод һәм технологияләр куллану шактый активлашты. Башка фәннәрне укыту белән беррәттән, әдәби уку дәресләренә дә әлеге яңалык үтеп керде. Бүгенге көн укытучылары яңа педагогик технологияләргә өстенлек бирә. Шундыйларның берсе – әдәби уку дәресләрендә еш кулланырга мөмкин булган кейс-метод. Кейс технологиянең төп бурычы – укучыны билгеле бер ситуациягә карата үз фикерен белдерергә, проблеманы аерып чыгарырга өйрәтү, билгеле бер күренешне мөстәкыйль рәвештә дөрес итеп анализлау күнекмәләрен формалаштыру. Әлеге метод нинди дә булса әдәби әсәрне өйрәнү, уку барышында эзлекле рәвештә кейс-биремнәр үти баруны күз уңында тота. Мисал өчен, әсәрне укый башлар алдыннан да, әсәрнең күпмедер өлешен укыгач та, ахырдан да төрле формадагы биремнәр үтәргә була. Әлеге методның төп аермалы ягы шунда: проблемалы ситуация чынбарлыктан алынган фактлар нигезендә формалаштырыла. Шул ук вакытта күтәрелгән проблема бүгенге көндә актуаль булырга һәм берничә төрле чишелеш алырга тиеш. Кейс-метод төркемнәрдә эшләүгә юнәлтелгән.

Кейс-метод куллануны 3 нче сыйныфның татар төркемнәрендә өйрәнелә торган Г. Тукайның «Умарта корты һәм чебеннәр» мәсәле мисалында карап узарбыз.

Иң элек сыйныфны өч төркемгә бүләбез. Төркемнәрдәге укучыларның белем дәрәҗәләре бертөрле булуы шарт. Алдан ук берничә конверт, шул конверт саны буенча һәр төркемгә биремнәр әзерләп куюу кирәк.

Әсәрне укый башлаганчы ук, һәр төркемгә дә беренче номерлы конвертлар бирелә. Конвертка өч төркемгә дә берәр төрле мәкаль салынган була:

1. Алтын булса да торган җир, сагындыра туган җир.
2. Ватаны юк – җыры юк сандугач.
3. Илдә булса үлмәссең, илсез көн күрмәссең.

Бирем шундый: төркемнәрдә фикер алышып, мәкальнең мәгънәсен аңлатып карагыз. Биремне үтәү өчен, ягъни фикер алышу өчен берничә минут вакыт бирелә. Җаваплар әзер булганнан соң, төркемнән бер кеше чыгыш ясый. Әлеге мәкальләр барысы да туган илнең, туган якның, Ватанның бер генә булуы, кеше өчен аның бик зур роль уйнавы турында. Төркемнәрнең һәркайсында да шушы юнәлештә нәтиҗә ясалырга тиеш.

Алга таба укытучы мәсәлнең исеменә игътибар юнәлтә һәм сыйныфка шундый сорау белән мөрәҗәгать итә ала: «Үзегезнең белгәннәрегездән чыгып, чебен һәм бал корты дип аталучы бөҗәкләрне төрле яклап тасвирларга омтылып карагыз. Төркемнәрдә фикер алышыгыз һәм үз фикерләрегезне чагыштырыгыз». Җаваплар тыңлангannан соң, түбәндәге нәтиҗәне чыгару зарур: «Чебен һәм умарта корты – бер-берсенә капма-каршы бөҗәк. Чебеннәр пычрак урыннарда яши, кешегә файда китерми, кешеләр алардан котылу ягын карый. Ә бал корты – бик тырыш, уңган. Ул кеше организмы

өчен бик файдалы булган бал җитештерә. Кешеләр аларны ярата, махсус ояларда тота».

Сыйныф мәсәл белән таныша башлый һәм әсәрнең уртасына җиткәч (Умарта кортының җавабы алдыннан), укытучы укучыларга икенче номерлы конвертны тәкъдим итә. Аның эченә төркемнәр өчен түбәндәге өч бирем салынган:

1. Ничек уйлыйсыз, Умарта корты чит илгә китәрме? Ни өчен?

2. Ничек уйлыйсыз, Умарта корты чебеннәргә ни дип җавап бирер икән?

3. Алга таба чебеннәр, үз акылларына килеп, туган җирләрендә калырлармы, холыкларын үзгәртерләрме?

Төркем эчендә укучылар берничә минут дәвамында фикер алыша һәм җаваплары белән бүлешә. Бер төркем укучылары үз җаваплары белән таныштырганда, башкаларның әлеге бәхәскә кушылып, үз фикерен белдерүе кейс-методның зур уңышы булып санала. Җаваплар тыңланганнан соң, нәтиҗәләр ясалмый, әсәрне уку алга таба дәвам итә һәм укучылар Умарта кортының чебеннәргә биргән җавабы белән таныша. Шушы этаптан соң, икенче номерлы конверттагы биремнәргә кире кайтып, төркемнәрдән алынган җаваплар анализлана. Ягъни укучыларның фаразлары белән әсәрнең укылган өлешендәге вакыйгалар чагыштырыла, нәтиҗәләр ясала.

Әсәрне уку шуның белән тәмамлана, укучыларга өченче номерлы конвертлар бирелә:

1. Сезнең алдыгызга шундый сайлау куйдылар: чит илгә күченеп китәсезме яки үзегезнең туган ягыгызда каласызмы? Җавапларыгызны нигезләгез.

2. Ничек уйлыйсыз, ни өчен Умарта корты чебеннәргә шундый җавап кайтарган? Сез үзегез чебеннәргә нәрсә дип җавап бирер идегез?

3. Үзләренең туган илләреннән китеп, читтә рәхәт күрми яшәгән кешеләрне беләсезме? Алар турында нәрсә әйтә аласыз?

Әлеге сорауларга җавап эзләү, төркем эчендә фикер алышу өчен укучыларга берничә минут вакыт бирелә. Шуннан соң җаваплар тыңлана, тулы әсәр буенча нәтиҗәләр чыгарыла.

Шулай итеп, Г. Тукайның «Умарта корты һәм чебеннәр» мәсәлен кейс-метод нигезендә өйрәнеп, анализлауны карап уздык. Тулы сыйныфның белем дәрәҗәсеннән чыгып, әсәр буенча биремнәрне үз эченә алган тагын берничә конверт тәкъдим итәргә мөмкин. Аларның һәркайсы укучының яшь үзенчәлегенә туры килергә тиеш. Югарыда китерелгән мисаллардан күренгәнчә, кейс-биремнәр, үзенчәлекле күнегү төре буларак, укучыда зур кызыксыну уята һәм әсәрне адымлап, эзлекле рәвештә анализлауны тәэмин итә. Конверт эченә салынган кейс-ситуацияләрнең чишелешен эзләгәндә, бүгенге көн укучысы өчен мөһим булган кыйммәтләр системасы алгы планга чыга, укучы шәхесенең тормышка карашлары камилләштерелә һәм практик күнекмәләр формалаштырыла. Ягъни бала үз фикерен нигезләргә, дәлилләргә һәм үз карашларын аңлата белергә өйрәнә, төркемдә эшләү күнекмәләре үсә. Әлеге методның тагын бер үзенчәлекле ягы шунда: ул укучыга бер проблеманың берничә төрле чишелеше була алуын күрсәтә, алган белемнәрен чынбарлыкта кулланырга ярдәм итә.

3



# БУШ БӘХӘСЛӘР ВАКЫТЫ УЗДЫ

**Рүзәл ЮСУПОВ,**

академик,
филология фәннәре докторы

Матбугатта хәбәр ителгәнчә, күптән түгел Дәүләт Советында Марат Әхмәтов җитәкчелегендәге Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы татар телен һәм башка халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе утырышында милли мәгариф хәлләре турында сөйләшү булган. Шунда әйтелгән кайбер фикерләргә үземнең карашымны абруйлы журналның могтәбәр укучылары белән уртаклашып алырга булдым.

Беренчедән, Дәүләт Советында милли мәгариф турында сөйләшү – бик кирәкле, күркәм күренеш. Бер теләк: андый әңгәмәләрдә берничә генә булса да татар теле, әдәбияты укытучыларын һәм галимнәрен катнаштыру мәгъкуль булыр иде.

Бу утырышта мәктәпләрдә татарча укыту, татар теле, әдәбияты укытучылары әзерләү мәсьәләләре турында әңгәмә кору табигый: хәзерге дәвердә татар телен өйрәтү-укытудагы, аны белү-кулланудагы проблемалар буа буарлык. Алар инде бу комиссия утырышларында гына хәл итеп бетерерлек тә түгел. Шулай да монысының аз гына булса да файдасы тими калмас, дип фараз кылыйк.

Республикабызның мәгариф һәм фән министры Илсур Һадиуллин бу утырышта милли мәгариф өлкәсендәге проблемаларны хәл итүнең берьюлы ике һәм аннан да күбрәк телдә укыта алырлык укытучылар әзерләү дип дөрес әйткән. Тик «аннан да күбрәк телдә укыта алырлык укытучылар әзерләү» дип, арттырыбрак җибәргәндер, бәлки. Ә ике телдә укыта алырлык педагоглар әзерләү – чыннан да булырлык һәм кирәкле гамәл. Илсур әфәнде укытучылар әзерләү проблемаларын яхшы белеп сөйләгән, чөнки ул – Казан педагогия университетында белем алган кеше. Бу уку йортында исә барлык предмет (фән) укытучыларын да диярлек татар һәм рус телләрендә укыта алырлык итеп әзерлиләр иде. Хәзерге хакимият әһелләре сабак алырлык хәл: республика җитәкчеләре заман таләпләренә җавап бирерлек, республика өчен бик кирәкле ике телдә эш итә торган, Россия вузлары арасында иң алдынгылардан саналган Казан педагогия университетын ныклап уйлап тормыйча бетереп ташлап, зур хата ясадылар. Моның ялгыш булганлыгы ачыкланды инде. Хәзер хатаны төзәтергә – бу уку йортын торгызырга кирәк. Моны никадәр тизрәк эшләсәң, шулкадәр яхшырак булачак: республиканың үзенең абруйлы югары педагогия уку йорты булырга тиеш.

Утырышта күптән бара торган бәхәс кузгатылган: туган телне кем өйрәтергә тиеш: гаиләме яки мәктәпме? Бу мәсьәләдә бердәм фикергә киленмәгән. «*Туган телне сакларга ниндидер закон проектлары ярдәм итәчәгенә ышану – ахмаклык. Дәреслекләр алуга зур сумма тотылса да, мәктәпләрдә туган телләр укытылса да... Бала үз гаиләсендә туган телен ишетми икән, бу тырышлык бушка булачак»,* – дигән комиссия члены – урта педагогик уку йорты җитәкчесе. Шундый җитәкченең, тупас итеп ахмаклык сүзен урынсыз кулланып сөйләве ямьсез күренеш булса, закон проектлары да (ни өчен проектлары гына, законнарның үзләре түгел? – *Р.Ю.*),бала үз гаиләсендә туган телен ишетми икән, мәктәптә туган тел укыту да, баланың туган телен өйрәнүе дә бушка булачак дип әйтүе – зур ялгыш. Гаиләдә бер сүзен дә өйрәнмәгән һәм белмәгәннәр чит телләрне уку йортларында ничек итеп камил дәрәҗәдә өйрәнеп чыгалар икән соң?

Комиссиянең икенче бер әгъзасының: *«Тел проблемасын гаилә дә хәл итә алмый»*,– дип, балаларга туган телне өйрәтүдә кистереп әйтеп, гаиләнең ролен инкяр итүе – шулай ук хата караш.

Балага туган телен кем өйрәтергә тиеш: гаиләме яки мәктәпме, дигән сорау кую, гомумән, дөрес түгел. Бу эш белән аларның икесе дә нәтиҗәле итеп, җиренә җиткереп шөгыльләнгәндә, туган телләрен камил белгән балалар һәм яшьләрне уңышлы рәвештә милли традицияләрдә тәрбияләп

үстереп була.

Балага сабый чагыннан ук туган телен өйрәтү – ата-ананың, бигрәк тә ананың изге бурычы. Нарасый беренче чиратта телне анасыннан өйрәнә. Беренче сүзләрне ул күкрәк сөте имгәндә үк ишетә башлый, шуңа күрә татарлар туган телне, кадерләп, ана теле дип атаганнар, балага туган тел ана сөте белән керә дип әйтәләр. Ата-анасы, әби-бабасы дөрес тәрбия бирә белгән гаиләдә балалар туган телләрендә дөрес, матур итеп сөйләргә-сөйләшергә өйрәнеп җитәләр, аның сөйләмә формасын, ягъни туган телнең ныклы нигезен, үзләштереп өлгерәләр.

Әмма төрле объектив һәм субъектив сәбәпләр аркасында, һәр ата-ананың да, ягъни гаиләнең, балаларына туган телне камил итеп, аның әдәби формасында өйрәтү мөмкинлекләре булмый.

Туган телне, аның әдәби формасын камил итеп өйрәтүнең гасырлар буена сыналып килгән, ышанычлы урыны ул – мәктәп. Балалар туган телләреннән гаиләдә алган белемнәрен мәктәптә махсус белгечләр – укытучылар, дәреслекләр, уку әсбаплары, техник җиһазлар ярдәмендә ныгыталар, киңәйтәләр, баеталар, туган телнең фәнгә нигезләнгән әдәби нормаларын үзләштерәләр.

Хәзерге цивилизация заманы кешеләренә хезмәт итә торган әдәби тел ул – халык күп гасырлар буена барлыкка китергән сәнгатьле (матур) әдәбият һәм фән-техника теле, нык үскән, катлаулы, камил тел. Шуңа күрә балалар аны бөтен үзенчәлекләре белән гаиләдә генә үзләштереп бетерә алмый (ата-анасы югары белемле, тәҗрибәле педагог булган сирәк очракларны исәпкә алмаганда). Шуның өчен дә цивилизацияле дөнья мәктәп дигән бик әһәмиятле оешма-учреждение уйлап чыгарган.

Димәк, балаларны дөрес, матур, камил итеп туган телләренә өйрәтү өчен, гаилә дә, мәктәп тә кирәк. Бала ана телен гаиләдән өйрәнеп килсә, ул аны мәктәптә югары дәрәҗәдә, яхшырак итеп, тизрәк, җиңелрәк үзләштерә. Бу – дәлилләп, шәрехләп торуны да таләп итми торган хакыйкать, аксиома.

Балага тел өйрәтү гаилә эшеме, мәктәп бурычымы, дип сүз көрәштерүчеләрне «ялкауга ял» принцибы белән эш итеп яшәүчеләр дип әйтергә була. Баласына намус белән ана телен өйрәтүдән котылырга теләгән ата-ана үз вазифасын мәктәпкә генә йөкләргә омтыла, үзләренең эшләрен, җиренә җиткереп, сыйфатлы итеп башкарырга күнекмәгән укытучы-педагоглар балаларга тиешле дәрәҗәдә белем бирә алмаулары өчен ата-аналарны гаепле итеп калдырырга тырышалар.

Әйтелгәннәргә нәтиҗә ясап, туган телләрен начар белгән яки бөтенләй белмәгән балалар өчен гаеп атта да, тәртәдә дә, ягъни ата-анада да, мәктәптә дә була дияргә мөмкин. Ләкин бу изге эшнең нәтиҗәлелеге өчен төп җаваплылык рәсми мәгариф учреждениесе – уку йортына төшә.

Югарыда әйтеп үткәнчә, хәзер милли мәгариф системасында, балаларга туган телләрен өйрәтү-укытуда проблемалар, хәл итәсе бурычлар күп. Татар мәктәпләренең бүгенге эше заман таләпләренә җавап бирерлек итеп оештырылмаса, рус мәктәпләрендә татар теле укыту хәзергечә эленке-салынкы дәвам итсә, безнең туган телебезнең тормыштагы роле, әһәмияте, сыйфаты көннән-көн түбәнәеп, әдәбиятыбызның, мәдәниятебезнең дә нигезе какшаячак, җимерелүгә таба барачак.

Бәхәссез: хөкүмәттән, парламенттан, ягъни республика җитәкчелегеннән, татар телен саклау, өйрәтү, куллану мәсьәләләрен, бу өлкәдә булган проблемаларны ныклап тикшереп, махсус программа буенча җитди һәм нәтиҗәле шөгыльләнү таләп ителә. Чаң сугар чак күптән җитте. Мәсьәләгә җиңел карау, буш бәхәсләр вакыты узды. Бераздан соң булырга мөмкин.



# УКЫТУЧЫМ – ОЛЫ ЮЛ БАШЫМ...

**Миләүшә ШӘЙХУЛЛОВА,**

Азнакай районы Җиңү бистәсе урта мәктәбенең югары квалификация категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы

*Марсель Галиевнең «Артта – зәңгәр күләгәле эзләр»* әсәренә нигезләнеп, төбәк язучылары, шагыйрьләре иҗатын һ.б.ны кулланып төзелгән дәрестән тыш чара эшкәртмәсе. Эшкәртмә югары сыйныф укучылары белән дәрестән тыш эшчәнлекне күз алдында тотып төзелде.*

**Максат:** укучыларга Азнакай төбәге әдипләренең иҗатында укытучы образы турында мәгълүмат бирү; укытучыларга карата хөрмәт, олылау хисләре булдыру, остазларның кеше тормышында мөһим урын алып торуларын, һәркем өчен кемнең дә булса үрнәк булуын төшендерү; укытучы һөнәренә карата кызыксыну уяту.

**Җиһазлау:** экран, проектор, такта, карта (проектор ярдәмендә экранга чыгарырга да була), парталар, ватман, фотоаппарат, ансамбль өчен уен кораллары, кашыклар һ.б.

**Формасы:** театральләштерелгән тамаша.

**Катнашалар** *(бер кеше берничә рольдә уйнарга да мөмкин)*:

**Алып баручы** (сәхнәдә күренми)**.**
**Айдаров** – роно мөдире.
**Туктаров –** мәктәп директоры.
**Нурия –** укытучы.
***Фәйрүзә апа*** – яшь вакытта (Фәйрүзә апа) һәм картайгач (К.У.).
**Өлкән укытучы.**
**Гөлназ** – яшь укытучы (Я.У.).
**Ринат абый** – элекке мәктәп директоры, география укытучысы.
**Газинур** – укучы.
**Галиев** – укучы.
**Хәсән ага** – математика укытучысы.
**Укучылар.**

*Сәхнәнең арткы планында берничә парта, такта куелган. Сәхнә ачылганда, Т. Миңнуллинның «Үзебез сайлаган язмыш» әсәре буенча сәхнәләштерелгән күренеш бара. Сәхнә алдында укытучылар сөйләшеп торалар.*

**Айдаров.** Иптәшләр! Бүгенге көн таләпләре буенча, укытучы булу – гаять җаваплы эш. Бурычларыбызны да беләсез. Без югары өлгерешкә ирешергә тиеш. Безнең бурыч, иптәшләр, мәктәпне тәмамлаган һәр укучының югары уку йортына керүе түгел. Безгә производствода эшләр өчен дә белемле кешеләр кирәк. Әгәр сез укыткан балаларның барысы да югары уку йортына керсә, кем сыер савар, кем җир сөрер, кем машина йөртер?

**Туктаров.** Әгәр без укыткан укучыларның барысы да сыер сауса, җир сөрсә, машина йөртсә, кем космоска очар, кем атомны йөгәнләр, кем балаларны укытыр?

**Нурия.** Камайларны, Сәгъдиләрне кем әзерләр?

**Туктаров.** Безнең заманга зыялы, белемле кешеләр кирәк. Аларны белемле итү – безнең бурыч.

**«Уйларымда мәктәп еллары» җыры** *(Виталий Агапов көе һәм сүзләре).*

(*Сәхнәнең 2 ягыннан егет белән кыз җырлый-җырлый чыгалар. Бер малай белән бер кыз җыр барышында бию хәрәкәтләре ясыйлар. Җыр салмак музыка белән алышына. Экранда укытучыларның укучылар белән төшкән сюжетлы фотолары күрсәтелә.)*

**Алып баручы** (А. Б.) *(сәхнә артыннан)*. Кулыннан тотып, шәкертен ул шигъри матурлык иленә алып керде.

– Төнлә атылган йолдызны

аны һәркем күрә ала, ә менә син көндезге күктән өзелгән йолдыз тавышын ишетергә өйрән, – дияргә ярата иде ул. Ә беркөнне...

– Хәзер инде минем сиңа кирәгем калмады. Синең үз кыйблаң, – дип, шәкертенә фатиха бирде.

*(Салмак музыка уйный. Экранда табигать күренеше. Мәктәпкә илтә торган сукмак. Сәхнәгә өлкән яшьтәге укытучы керә. Музыка акрыная бара. Укытучы шигырь укый.)*

**Роза Солтанова. «Укытучы – өйрәтүче зат ул».**

Сабыр гына сукмак буйлап киләм
Мәктәпкә, дип, дөнья күзәтеп…
Хата китмәгәнме, без җаваплы,
Ялгышларны булмый төзәтеп.

Бала күңеле нечкә кыл чыбыктай
Тетрәнәдер искән җилгә дә.
Кыл чыбыкны дөрес чыныктыру,
Беләм, фәкать безнең җилкәдә.

*(Экрандагы табигать күренеше дәрес вакытында төшкән фотолар, аннан чыгарылыш фотолары белән алышына.)*

Укытучы – өйрәтүче зат ул,
Тормышка да, укый белергә.
Саубуллашкач туган мәктәп белән,
Зур тормышка атлап керергә!

Адашмасмы син укыткан бала,
Ялгышмасмы тормыш корганда?
Сау-сәламәт бала салынырмы
Ак чәчәкле балкыш юрганга?

Алган белем, әдәп, итагатьлек
Булырмы соң алар юлдашы?
Гаилә корган егет-кызга бүген
Ана күрсәткәнме юл башы?
Апа күрсәткәнме юл башы?

*(Өстәлдә яткан чыгарылыш альбомын кулына ала.)* Бу чыгарылышым да быел зур тормыш юлына аяк баса. Алар инде – дипломлы белгечләр. Юлларыгыз уңышлы булсын, балалар. Хәерле сәгатьтә!

*Сәхнәгә яшь укытучы кыз керә.*

**Яшь укытучы (Я.У.).** Мин кабат яраткан мәктәбемдә, хөрмәт иткән укытучыларым янында. Бу юлы инде укытучы буларак. Укытучыга илаһи итеп карау, ... аңа соклану, табыну, аны ярату һәм хөрмәт итү кебек үтә бер нечкә хис безгә, авыл балаларына гына хас булдымы икән? Көннән-көн үзгә бер яңалык арттыра барган күңел офыгының капусларын ачып, үзләренә карата олы тойгылар уяткан укытучыларны онытырлыкмыни?! Без аларга якын итеп, яратып, «апа», «абый» дип дәшә идек. Укытучы һөнәрен сайлавыма да, әлбәттә, алар сәбәпче. Бүген дә аларны күрергә, яңа уку елы башланыр алдыннан фатихаларын алырга дип иртәрәк килдем. *(Исәлекләргә бирелгән укытучыны күрә, аңа мөрәҗәгать итә. Җылы итеп күрешәләр.)* Хәерле көн, апа!.. Сезне нәкъ менә шунда табасыма шикләнмәдем. Шатлыгымны Сезнең белән дә уртаклашасым килде. Барлык укытучыларыма да рәхмәтлемен, ләкин укытучы һөнәрен сайлавымның төп сәбәпчесе – Сез.

**Өлкән укытучы (Ө.У.).** Рәхмәт җылы сүзләреңә, Гөлназ. Котлыйм сине, яшь коллега. Үзем дә сезнең чыгарылышны уйлап тора идем әле.

**Я.У.** Апа, Сездән гел сорыйсым килеп йөрде. Укытучы һөнәрен сайлавыгызга нәрсә сәбәпче булды?

**Ө.У.** И-и Гөлназ, мине дә бу һөнәргә укытучыларыма булган хөрмәт, аларга соклану китерде. Мин саргылт-көрән төстәге таш

стеналы, кызыл түбәле мәктәбемне бик еш күз алдына китерәм. Күпме вакытлар үтсә дә, аның коридорыннан һаман шулай безне укыткан укытучылар йөридер кебек… Зур зәңгәр тәрәзәле мәктәп… Куе бакча… чирәмле ишегалды. Авыл уртасында үзенә бер оазис, серле дөнья иде инде ул безнең өчен… Менә шул дөнья уртасыннан, кулын артка куеп, мәктәп директоры Ринат абый килә. Без аны «директор абый» дип йөртә идек. Гадәттән тыш усал тоела иде ул безгә. Ләкин… кирәк вакытта шаян да була белә иде. Ә озын тәнәфестә оештырылган биюләр вакытында Ринат абыйның директор икәне бөтенләй онытылып тора.

*Дәрескә кыңгырау чылтырый. Укучылар парталар артына утырышалар. Өлкән укытучы белән яшь укытучы әкрен генә сәхнәдән чыгып китәләр. Сәхнәгә мәктәп директоры Ринат абый керә.*

**Ринат абый.** Хәерле иртә, укучылар! Дәресне башлаганчы, дәрескә килмәүчеләрне барлап алыйк әле. Газинур да килгән икән. 2 көн нишләп мәктәптә булмадың, Газинур?

**Газинур.** Сыер суйдык, директор абый.

**Ринат абый** *(тыныч тавыш белән)*. Ите күп чыктымы?

**Газинур.** Бер түшкә инде, директор абый.

**Ринат абый.** Мае күп чыктымы?

**Газинур.** Бер табак инде, директор абый.

*(Газинур беркатлыланып җавап бирә, сыйныф тыела алмыйча көлә башлый.)*

**Ринат абый.** Өйгә бирелгән эшне тикшереп алабыз. Мәрмәр диңгезенә көньяктан нинди бугаз аша кереп була? Карта янына Галиевне чакырабыз? *( Ул картадан Мәрмәр диңгезен эзли, ләкин таба алмый. )*

**Галиев** *(залга карап сөйли)*. Директор абый күрсәткән иде бит узган дәрестә ул Мәрмәр диңгезен. «5»ле алгач, киләсе дәрестә барыбер сорамый дип, астан гына рәсем ясап утырган идем шул. Колагыма керде югыйсә, мәрмәр дигән сүз, диңгезгә таш исеме кушалармыни инде, дип аптырап та калган идем, күтәрелеп карарга исә баш җитмәгән. *(Сыйныфтан ярдәм көтә. Кемдер кулы белән Мәрмәр диңгезенең кайда икәнен аңлатырга тырыша. Ул, Мәрмәр диңгезен эзләп, Кызыл диңгезгә кереп чума.)*

**Ринат абый** *(бармагы белән картадан күрсәтә)*. Эгей диңгезеннән килеп, Мәрмәр диңгезенә бары тик Дарданелл бугазы аша гына эләгергә мөмкин. Менә ул!

– Тимор диңгезен күрсәт!

– Бофорт диңгезе…

*(Экранда укытучының Галиевнең алдагы дәрестәге «5»ле билгесе янына «3»ле куйганы күренә. Р.Миңнуллин сүзләренә язылган «Күңелле тәнәфес» җырының 1 нче куплеты яңгырый. Укучылар, кушылып җырлый-җырлый, тәнәфескә чыгалар.)*

Чылтырый кыңгырау,
Дәрестән чыгарга.
Кыңгырау-тәнәфес
Яратучыларга.
Кыңгырау-тәнәфес
Яратучыларга.

*(Мәктәп директоры баянда уйный. Укучылар белән берлектә уеннар, биюләр оештырыла.)*

1. «Яулык салыш» уены.

2. Татар халык биюе «Алтылы».
*«Күңелле тәнәфес» җырының 2 нче куплеты дәрескә чакыра.*

Көч кирәк укырга,
Көч кирәк һәр эшкә.
Чылтырый кыңгырау –
Монысы дәрескә. (2)

*Укучылар парталар артына утырышалар. Музыка акрыная барып тына.*

**А.Б.** Математика укытучысы Хәсән ага Мурзин гаҗәп хәрәкәтчән кеше иде. Бакчасында төрле җиләк-җимеш, хәтта йөземгә кадәр үстерсә дә, аның төп дөньясы математика иде. Катлаулы тигезләмәләр чишеп күрсәткәндә дә, бәхетле халәткә безне дә алып керә, мавыктыра белә иде. Саннардан шигърият табу һәркемгә бирелмәгән шул.

**Хәсән ага** *(ишектән керә-керешкә үк)*. Бишенче, унбишенчеләр тактага. *(Җитез генә килеп, тактаны икегә бүлә.)* Тактадагылар 67 нче, калганнар 68 нче мәсьәләне чишә. Эшләгез... *(Укучыларның мәсьәлә чишүе экранда күренә, тактага бары тик җавап кына языла.)*

**Беренче бетергән укучы** *(кыюсыз гына)*. Мин бетердем, абый.

**Хәсән ага** *(сикереп тора да кинәт кычкырып җибәрә)*. Әллә шулай чыкты?! *(Укучы тиз генә җавапны сөртеп куя.)*

**Хәсән ага** *(сүзеп карап тора да шыпырт кына.)* Утыр... *(Укучы мәсьәләне кабат чишә башлый, икенче төрле җавап язып куя.)*

**Хәсән ага.** Утыр... *(Укытучы беренче тапкыр чыккан җавапны язып куя.)* Нигезле белмисең, җавабың дөрес иде. Үз-үзеңә ышанычың юк! Дүртле.

*(Сәхнәгә, сөйләшә-сөйләшә, өлкән укытучы белән яшь укытучы чыга.)*

**Ө.У.** Укытучыларым арасында сыйныф җитәкчем Фәйрүзә апа аерым урын алып тора. Ул елмайса, сыйныф эче яктылык белән тула иде. Дәресләренә бик яратып йөри идек.

*Бер кулына мандолина тотып, култык астына ватман кыстырып, иңенә фотоаппарат асып, Фәйрүзә апа керә. Укучылар аның кулыннан әйберләрне тиз генә бүлешеп алып бетерәләр. Берсе мандолина чиртә, икенчесе ватманга нидер яза, өченчесе фотога төшерә башлый.*

**Фәйрүзә апа.** Җомга көнне булачак бәйрәм концертына чакырып, белдерү язарга кирәк. Рәмилә, бу эшне сиңа тапшырам. Укучылар, бүген кич «Драмтүгәрәк». Яңа спектакльгә рольләр бүләбез. Соңга калмагыз.

**1 нче укучы.** Минем дә концертта чыгыш ясыйсым килә. Булдыра алмам дип шикләнәм. Минем бернәрсәгә дә сәләтем юк.

**Фәйрүзә апа.** Кошлар тумый канатсыз, кеше тумый талантсыз, ди татар халык мәкале. Сәләтсез кеше булмый, һәммә кешегә дә тумыштан бирелә.

**2 нче укучы.** Бер кеше берничә сәләткә дә ия була ала, әйеме, апа. Әнә безнең Рәмилә кебек.

**Фәйрүзә апа.** Әлбәттә, Нияз. Бер сәләт башка бик күп сәләтләрне ачарга сәбәп булырга да мөмкин. Аны вакытында танып ала белергә генә кирәк.

**Укучы.** Кеше моңа зур тырышлык күрсәтеп кенә ирешә ала, әйе бит, апа.

**Фәйрүзә апа.** Әлбәттә, шулай, укучылар. *(1 нче укучыга мөрәҗәгать* итә.) Син, Миләүшә, бик матур сөйлисең, яттан күп шигырьләр беләсең. Әйдә,

шуларның берәрсен сәхнәдән укы. Һәркемгә ошаячак. Менә мин әйтте диярсең. *(Укучыларга мөрәҗәгать итә.)* Иртәгә безнең «Фототүгәрәк» көне бит. Экскурсия вакытында төшкән фотоларны ясарбыз. Ә хәзер инструменталь ансамбль чыгышын кабатлап алыйк. Кыңгырау чылтыраганчы өлгерәбез әле. *(Укытучы укучыларга тезелергә булыша, кисәтүләр ясый, төзәтмәләр кертә. Укучылар тезелеп беткәч, әкрен генә артка күчә һәм сәхнәдән чыгып китә.)*

**Инструменталь ансамбль башкаруында «Суда, суда» татар халык җыры башкарыла.**

*Сәхнәгә өлкән һәм яшь укытучы чыга.*

**Ө.У.** Менә шулай, Гөлназ. Ничек кенә өлгереп беткәндер шулкадәр эш оештырырга. Педагоглык эшчәнлегемдә дә остазымның роле бик зур. Мин, үзем дә сизмичә, аның һәрбер сыйфатын үземә үрнәк итеп алганмын. Ул гомерем буена минем өчен намуслылык, тәрбиялелек, зыялылык, сабырлык үрнәге булды. Тиздән үзе дә килеп җитәргә тиеш. Белем бәйрәменә килми калмый ул.

*Бер укытучы Фәйрүзә апаны җитәклап керә.*

– Бәйрәмебезнең кадерле кунагы – Фәйрүзә апабыз килеп җитте. *(Хәл сорашу. Сәхнәдәгеләр чиратлап шигырь юлларын укыйлар.)*

Рәхмәт сезгә, укытучым,
Тирән белем биргәнгә.
Рәхмәт йөрәк җылыгызны
Безгә тигез бүлгәнгә.

Бик яратып ачтыгыз сез
Катлаулы фән серләрен.
Армый-талмый яуладык без
Биек белем үрләрен.

Белем иле ачкычлары
Бар бит сезнең кулларда.
Сез кабызган якты утлар
Маяк кебек юлларда.

**«Укытучыма» җыры башкарыла.**
(Илназ Бах репертуарыннан.)

**Ө.У.** Ясамадым олы ачышлар,
Менгәнем юк минем галәмгә.
Бары гади укытучы булып
Хезмәт итәм шушы гамәлдә.
Мин гади бер укытучы булып
Хезмәт итәм бүген тормышта.
Һәр укучым – язылмаган роман,
Һәр дәресем маяк тормышка.

**«Уйларымда мәктәп еллары»**
*(Виталий Агапов көе һәм сүзләре)*

Балачакның гүзәл бер мизгеле
Хәтеремдә минем бүген дә.
Кулга тотып чәчәк бәйләмнәре
Килгән көнем белем иленә.

Кыңгыраулы мәктәп елларына
Алып кайта мине уйларым.
Укытучы апам дәшә сыман:
Улларым сез минем, кызларым.

Хуш килдең син, балам, әйдә,
диеп,
Алып киттем тормыш юлыннан.
Авыр чакта ярдәм кулы суздың,
Саклдың син ялгыш адымнан

Өйрәттең син, ярат, балам,
диеп,
Туган илне, әткәң-әнкәңне.
Гомерең буе халкың өчен тырыш,
Онытма син туган телеңне.

*Юлия КАЛИНИНА фотосы*

5




# ӘДӘП-ӘХЛАККА ӨНДӘҮЧЕ ӘСӘРЛӘРНЕҢ ЙОГЫНТЫСЫ

**Альбина ФӘТХЕТДИНОВА,**

Азнакай районы Чубар Абдул урта мәктәбенең I квалификация категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы

**Максат**: татар телен, әдәби мирасны пропагандалау; татар язучыларының әсәрләрен популярлаштыру; татар әдәбиятына кызыксыну уяту.

**Бурычлар:** Ркаил Зәйдулла иҗатына күзәтү ясау; татар телен, әдәп-әхлак, милләтне саклауны күз уңында тоткан әсәрләргә анализ; аларның хәзерге чордагы актуальлеген билгеләү. Дәрестән тыш чарага (мөмкинлеккә карап) Ркаил Зәйдулла әсәрләре буенча куелган спектакльләрдә катнашкан актёрларны чакыру да каралган.

**Дәрестән тыш чарага кадәр башкарыласы эшләр:** Ркаил Зәйдулла әсәрләре буенча куелган спектакльләр белән танышу, аларның видеоязмаларын күрсәтү, рецензияләрне уку.

**Чара барышы**

*Дәрестән тыш чара театральләштерелгән формада бара. Дәрестән тыш чара 9–11 нче сыйныфлар өчен туры килә.*

*Залда компьютер өстәле, кечкенә кәнәфи, китаплар киштәсе тора. Өстәлдә 18 яшьлек малай, колагына наушник кигән килеш, компьютерда уйный. Кәнәфидә 20–30 яшьләрдәге туташ телефонга багып утыра. Китап киштәләренең тузанын сөртеп бабай йөри.*

**Бабай** (*тузан сөртүеннән кисәк туктап*). Бу кадәр китапны тузан җыеп ятсын дип җыйдыммы мин? Кара әле! Кемнәр генә юк бит монда! Туфан Миңнуллин, Роберт Миңнуллин, Адлер Тимергалин, Ркаил Зәйдулла дисеңме! Монысын килен белән улым театрга алып баргач сатып алган идем… Монысын үзләре алып кайтып бирде. Килен эшли торган җирдә элек архив булган. Шундагы китапларны чыгарып ташларга теләгәннәр. Байлык бит бу! Ничек чыгарып ташлыйсың! Бу китапларның һәр битендә, һәр хәрефендә тәрбия, мәгънә, әдәп ята! *(Оныкларына игътибар итеп.)* Карагыз әле, әй балалар! Сезгә дәшәм! Эдик, Әдилә! Ишетмисез дә!

**Әдилә** (*телефоныннан бер мизгелгә генә аерылып тора да*). Нәрсә булды, бабай? Минем хәзер вебинар була! Әзерләнәм. Комачаулама әле, пожалуйста!

**Бабай.** Нәрсә соң ул синең вебинарың? Дәресме ул?

**Әдилә.** Синеңчә, дәрес. Заманча әйтсәк, вебинар. Акыл өйрәтәм. Психология буенча!

**Бабай.** Акыл өйрәтергә… Психологка укыдыңмы соң син? Син бит белемең буенча укытучы?

**Әдилә.** Булса ни? По профессии хәзер берәү дә эшләми! Не выгодно! Яшь башым белән мәктәптә «ташбашлар»га «икеле» сырлап утырасы килми әле.

**Бабай**. Ә ник «икеле» сырлыйсың? Укытырга кирәк! Әдәпкә, әхлакка өйрәтергә!

**Әдилә.** Бабай! Хәзер бөтен кеше дә әдәпне дә, әхлакны да әнә телефоннан таба! Йә булмаса, әнә Эдик сыман, компьютер уеннарыннан. Күрдеңме, нинди әдәп аның анда?! Акырышалар да суешалар.

**Бабай.** Караган саен таң калам мин сезгә, балалар. Йә, болай булмый! Хәзер күрсәтәм

әле мин сезгә! *(Чыгып китә. Интернетны, утны өзә, оныклар чырылдый башлый.)* Йә, нәрсә? Булдымы вебинарларыгыз? Уйнап туйдыгызмы?

**Эдик.** Бабай, ну ник син алай эшләдең инде? Мин инде бу уенны атна буе уйнап бетерә алмыйм! Урамдагы пацаннар әллә кайчан яңа уровеньга күчте, ә мин һаман да шушы 10 нчы уровеньда! Позор!

**Әдилә**. Ә мин хәзер вебинар ничек уздырам инде? Вай-фай булмагач! Монда бит Интернет тотмый!

**Бабай**. Компьютер уенын бер атна буе уйныйм дисеңме? Ә син, укытучы башың белән, кеше башын бутыйм дисеңме? Менә нәрсә ул позор! Сезнең белән тәрбия сәгате уздырып алмыйча булмас бугай.

**Эдик, Әдилә.** Началось!

**Бабай.** Менә бу киштәләргә карагыз әле! Әйдәгез, берәр китапны сайлагыз! Шуның буенча мәгълүмат бирәм.

**Эдик.** Ник кирәк инде ул миңа?

**Әдилә**. Что это нам даст?

**Бабай.** Акыл бирәчәк. Белем өстәячәк. Боларда бит барысы да бар! Тарих та, милләт тә, мәгънә дә!

**Бабай.** Ә-ә, Ркаил абыең Зәйдулла китабы бу! Менә дигән язучы! Шагыйрь, драматург, язучы, үзенчәлекле фикер иясе. Ул алган премияләрне санап бетерерлек түгел! Җәлилне дә, Тукайны да алды ул.

*(Залга экран чыгарыла. Бу экранда презентация яисә видеорәт рәвешендә Ркаил Зәйдулланың кыскача тәрҗемәи хәле күрсәтелә. Интервьюлардан өзекләр, видеоматериаллар кулланырга мөмкин. )*

**Әдилә.** О чём он писал-то? Есть что-то про психологию?

**Бабай.** Ркаил Зәйдулла кебек язучыларның әсәрләрендә тирән мәгънә ята, балалар. Кирәк дисәң, психологиясен табарга була. *(Китап киштәсеннән китап ала.)* Йә, менә, мәсәлән, «Үлеп яратты» әсәрен алыйк. Нәрсә турында дип уйлыйсыз?

**Эдик.** Мәхәббәт инде! Яратты дигән сүз бар ич. Ромео и Джульетта, Таһир һәм Зөһрә, и всё такое!

**Бабай.** Бер яктан, дөрес әйтәсең, улым. Тик бу әсәр тирәнрәк шул... Йәле, компьютерыңны кабыз!

*(Компьютердан «Үлеп яратты» спектакленнән Мөхлисә Буби монологын карыйлар.)*

**Бабай.** Әхлак, әдәп диннән башлана, балалар. Милли үзаңнан башлана барысы да! Ркаил абыегыз бу әсәре белән күренекле мәгърифәтче, педагог, беренче казыя, Россиядә мөселман хатын-кызлары өчен тәүге уку йортларына нигез салган, милләт дип нәтиҗәле хезмәт иткән, милли мәдәниятебезне саклау өчен көрәшкән Мөхлисә Бубига багышланган. Сталин чорында мәдәниятебез коточкыч зур югалтулар кичерә: йөзләгән, меңләгән татар зыялылары, әдәбиятчылары, фән вәкилләре, җәмәгать эшлеклеләре һәм дин әһелләре юк ителәләр, ә аларның хезмәтләре тыелалар. Үзләрен аямыйча халкыбызга хезмәт иткән бу шәхесләрнең

исемнәре, эшләре безгә хәзер бигрәк тә мөһим. Киләчәк буын белсен, үрнәк алсын өчен кирәк бу! Мөхлисә Буби соңгы сулышында да иманлы булып кала. Намазын да калдырмый. Итагатьле, тәрбияле, зыялы ханым! Бу бит рухи яктан нык булу үрнәге, балалар!

**Әдилә.** Мөхлисә Буби соңгы сәгатенә кадәр иманына, иман белән сеңгән тәрбиясенә, сынмас рухына таяна! Чын хатын-кыз үрнәге бит бу! Какая драма, какая личность! Это очень интересно! Чор нинди кешеләр тудыра бит, әй!

**Бабай**. Ә мин нәрсә дим? Менә шуларны өйрәнер идең, кызым. Зәйдуллинның яраткан темасы инде ул – тарихи вакыйгаларның шәхестә чагылышы, кешене ничек үзгәртүе, аңа ничек итеп тәэсир итүе.

**Эдик.** «Са...таш...кан сандугач» әсәре нәрсә турында? Про природу что-ли?

**Бабай.** Ә-ә, юк, улым. Бу әсәрдә бик зур проблемалар ярылып ята. Алар хәзерге заман өчен дә актуаль. Яшь, үсеп килүче буынга исә гыйбрәт булырлык әсәр ул! Әйдә, ач компьютерыңны!

*(Компьютердан «Саташкан сандугач» спектакленнән өзекләр карыйлар.)*

**Бабай.** Күрдегезме, балалар. «Саташкан сандугач» драмасы – нинди катлаулы, тирән психологик әсәр. Кеше бәхетен урлап, үз бәхетеңне корып булмый дигән фәлсәфә ята анда.

**Әдилә.** Минемчә, «Саташкан сандугач»та бүгенге җәмгыятьтә бара торган тискәре процессларның яшь буынга ничек начар тәэсир итүе дә күренә. Чөнки мондагы геройларның идеаллары югала, саф хыяллары чәлпәрәмә килә, ниндидер куркыныч сыйфатлар алга чыга...

**Эдик.** Про это можно фильм снять!

**Бабай.** Ркаил Зәйдулланың әсәрләрен фильм итәргә дә, спектакль итеп чыгарырга да була. Алар барысы да – актуаль, мәгънәле! Һәм, һичшиксез, һәр кеше аның әсәреннән үзенә кирәген алачак.

**Әдилә.** «Сөембикә» дигән хикәясе дә бар икән. Анысы нәрсә турында? Про царицу?

**Бабай.** Бу хикәя ханбикә турында түгел, әмма хикәя героеның да язмышы бик фаҗигале... Балалар, мин алдарак нәрсә дидем әле? Милли үзаң булырга тиеш дидемме? Милли үзаңы көчле, нык, югары булган кеше мескен дә, кол да булмый, ул баш ими, горур була. Ә менә бу хикәядә, кызганыч, милләтнең мескен кешеләре дә урын алган. Аларны мескенлеккә эчкечелек, әхлаксызлык илткән. Яшьләргә «Мондый булырга һич ярамый!» дип, колакларына киртләп куяр өчен бер дигән әсәр инде ул.

**Эдик** *(компьютерына карап)*. Бабай, кара әле. Монда бит әле күпме әсәр, күпме пьеса, шигырь!

**Әдилә.** Кая, кая? Тә-әк, менә монысын теркәп куям. Менә монысын укыйсы булыр. Ә бу нәрсә турында икән?

**Бабай.** И-и балалар, кайсысын укысагыз да, рәхмәт. Андый кешеләрне белергә кирәк. Китап – тәрбия чишмәсе ул.

6



# КИЕМНӘР КИБЕТЕНДӘ

*(2 нче сыйныфта татар теле дәресе)*

**Римма ГОБӘЕВА,**

Казандагы 132 нче урта мәктәпнең
югары квалификация категорияле
татар теле һәм әдәбияты укытучысы

**Дәрес тибы:** яңа белемнәр ачу дәресе.

**Максат:**

– өйрәнелгән лексик-грамматик материалны кабатлау һәм системалаштыру;

– яңа лексика белән таныштыру һәм сөйләмдә кулланырга өйрәтү;

– укучыларны кибетләр һәм анда сатыла торган кием исемнәре белән таныштыру;

– киемгә карата сакчыл караш тәрбияләү.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр**

*Шәхескә кагылышлы:* укучыларның башкарган эшенә җаваплылык хисен арттыру, эшне җаваплы, аңлап башкару; татар телен белүнең әһәмиятен аңлау.

**Метапредмет**

*Танып белү УУГ:* җөмләдәге фактик мәгълүматларны таба белү; төшенчәләр чыгара белү; уку гамәлләрен башкаруда барлыкка килгән каршылыкларны билгеләү.

*Коммуникатив УУГ:* аралашу вакытында үз фикереңне формалаштыру һәм дәлилләү; әңгәмәдәшләреңнең фикерләрен тыңлап, уртак фикергә килү.

*Регулятив УУГ***:** дәреснең максатын ачыклый алу, эш вакытында килеп чыккан кыенлыкларны билгели белү, эшчәнлеккә үзбәя бирү.

*Предмет буенча:* киемнәр кибете белән бәйле лексиканы баету, 1 нче һәм 2 нче зат тартым кушымчаларын куллануны камилләштерү.

**Предметара бәйләнеш:** рус теле, математика.

**Эшне оештыру:** фронталь, төркемнәрдә, парларда, индивидуаль.

**Җиһазлау:** дәреслек (Хәйдәрова Р.З. «Күңелле татар теле» китабы.

2 нче сыйныф, 2020), дәфтәрләр, методик кулланма (Хәйдәрова Р.З. Укытучылар өчен методик кулланма. 2 нче сыйныф, 2020), мультимедиа, слайдлар, экран, дидактик-күрсәтү материаллары.

**Дәрес барышы**

**I. Оештыру. Мотивлаштыру**

**Укытучы.** Исәнмесез, укучылар! Хәерле иртә!

**Укучылар.** Хәерле иртә миңа, хәерле иртә сиңа, хәерле иртә аңа, хәерле иртә безгә, хәерле иртә сезгә, хәерле иртә аларга.

**Укытучы.** Укучылар, әйдәгез, дәресне яхшы кәефтән башлыйк. Ә кәеф яхшы булсын өчен нишләргә кирәк?

**Көтелгән җавап.** Яхшы сүзләр әйтергә.

**Укытучы.** Мин менә бу матур сүзләр тартмасын җибәрәм, сез чылбыр буенча бер-берегезгә яхшы сүзләр әйтегез.

**Көтелгән җавап.** Алсу, синең портфелең матур, синең карандашың яңа һ.б.

**Укытучы.** Укучылар, тактага игътибар итик әле. Кем безгә матур итеп әлеге мәкальне укып бирер?

**Көтелгән җавап.** «Гыйлем ашарга сорамас, ашарга бирер». *(Татар халык мәкале)*

*(Уку, гыйлем алу, күп белү кешегә зыян итми, киресенчә, күбрәк мөмкинлекләр генә бирә. Мәсәлән, әгәр дә без 3 телдә су сорый беләбез икән, димәк, ким дигәндә, 3 илдә без сусыз калмаячакбыз.)*

**Укытучы.** Укучылар, ә сез гыйлем алырга әзерме? *( Әйе, әзер)*

**II. Белемнәрне актуальләштерү. Яңа материалны үзләштерүгә ихтыяҗ тудыру**

**Укытучы.** Укучылар, әйдәгез, өй эшен тикшереп алыйк. Кем 1 нче төр өй эшен эшләде (6 нчы күнегү), кулларыгызны күтәрегез. Әйдәгез, экран буенча үзебезнең эшләребезне тикшерик. **(Слайд)**

**Эталон**
Урман: поши, төлке, аю, бүре, куян.
Авыл: сыер, сарык, кәҗә, ат, әтәч.
*(Куян.)*

**Укытучы.** Кем 2 нче төр өй эшен эшләде (7 нче күнегү), экрандагы эталон буенча өй эшләрегезне тикшерегез.

**Эталон**
Әтәч авылда яши.
Куян урманда яши. *(Куян урманда да, авылда да яши.)*
Ат авылда яши.
Сыер авылда яши.
Сарык авылда яши.
Аю урманда яши.
Кәҗә авылда яши.
Төлке урманда яши.

**Укытучы.** Кем 3 нче төр өй эшен эшләде, шулар 3 нче рәткә күчеп утыра, бер-беребезнең эшләрен тикшерәбез, иң кызыклысын сайлыйбыз һәм сыйныфка әйтәбез.

**Укытучы.** Кем 1 нче төр өй эшен хатасыз эшләде, кулларыгызны күтәрегез. Нинди дә булса кыенлык тудымы?

**Көтелгән җавап.** Мин куянны кайсысына кертергә белмәдем, чөнки ул күбрәк урманда яши, әмма хәзер аны авылларда да үрчетәләр.

**Укытучы.** Чыннан да, куянны күп очракта без урман белән бәйләп язабыз, әмма икесендә дә, тагын да дөресрәк булыр. 3 нче төр өй эшен эшләгән укучылар, сез кемнең эшен иң кызыклы дип таптыгыз? Әйдәгез, бу табышмакны сыйныфка да әйтеп карыйк.

**Көтелгән җавап.** Минемчә, бу кроссенсның җавабы – хайваннар, дөресрәге кыргый хайваннар, чөнки монда куян, төлке, аю, поши, бүре, тиен, керпе, кабан дуңгызы ясалган.

**Укытучы.** Бик яхшы. Башка кроссенс ясаучы укучылар да үз эшләренә исем-фамилияләрен язып, миңа тапшырырлар. Сезнең парталарда үзбәя конвертлары тора, сез аларга түгәрәкләр салып барырсыз. Яшел түгәрәк – бик яхшы җавап, сары түгәрәк – яхшы җавап, әмма бераз тырышырга кирәк, кызыл түгәрәк – тырышырга кирәк. Ә хәзер өй эше дөреслеге буенча бер түгәрәкне үзбәя конвертларына салып куегыз. *(Укучылар үз эшләрен бәяләп куялар.)*

**III. Кыенлык тууның урынын һәм сәбәбен билгеләү этабы**

**Укытучы.** Укучылар, экранга карагыз әле, сезгә монда кроссенс бирелгән, моның җавабы – безнең бүгенге темабыз. Ничек уйлыйсыз, сорау билгесе астында нинди тема яшеренгән икән?

**Көтелгән җавап.** Минемчә, безнең тема «Киемнәр» дип атала, чөнки монда төрле киемнәр ясалган. Без аларны сатып алабыз һәм киябез.

**Көтелгән җавап.** Ә мин безнең тема «Киемнәр кибете» дип уйлыйм, чөнки монда киемнәр дә бар, касса һәм акча белән акча янчыгы.

**Укытучы.** Дәреснең темасын белер өчен безгә тагын бер күнегү эшләргә була.

**IV. Кыенлыктан чыгу проектын төзү**

Сөйләшүнең кайда барганын ачыкларга.
1) Ашамлыклар кибетендә.
2) Киемнәр кибетендә.
3) Яшелчә кибетендә.
4) Икмәк кибетендә.
– Исәнмесез, сездә миңа яраклы сарафаннар бармы?
– Бар, кайсы төстәгесе кирәк?
– Миңа кызыл төстәге сарафан килешә.

– Менә киеп карагыз.

– Рәхмәт. Ул ничә сум тора?

–14 сум. 3 нче кассада түләгез.

**Көтелгән җавап.** Бүгенге дәреснең темасы «Киемнәр кибетендә», чөнки әлеге диалогта кыз үзенә сарафан сатып ала, ә сарафан – ул кием.

**Укытучы.** Укучылар, әлеге теманы яхшылап аңлар өчен безгә нишләргә кирәк?

**Көтелгән җавап.** Дәреслек белән эшләргә. «Киемнәр кибете» темасы буенча яңа сүзләр өйрәнергә.

**V. Төзелгән проектны реализацияләү**

**Укытучы.** Укучылар, 118 нче битне ачтык, 1 нче күнегүне таптык. Нинди бирем бирелгән?

*(Укучылар текстны укый.)*

**Укытучы.** Әйе, дөрес. Әйдәгез, без хәзер матур итеп утырдык, игътибар белән мине тыңлыйбыз, аннан соң сез укырсыз. *(Укытучы укый, укучылар укыйлар.)*

**Укытучы.** Таныш булмаган сүзләр бармы*? (Әйе.)*

**Укытучы.** Әлеге сүзләр тексттан соң бирелгән, әйдәгез, без бу сүзләрне сүзлек дәфтәрләренә теркәп куйыйк. *(Укучылар сүзләрне сүзлек дәфтәренә язып куя. 5–7 тапкыр кабатлау.)* Текстта аңлашылмаган сүзләр калдымы?

**VI. Сөйләмдә кулланып, беренчел йомгаклау**

**Укытучы.** Кем безгә эчтәлекне сөйләп карый?

**Көтелгән җавап.** Әти, әни һәм Айгөл кибеткә бардылар. Айгөлгә күлмәк һәм итәк кирәк.

– Апа, миңа матур күлмәк кирәк.

– Бездә күлмәкләр күп. Сиңа нинди төс ошый?

– Зәңгәр.

– Менә карагыз.

– Кызым, сиңа килешә.

– Рәхмәт, әнием.

Айгөлгә күлмәк алдылар, Айгөл шатланды.

**Укытучы.** Бик яхшы.

**Ял минуты**

**Укытучы.** Хәзер мин сезгә җөмләләр әйтәм, ә сез бу текстка туры килсә, моны күрсәтәсез, әгәр җөмлә текстка туры килмәсә, сез аны күрсәтмисез.

**Укытучы.**

Айгөл кибеткә барды.(+)

Апа, миңа чалбар кирәк.(-)

Бездә күлмәкләр юк.(-)

Сездә кызыл күлмәк бармы?(-)

Менә карагыз.(+)

Бу күлмәк сиңа килешә!(+)

Сау бул, әнием.(-)

Айгөлгә бияләй сатып алдылар. (-)

Айгөл шатланды.(+)

**Укытучы.** Бик яхшы. Кемнәрнең чалбары кара төстә, шул такта янына чыга. Сез беренче төркем буласыз. Кемнең кара чалбары юк, алар икенче төркемдә була. Сезгә төрле кием рәсемнәре бирелгән, аларны төрле төркемгә бүләргә кирәк булачак, сез нинди төркемнәргә бүләрсез, ни өчен? *(Рәсемнәрдә пальто, тун, куртка, яулык, эшләпә, башлык, киез итек, резин итек, ботинкалар.)*

**Көтелгән җавап.** Өч төркемгә бүлдек: баш киеме, өс киеме, аяк киеме.

**Укытучы.** Бик яхшы, утырыгыз. Хәзер 4 нче күнегүнең биремен укыгыз. Парлап эшлибез. Берәрләп әйтәбез. *(Укытучы укучыларның эшен тикшерә, хаталарын төзәтә.)* Әлеге күнегүне эшләгәндә, авырлыклар тудымы? Безгә бу хаталарны ничек төзәтергә икән соң?

**Көтелгән җавап.** Безгә тагын да күбрәк күнегүләр эшләргә кирәк.

**VII. Эталон буенча үзконтроль, үзеңне тикшерү этабы**

**Укытучы.** Әйдәгез, карточкалардагы биремнәрне эшләп алыйк.

**Карточка**

Тебе хочется узнать:

– есть ли в магазине платье красного цвета;

– сколько стоит юбка;

– подходит ли тебе это платье / эта рубашка?

*(Укучылар эшлиләр һәм эталон буенча тикшерәләр.)*

| |
|---|
| Карточкага эталон<br>(Сездә кызыл күлмәк бармы?)<br>(Итәк ничә сум тора?)<br>(Бу күлмәк миңа килешәме?) |

**VIII. Яңа белемнәрне куллану һәм кабатлау этабы**

**Укытучы.** Әйдәгез, тиз генә «Киемнәр кибете»ндә сатучы булып уйнап алыйк. Беренче рәттән башлыйбыз, сез сатучылар буласыз, ә икенче рәт алучылар була.

**Укучылар.** Исәнмесез!

– Исәнмесез! Сезгә нәрсә кирәк?

– Ә сездә нәрсәләр бар?

– Бездә күлмәк, чалбар, итәк, башлык, яулык, эшләпә, итек, резин итек, ботинкалар бар.

– Миңа күлмәк кирәк. Сездә зәңгәр күлмәк бармы?

– Юк, бездә кызыл күлмәк кенә бар. Киеп карагыз.

– Сезгә бик килешә.

– Рәхмәт. Ул ничә сум тора?

–15 сум.

– Бер, ике, өч, дүрт, биш, алты, җиде, сигез, тугыз, ун, унбер, унике, унөч, ундүрт, унбиш сум. *(Берничә укучы шулай саный.)*

– Сау булыгыз. Тагын килегез.

**IX. Рефлексия**

**Укытучы.** Әлеге дәрес нәрсәне өйрәнүгә багышланган иде?

**Көтелгән җавап.** Бу дәрестә без киемнәр кибете темасын өйрәндек. Яңа текст белән таныштык, яңа сүзләр белдек.

**Укытучы.** Укучылар, карагыз әле, безнең киемнәребез тәртипсез рәвештә калганнар, әйдәгез, без аларны тәртипләп шкафка куйыйк! Һәр укучы бер предметны алып куйса, безнең сыйныф тәртипкә керер иде.

**Көтелгән җавап.**

– Бу – эшләпә. Аны башка кияләр. Мин аны монда куям.

– Бу – яулык. Аны башка ябалар, мин аны монда куям.

– Бу – тун. Аны өскә кияләр, мин аны монда элəм.

– Бу – пальто. Аны өскә кияләр. Мин аны элгечкә элеп куям.

– Бу – киез итек. Аны аякка кияләр. Мин аны аска куям.

– Бу – резин итек. Аны аякка кияләр. Мин аны монда куям.

**Укытучы.** Бик яхшы. Чиста һәм пөхтә булды. Бу укучыларга килешәме? Әлбәттә, килешә.

**Укытучы.** Менә бу кечкенә генә карточкага үз фикерләрегезне языгыз әле. Теманы өйрәнгәндә нәрсәләр кыенлык тудырды? Нәрсә кызык булды? Нинди мәгълүматны истә калдырдыгыз? Бу сезгә тормышта кирәк булырмы? Кайда?

**X. Өй эше**

**Укытучы.** Әйдәгез, хәзер өй эшен язып куябыз. Сезгә өч төрле өй эше бирелә, кайсысы сезгә күбрәк ошый, шунысын сайлап аласыз.

1) 6 нчы күнегү, 120 нче бит, дустыңа комплимент яса. 3 җөмлә язып куй.

2) 7 нче күнегү, язмача.

3) «Киемнәр» темасына кроссенс яисә кроссворд ясап килергә.

**Билгеләр кую. Саубуллашу.**



7

# ТАТАР ТЕЛЕНЕҢ КИЛЕП ЧЫГЫШЫ ЯГЫННАН СҮЗЛЕК СОСТАВЫ

**Илсинә ГАРИФУЛЛИНА,**

Саба районы Тимершык урта мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы

**Дәрес барышы**

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру**

Исәнләшү, уңай психологик халәт тудыру.

**Укытучы.** Хәерле көн, укучылар! Туган тел дәресендә сезне сәламләвемә бик шатмын! Уңышлы уку көннәре телим.

**II. Уку мәсьәләсен кую**

**Укытучы.** Укучылар, бүген мәктәпкә барыгыз да иртәнге ашны ашап килдегезме? Нәрсә ашадыгыз? Иртән чәй эчеп килүчеләр бар идеме? Ә каһвә? Шоколад яисә какао? Укучылар, ә сез чәй сүзенең кайсы телдән керүен беләсезме? Каһвә, шоколад, какао?.. Бу сүзләр татар теленең үз сүзләреме? Димәк, бүгенге дәрестә нәрсә турында сөйләшербез? Әйе, бүгенге дәрестә без башка телдән кергән сүзләр турында сөйләшербез.

Дәресебезгә нинди максатлар куярбыз? Дәрестә нинди сорауларга җаваплар эзләрбез?

**Көтелгән җаваплар.**

**Укытучы.** Ни өчен телебезгә яңа сүзләр керә? Әлеге сүзләрне нинди сүзләр дип атыйлар? Татар теленә кайсы телләрдән сүзләр кабул ителгән соң? Башка телдән сүзләр кабул ителү уңай күренешме яисә тискәреме?

**III. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү**

**Укытучы.** Бүгенге дәрестә без эш битләрендә төрле биремнәр башкарырбыз, сезнең төрле тип текстлар белән эшли, кирәкле мәгълүматны аерып ала белүегезне, төрле төр эшләрне дөрес башкара белү грамоталыгыгызны бәяләрбез.

Ә хәзер дәресебезнең темасын төгәлрәк билгеләр өчен эш битендәге беренче биремне башкарыйк. Әлеге биремне башкарганда, мин сезгә *«Инсерт» алымы*н кулланырга тәкъдим итәм.

Әлеге текстны уку барышында

- сезгә таныш булган мәгълүмат язылган юлларга - ✓;
- сез яңалык дип тапкан урыннарга - **+;**
- килешмәгән фикерләр булса - **–;**
- текстны уку барышында сораулар, аңлашылмаучанлыклар туса, **?** билгесен куеп барыгыз.

| ✓ | + | – | ? |
|---|---|---|---|
| | | | |

**1 нче бирем.** Текстны укы. Сорауларга җаваплар яз**.**

Татарлар элек-электән үк сәүдә белән шөгыльләнгән. Башка илләр белән сәүдә эшләре алып барганлыктан, әлеге халыкның сүзлек байлыгы гел артып торган. Әлбәттә, тел үсеш кичерсен өчен, башка телләрдән яңа сүзләр кабул итү кирәк.

Татар теле башка телләрдән кергән сүзләргә бик бай. Мондый сүзләрне алынма сүзләр дип атыйлар. Туган телебезгә рус-Европа, гарәп-фарсы, һинд, монгол, кытай сүзләре үтеп керә һәм ныклап урнашып кала.

Татар телендә саны һәм активлыгы белән гарәп, фарсы һәм рус алынмалары аерылып тора.

1. Алынма сүзләр нинди сүзләр ул?
2. Алынма сүзләр телгә нинди юллар аша үтеп керә?
3. Татар телендә кайсы телләрдән кергән сүзләр бар?
4. Телгә яңа сүзләр үтеп керү уңай күренешме яисә тискәреме, ни өчен шулай уйлыйсың?

**Көтелгән җавап.**

1. Алынма сүзләр – башка телләрдән кергән сүзләр.
2. Алынма сүзләр телебезгә сәүдә

эшләре һәм башка юллар аша үтеп керә.

3. Татар телендә рус-Европа, гарәп-фарсы, һинд, монгол, кытай телләреннән кергән сүзләр бар.

4. Телгә яңа сүзләр үтеп керү уңай күренеш дип уйлыйм, чөнки бу күренеш телнең сүзлек составы үсүгә китерә.

**Укытучы**. Димәк, бүгенге дәресебезнең темасы – «Алынма сүзләр».

– «Инсерт» алымы буенча укылган текстка нәтиҗә ясыйк.

**Көтелгән җавап.** Әлеге текстны укыганнан соң, мин түбәндәге нәтиҗәгә килдем:

| ✓ | + | – | ? |
|---|---|---|---|
| *Мин таныш:* Татар теле башка телләрдән кергән сүзләргә бай. Мин үзем дә сөйләмемдә алынмалар кулланам. | *Минем өчен яңалык:* Татар телендә һинд, монгол, кытай телләреннән кергән сүзләр бар икән. | *Мин килешмим:* Бу тексттагы барлык фикерләр белән мин килешәм. | *Мин аңламадым:* Ни өчен телебездә алынма сүзләр шактый күп очрый, бу уңай күренешме? |


*(Җаваплар төрлечә булырга мөмкин, үзара фикер алышыныла.)*

**Укытучы.** Татар теле һәрвакыт үсеш-үзгәрештә, һәм аның үсешенә, әлбәттә, башка телләрнең йогынтысы да бар. Ә сезнең үзегезнең сөйләмегезгә игътибар иткәнегез бармы? Без куллана торган сүзләр кайсы телдән кергән сүзләр икән? *(Фикер алышу.)*

– Чыннан да, без үзебез дә сизмәстән, башка телдән кергән һәм татар теленең лексик составына инде ныгып урнашкан сүзләрне һәрдаим кулланабыз. Ә татар теленең сүзлек составын күбрәк кайсы телләрдән кергән сүзләр тәшкил итә икән соң? Әлеге сорауга җавап табар өчен эш битендәге 2 нче биремгә күчик.

**2 нче бирем.** Диаграмманы өйрән һәм сорауларга җавап бир:

1. Татар теленең сүзлек составын нинди сүзләр тәшкил итә?
2. Кайсы сүзләр татар теленең лексик нигезен барлыкка китерә?
3. Алынма сүзләрдән кайсы тел сүзләре күбрәк кулланыла?
4. Кулланылыш ягыннан 3 нче урында торган алынмаларны атагыз.
5. Әлеге диаграммага нигезләнеп, партадашыгызга татар теленең килеп чыгышы ягыннан лексик составы турында сөйләгез.




(Сорауларга җаваплар алына, укучылар, парлашып, татар теленең килеп чыгышы ягыннан лексик составы турында фикер алыша.)

**Көтелгән җавап.**

1. Татар теленең сүзлек составын төрки-татар, гарәп-фарсы, рус, инглиз, француз, итальян, немец сүзләре тәшкил итә.
2. Төрки татар сүзләре татар теленең лексик нигезен тәшкил итә.
3. Алынма сүзләрдән рус теле

сүзләре күбрәк кулланыла.

4. Кулланылыш ягыннан 3 нче урында торган алынмалар инглиз теленеке.

5. Татар теленең килеп чыгышы ягыннан лексик составын татар теленең үз сүзләре һәм алынмалар тәшкил итә. Төрки-татар сүзләре лексик составның нигезен барлыкка китерәләр. Татар телендә башка телдән кергән сүзләр дә кулланыла. Мәсәлән, гарәп-фарсы, рус, инглиз, француз, итальян һ.б. Иң күп алынма сүзләр рус теленеке (14 % тәшкил итә). Иң азы һинд-Европа телләренеке (инглиз, француз, итальян, немец һ.б.)

**Укытучы.** Димәк, телебезнең сүзлек составын сез диаграммада күреп киткән телләрдән кергән сүзләр тәшкил итә. Ә хәзер без алынмаларга мисаллар барлап китәрбез. Моның өчен сезгә эш битендәге схеманы өйрәнеп, өченче биремне башкарырга кирәк булыр.

**3 нче бирем.** Эш битендәге схеманы өйрән һәм таблицаны тутыр.

**Көтелгән җавап.**

**Ял минуты**

**Укытучы.** Хәзер мин сезне «Серле әңгәмә»гә чакырам. Әйдәгез, түгәрәккә җыелып утырыйк. Без сезнең белән якыннанрак танышырбыз. Әлеге **әңгәмә-уенның кагыйдәләре:**

Туп тоткан кеше үзенең исемен һәм үзе турында бер кызыклы факт әйтергә тиеш. Ләкин бер шарт бар: сез җөмләләрегездә таблицага тутырган төрки-татар сүзләрен яки алынмаларны кулланырга тиеш буласыз. Мәсәлән, «Мин – Илсинә Илдус кызы. Парашюттан сикерү – минем зур хыялым». Әлеге җөмләдә француз сүзен (парашют) кулландым.

Туп башка укучыга тапшырыла, уен шул рәвешчә дәвам ителә.

**Укытучы.** Эшебезне дәвам иттереп, алдагы биремгә күчик.

**4 нче бирем.** Функциональ грамоталылыкны бер компоненты буларак креатив фикер йөртү эшчәнлеген үстерү максатыннан ребуслар чишү.

**Көтелгән җавап.** Эскерт, волейбол, басмаханә, ландшафт.

**5 нче бирем.** Компьютерлык грамоталылыгын үстерү өчен бирем.

Татар теленең онлайн аңлатмалы сүзлегенә мөрәҗәгать ит. 3 нче биремдәге сүзләрнең мәгънәләрен укы һәм кайсы телдән керүләрен ачыкла.

**Көтелгән җавап**.

**Эскерт –** печәннән, саламнан яки

| **Төрки-татар сүзләре** | **Гарәп-фарсы** | **Француз** | **Рус** | **Инглиз** | **Немец** | **Итальян** |
|---|---|---|---|---|---|---|
| бер, мин, кичә, абый, әби һ.б. | хат, рәсем, сәгать, табигать | опера, парашют, газон, костюм | өстәл, шәл, кәбестә, караватт | финиш, хоккей, клоун, бокс | фокус, штанга, шлагбаум, галстук | опера, помидор, газета, гирлянда |

көлтәләрдән махсус ысул белән салынган зур кибән. Рус алынмасы – скирд.

**Волейбол** – тартып куелган ятьмә аша бер командадан икенче командага кул белән туп ыргытып уйный торган спорт төре. Инглиз алынмасы – volleyball.

**Ландшафт** – җир өслегенең үзенә генә хас рельефы, климаты, туфрагы, үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы булган бер кисәге. Немец алынмасы – landschaf.

**Басмаханә –** газета-журналлар, китаплар басыла торган урын; типография; матбага. Гарәп-фарсы алынмасы.

**IV. Рефлексия. Йомгаклау**

**Укытучы.** Дәресебез ахырына да якынлашты. Бүгенге дәрескә нәтиҗә ясар өчен «Биш бармак» алымын кулланырбыз.

**Чәнти бармак**. Нинди яңа белемнәр алдыгыз? Нинди проблемалар белән очраштыгыз? Нинди хаталар җибәрдегез?

**Атсыз бармак**. Максатыгызга ирешер өчен нәрсәләр эшләдегез? Нәрсәләр эшләргә әле җитешмәдегез?

**Урта бармак**. Нинди хисләр кичердегез? Нинди хисләр өстенлек итте? Кайсы эш төрләре сезгә кызыклы иде, кайсылары кызыклы булмады?

**Имән бармак.** Сыйныфташларыгыз белән эш барышында уртак тел таба алдыгызмы? Кемнәргә булыштыгыз? Кемнәр сезгә булышты?

**Баш бармак**. Бүгенге дәрестә үзегезне ничек хис иттегез? Кайсы эш күп энергия таләп итте? Кайсы эш сезне ял иттерде?

**Үзбәя**

**Зәңгәр** – актив катнаштым, биремнәрне дөрес үтәдем. **Яшел** – актив булдым, ләкин биремнәрдә бераз хаталар чыкты.

**Кызыл** – әле миңа бик күп тырышырга, хаталарымны төзәтергә кирәк.

**V. Өй эше**

**Габдулла Тукайның «Театр» шигыреннән өзекне укы.**

Халыкка дәресе гыйбрәттер – театр,
Күңелдә йоклаган дәртне уятыр...
...Театр көлдерәдер, уйнатадыр,
Тагы үткән гомерне уйлатадыр...
...Тигез күрә бөтен җанны театр:
Кирәк кол бул, кирәксә – император...

**Биремнәр:**

1. Сүзләрне килеп чыгышы ягыннан тикшер.
2. Г.Тукайның «Театр» шигырендә кайсы телдән кергән сүзләр өстенлек итә?
3. Интернет чыганакларына мөрәҗәгать ит: шигырь ничәнче елда язылган? Шигырьдәге сүзләр әле дә кулланылыштамы? Нәтиҗә яса.

**Кулланылган әдәбият**

1. *Зарипова Г.Г., Мирдиянова Б.М.* Татарский язык. Культура речи: учебно-методическое пособие.
2. *Мирзаһитов Р.Х., Сәгъдиева Р.К., Хөснетдинов Д.Х.* Татар теле (кагыйдәләр, методик киңәшләр, анализ үрнәкләре, биремнәр). Абитуриентлар, укытучылар, студентлар өчен.
3. *Мирзаһитов Р.Х., Сәгъдиева Р.К., Хөснетдинов Д.Х.* Татар теленнән электрон кушымта.
4. *Шәкүрова М.М.* Туган тел (татар теле). 5 сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк: төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен)
5. https://suzlek.antat.ru/



8

# СЫЙФАТ ДӘРӘҖӘЛӘРЕН РӘСЕМ СӘНГАТЕ АША ӨЙРӘНҮ

*(6 нчы сыйныфта татар теленнән интеграцион дәрес)*

**Әлфия ИСРАФИЛОВА,**

Актаныш районы Чалманарат төп мәктәбенең I квалификация категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы

**Максат**

*Дидактик:*

– укучыларның сыйфат һәм сыйфат дәрәҗәләре турында белемнәрен системага салып үзләштерү, тирәнәйтү, гамәли куллана алуларына ирешү;

– танып белү активлыгын һәм мөстәкыйльлекне үстерү, сыйфат дәрәҗәләрен куллану, бәйләнешле сөйләм телен, грамоталы язу, төркемнәрдә бер-берсе белән киңәшләшеп эшләү, нәтиҗә ясау, бәяли белү күнекмәләрен камилләштерү.

*Үстерелешле:* анализлау, синтезлау, гомумиләштерү күнекмәләрен куллана белүне үстерү.

*Тәрбияви:* татар рәссамнарының иҗатына кызыксыну уяту; эстетик хисләр тәрбияләү.

**Универсаль уку гамәлләре**

*Танып белүдә:* сыйфат дәрәҗәләре, сыйфат сүз төркеме белән танышу.

*Шәхескә бәйле:* үзалдыңа максат кую, аңа ирешү юлларын эзләү;

– активлыкка, мөстәкыйль, иҗади фикер йөртергә, фәнни-тикшеренү эшчәнлеген башкару, шәхес буларак формалашуны дәвам итү;

– үзең алган белем күнекмәләрен тормышның төрле шартларында куллана белергә өйрәнү.

*Коммуникатив:*

– эзлекле сөйләм, диалог төзүдә һәм коллектив фикер алышуда катнашу;

– сыйныфташлары һәм укытучы белән уку эшчәнлеген оештыруда хезмәттәшлек итү;

– үз фикерен тулы һәм төгәл итеп әйтә белү;

– күмәк эш вакытында уртак фикергә килү;

– иптәшеңнең гамәлләрен бәяләү, күршең белән хезмәттәшлек итү.

*Регулятив:*

– дәреснең проблемасын (тема) һәм максатларын мөстәкыйль формалаштыру;

– максатка ирешү юлларын билгеләү;

– үз эшчәнлегеңнең нәтиҗәле булуына ирешү, үз эшчәнлегеңне контрольгә алу;

– кагыйдә, күрсәтмәләрне истә тоту һәм аларга ияреп гамәлләр кылу.

**Дәрес тибы:** яңа белемнәрне ныгыту, туплау.

**Эшчәнлекне оештыру төрләре:** фронталь, шәхси эш, төркемнәрдә эшләү.

**Ресурслар һәм җиһазлау:** «Сыйфат», «Сыйфат дәрәҗәләре» таблицалары, туп, алма предметлары, рәсемнәр, слайдлар, тема буенча презентация, ноутбук, экран, Илдар Зариповның «Миләш», «Кунаклар килде», «Март ае», Усман Абдулловның «Сабантуй» картиналары.

**Дәрес барышы**

| Дәрес этаплары | Укытучы эшчәнлеге | Укучы эшчәнлеге |
|---|---|---|
| **I. Дәресне оештыру, мотив-лаштыру** | Уңай психологик халәт тудыру.<br>– Хәерле көн, укучылар! Кәефләрегез ничек? Укучылар, сез, бүген иртән торгач, тәрәзә янына килеп, урамга, кояшка, күккә карадыгызмы? Кемнәр һәр иртә шулай табигатькә соклана?<br>– Яхшы, укучылар, димәк, сез иртән иртүк гүзәллек белән, табигать белән күрешеп аралашырга өлгергәнсез! | –Хәерле көн! Укучыларның җаваплары:<br>– Мин тәрәзәгә карадым.<br>– Мин кояшка күз йоммыйча карап тордым.<br>– Мин кошларны күзәттем.<br>–Мин болытларны карадым, алар ап-ак иделәр һ.б. |

| | | |
|---|---|---|
| **II. Белемнәрне акту-альләштерү** | Узган дәрестә өйрәнгән сыйфат дәрәҗәләрен искә төшерү өчен бирем.<br>Беренче укучы көн турында гади итеп сөйләргә тиеш.<br>Икенче укучы көн турында матур, эчтәлекле, сурәтләү чараларына бай итеп сөйли. | Такта янына ике укучы чыга һәм бүгенге көн турында сөйлиләр.<br>Беренче укучы көн турында гади итеп сөйләргә тиеш.<br>Икенче укучы көн турында матур, эчтәлекле, сурәтләү чараларына бай итеп сөйли.<br>Класс бәя бирә, чагыштыра һәм сүзнең сыйфат турында барганлыгын нәтиҗә итеп китереп чыгара.<br>Икенче укучы көн турында сөйләгәндә, сыйфатларны күп куллана.<br>Сорауларга тулы, эзлекле җаваплар бирәләр, нәтиҗәләр ясыйлар. |
| | **Бирем.** Сорауларга җавап бирергә:<br>– Сыйфат нәрсә ул?<br>– Сыйфатның нинди дәрәҗәләре бар? | Класс сыйфатның нинди сүз төркеме икәнен аңлаталар, аның дәрәҗәләрен билгелиләр.<br>Укучылар җавабыннан соң интерактив тактада кагыйдә чыга. |
| **III. Уку мәсьә-ләсен кую** | 1. Табигать күренешләре белән презентация кушыла.<br>– Укучылар, мин иртән көннең нинди икәнлеген каравыгыз белән юкка гына кызыксынмадым. Табигать ул – рәссам. Бүген көн кояшлы, иртәгә болытлы. Болытлар – ак, йөзәләр. Җил исә, бүген талгын булса, иртәгә көчле булырга мөмкин.<br>Уен уйныйбыз һәм фикерләр белән уртаклашабыз. | «Сүзләрне үз урыннарына кую» уены уйнала.<br>**Гади дәрәҗә:** *тыныч, суыграк, нык җылы, иң кызу, зәңгәр.*<br>**Чагыштыру дәрәҗәсе**: *кояшлы, катырак, бик көчле, явымлы.*<br>**Артыклык дәрәҗәсе**: *кызгылт, саргылт, озын, кыскарак.*<br>**Кимлек дәрәҗәсе:** *иң матур, бик зур, кечерәк, югарырак.*<br>Сорауларга тулы, эзлекле җаваплар бирәләр, нәтиҗәләр ясыйлар.<br>Укучылар сыйфатларның ясалышлары һәм мәгънәләрендә аерма булуын әйтәләр.<br>Җаваплар тыңланыла. |
| | – Укучылар, ничек уйлыйсыз, бүгенге дәреснең темасы ничек булыр? | – Без бүген сыйфат дәрәҗәләре буенча белемнәрне арттырабыз, ныгытабыз, өйрәнербез. |
| | – Без дәрестә үзебезгә нинди максат куярбыз икән? | – Сыйфат һәм дәрәҗәләре турында белемнәр үзләштерү, тирәнәйтү. |
| | – Алар арасында аерма бармы? | – Аерма бар. |

| | | |
|---|---|---|
| | – Сыйфат дәрәҗәләре ничек ясалган? | – Кушымчалар ярдәмендә. |
| | – Укучылар, ә сез нинди рәссамнарны беләсез?<br>– Без бүген рәссамнардан Илдар Зарипов, Усман Абдуллов белән танышырбыз.<br>Бу рәссамнарның исемендәге хәрефләргә сыйфатлар уйлап табыгыз һәм аларны сыйфат дәрәҗәләренә куегыз. | – Баки Урманче, Харис Якупов, Мәхмүт Усманов, Лотфулла Фәттахов.<br>И – иркен, иркенрәк<br>Л – ләйсән<br>Д – дөрес, дөресрәк<br>А – ачык, ачыграк<br>Р – рәхимсез<br>У – уңышлы, уңышлырак<br>С – сары, саргылт, сарырак<br>М – моңлы, моңлырак<br>А – авыр, авыррак<br>Н – начар, начаррак |
| **IV. Яңа белемнәрне ачу** | – Укучылар, менә без сезнең белән сыйфат дәрәҗәләрен өйрәнүне картиналар белән эшчәнлектә дәвам итәбез.<br>– Мин сезгә дүрт картина тәкъдим итәм, кемнең кайсы картина белән эшлисе килә, шунысын сайлагыз:<br>– Илдар Зариповның «Миләш», «Кунаклар килде», «Март ае» һәм Усман Абдулловның «Сабантуй» картиналары. | Укучылар картина буенча эшлиләр.<br>Класс дүрт төркемгә бүленә.<br>Һәр төркем картинага анализ ясарга әзерләнә.<br>Һәр төркем үзе сайлаган картина турында ике төрле итеп сөйләргә әзерләнә:<br>Бер төре – сөйләм эзлекле, матур, эчтәлекле, күп итеп сыйфатлар кулланып сөйләү.<br>Икенче төр – сыйфатлар кулланмыйча сөйләү.<br>Ике төр сөйләмне чагыштыру, нәтиҗәләр ясау. |
| **Ял вакыты** | «Төсләр ни сөйли?» уены уйнала.<br>– Укучылар, сезгә хәрәкәтләрне төсләр белән билгеләргә кирәк. Нинди хәрәкәтне нинди төс белән билгеләр идегез? | Кызыл – йөгерү.<br>Зәңгәр – йөзү.<br>Сары – кулларны өскә күтәрү.<br>Яшел – кулларны аска төшерү.<br>Күк – җил кебек тирбәлү.<br>Кара – чүгәләү. |
| **V. Белемнәрне беренчел ныгыту** | – Сезгә кушымчалар бирелә, аларны сыйфат дәрәҗәләре белән тоташтырырга кирәк. | Пазллар формасында карточкалар бирелә:<br>бер өлешенә сыйфат дәрәҗәләре язылган, икенче өлешенә кушымчалары. |

| | | |
|---|---|---|
| | – Илдар Зариповның «Миләш» картинасы кайсы ел фасылы турында?<br>«Кунаклар килде» картинасы кайсы ел фасылы турында?<br>– «Март ае» картинасы кайсы ел фасылы турында?<br>– Усман Абдулловның «Сабантуй» картинасы кайсы ел фасылына карый?<br>– Укучылар, картиналарның уртак һәм аермалы якларын билгеләгез. | – Көз.<br><br>– Кыш.<br><br>– Яз.<br><br>– Җәй.<br><br>Укучылар сөйләм телен шомарталар:<br>картиналарны чагыштырып уртак һәм аерылып торган якларын билгелиләр – сыйфат дәрәҗәләрен кулланалар.<br>Картиналарның эстетик, тәрбияви ягын билгелиләр. |
| **VI. Яңа белемнәрне системалаштыру** | – Укучылар, сез хәзер шагыйрьләр һәм рәссамнар командаларына бүленәсез. Һәр команда тагын дүртәр төркемгә бүленә һәм бер теманы алып рәсем ясый. Шагыйрьләр шулай ук дүрт төркемгә бүленә. | Картинаны ясагач чагыштыралар. Картинаны ясау барышында шагыйрьләр һәр төркемнең эшен күзәтә һәм картина буенча сыйфат дәрәҗәләре кертеп, бер куплет шигырь яза, лирик хикәя яза – 5 җөмлә, табышмак чыгара – бер, ике, өч яки дүрт юлдан торган, юмористик хикәя яза – 5 җөмлә. |
| **VII. Рефлексия. Дәрескә йомгак** | **Мөстәкыйль эш.**<br>Бүгенге дәрестә алган белемнәр буенча нинди кагыйдәләр язарга була, шул кагыйдәләрне дәфтәргә язып куярга. | Мөстәкыйль эш эшлиләр – бүгенге дәрестә нинди белем алдылар, шул белемнәр буенча нинди кагыйдәләр бар, шуларны дәфтәргә язып куялар. |
| | – Дәрес башында нинди максат куйган идек? Без максатыбызга ирештекме? – Нинди файдалы мәгълүмат алдыгыз? Ул сезгә киләчәктә кирәк булырмы? | Укучылар җавабы тыңланыла. |
| | – Укучылар, сез үзегезнең дәрестәге активлыгыгызны ничек бәяләр идегез? | Укучылар үзләренә сыйфат дәрәҗәләрен кулланып бәя бирәләр. |

| | | |
|---|---|---|
| | – Укучылар, иптәшләрегезгә нинди бәя бирер идегез? Кайсыгызга кемнең җаваплары бик ошады? Бәяләү өчен нинди төсләр кулланыр идегез? | Укучылар теләк буенча иптәшләренең активлыгына бәя бирәләр һәм төс белән билгелиләр. Сыйфат дәрәҗәләрен кулланалар. |
| **VIII. Өй эше** | – Үзегез теләгән татар рәссамының картинасына карап, төрле дәрәҗәдәге сыйфатлар кергән бәйләнешле текст язарга. | Игътибар белән тыңлыйлар. Өй эше аңлашылмаса сорыйлар. |
| | – Укучылар, дәрес тәмам, афәрин! | |

**1 нче төркем** өчен картина –
И.Зарипов. «Кунаклар килде».



**3 нче төркем** өчен картина –
И.Зарипов. «Март ае».



**2 нче төркем** өчен картина –
И.Зарипов. «Миләш».



**4 нче төркем** өчен картина –
У. Абдуллов. «Сабантуй».



9




# ТЕАТР ЯКТЫЛЫККА, НУРГА ИЛТӘ

*(Г.Камалның «Беренче театр» әсәренә анализ)*

**Фирдәвес ГЫЙБАДУЛЛИНА,**

Лаеш районы Державино төп мәктәбенең югары квалификация категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы

**Максат**

*Дидактик:* укучыларны, әсәргә укытучы ярдәмендә анализ ясап, персонажларга һәм язучы осталыгына бәя бирергә өйрәтү.

*Үстерелешле:* укучыларның логик фикерләү сәләтен, иҗади активлыкларын, мөстәкыйльлекләрен үстерү.

*Тәрбияви:*

– үзара дустанә мөнәсәбәт булдыру, эшлекле рәвештә аралашырга өйрәтү;

– туган якның танылган шәхесләренә хөрмәт хисе уяту, милли үзаңны үстерү, тырышлык тәрбияләү.

**Дәреснең көтелгән нәтиҗәләре**

*Шәхескә кагылышлы:* укуга карата теләк-омтылыш, җаваплы караш булдыру.

**Метапредмет нәтиҗәләр**

*Предмет:* әсәргә укытучы ярдәмендә анализ ясап, персонажларга һәм язучы осталыгына бәя бирү күнекмәләрен формалаштыру, иҗади фикерләүне үстерү.

*Танып белүдә***:**

– нәтиҗәләр чыгару, гомумиләштерү;

– үз фикереңне исбатлый һәм яклый белергә күнектерү.

*Коммуникатив:*

– иптәшеңне тыңлый, ишетә белү, ишеткәнне үз фикерең белән чагыштыру, фикереңне тулы һәм төгәл итеп әйтә белү;

– төркемнәргә берләшү, бер фикергә килә белү.

*Регулятив:* укытучының күрсәтмәләрен истә тоту һәм аларга ияреп гамәлләр кылу.

**Предметара бәйләнеш:** тарих.

**Дәрес тибы:** белемнәрне ныгыту дәресе.

**Эш төрләре**: төркемнәрдә, парларда, фронталь, индивидуаль.

**Укыту методлары һәм алымнары:** өлешчә эзләнүле, күрсәтмәле.

**Җиһазлау:** дәреслек (Ганиева Ф.Ә. Әдәбият. 6 сыйныф), таратма материал, презентация.

**Дәрес барышы**

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру этабы**

Уңай психологик халәт тудыру.

**II. Уку мәсьәләсен кую**

*(Г.Тукайның «Театр» шигыреннән өзек укыла. Язмада.)*

Халыкка дәрсе гыйбрәттер театр,
Күңелдә йоклаган дәртне уятыр.
Театр яктылыкка, нурга илтә,
Кире юлга җибәрми, уңга илтә.
Театр көлдерәдер, уйнатадыр,
Тагы үткән гомерне уйлатадыр,
Күрерсең анда үз хәлең, көлерсең.
Көлерлек булса, булмаса – еларсың.
Тигез күрә бөтен җанны театр:
Кирәк кол бул, кирәксә император.

**Укытучы**. Дәреснең темасы нинди булыр?

**Укучылар.** Г. Камалның «Беренче театр» әсәрен анализлау. ***(****Дәреснең максаты ачыклана.)*

**Укытучы.** Без дәрестә ни белән шөгыльләнәчәкбез? *(Төркемнәрдә, анализ ясап, персонажларга бәя бирергә, әсәрнең сюжетын кыскартып сөйләргә, әсәрдән үзебезгә кирәкле сыйфатлар алырга.)*

**III. Уку мәсьәләсен чишү**

Төркемнәрдә бирем үтәү.

**Бирем.** Әлеге вакыйгалар кайсы елларда булган?

Г.Тукай туган, Г. Камал туган, татар театры оешкан ел.

1906 ел, 1886 ел, 1879 ел. *(Җаваплар тикшерелә.)*

**Укытучы.** Әйе, укучылар, татар театрының туган көне итеп 1906 елның 22 декабре санала.

– Без укыган әсәрдә сүз нәрсә турында барды?

**Көтелгән җавап.** Беренче тапкыр татарча театр уйнала.

– Әсәрнең сюжетын сөйләтү.

– Кыскартып сөйләтү.

– Бер җөмлә белән генә әйтергә. *(Әсәрдә яңалык белән искелек көрәшә.)*

– Рольләргә бүлеп уку. *(Алдан әзерләнгән татар костюмнары киелә.)*

1 нче төркемнән ике укучы Вәли һәм Гафифә диалогын укый.

2 нче төркемнән ике укучы Гафифә һәм Хәбибрахман диалогын укый.

3 нче төркемнән ике укучы Хәмзә бай һәм Биби диалогын укый.

**Төркемнәрдә эшләү**

1 нче төркем – Вәли һәм Факиһәгә хас сыйфатларны язарга.

2 нче төркем – Хәбибрахман һәм Гафифәгә хас сыйфатларны язарга.

3 нче төркем – Хәмзә байга хас сыйфатларны язарга. *(Җаваплар тыңланыла.)*

**Укытучы.** Биби турында нәрсә әйтә аласыз? *(Төркемнәрдә фикер алышалар. Җавап бирү барышында бер төркем икенчесен тулыландыра.)*

**Укытучы.** Узган дәрестә без әлеге спектакльдән өзек карап киткән идек. Ул өзектә Биби ролен кем башкарды?

**Көтелгән җавап.** Артистка Фирдәвес Әхтәмова.

**Укытучы.** Әйе, бу рольне Татарстанның халык артисты, якташыбыз Фирдәвес Әхтәмова башкара. Шушы роле аны артистка буларак таныта. Соңгы роле А. Гыйләҗев әсәре буенча куелган «Бибинур» исемле фильмда Бибинур ролен башкара. Менә шушындый кызыклы факт.

**1 нче төркемнән бер укучы** *(Ф.Әхтәмова турында сөйли).* Якташыбыз – танылган артистка Ф. Әхтәмова 1939 елның 21 июлендә Яушыйк авылында гади генә гаиләдә туа. Әтисе Каюм абзый сугышның беренче көннәреннән үк фронтка китә, озак та үтми үлгән хәбәре килә. Фирдәвес өченче сыйныфта укыганда, әнисе дә үлеп китә. Ятим калган кызны абыйсы үзе белән Казанга алып китә. Ул укуын Г. Ибраһимов исемендәге татар мәктәбендә дәвам итә. Ф. Әхтәмова, мәктәптә укыган вакытта ук, үзешчән сәнгатьтә катнаша. Аны Рәшидә Җиһаншина күреп ала һәм театр училищесына укырга килергә чакыра.

1956 елда Мәскәүдәге Щепкин исемендәге театр училищесына укырга керә. 1961 елны аны уңышлы тәмамлап, Г. Камал театрына эшкә килә. Гомеренең соңгы көннәренә кадәр шул театрда хезмәт итә.

Ф. Әхтәмованы тамашачы Биби ролен (Г. Камал. «Беренче театр») оста итеп башкарган артистка буларак хәтерли.

**Укытучы.**Театр артистлары турында сөйләгәндә, үзебезнең авылдан чыккан Фирдәвес Хәйруллина турында да искә төшермичә мөмкин түгел. Кабинетта аңа багышланган стенд бар. Тагын кайда аның турында белә алабыз?

**Көтелгән җавап.** Авыл музеенда аның спектакльдә киеп уйнаган күлмәге саклана.

**Укытучы.** Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты Ф. Хәйруллинаның бала чагы турында сөйләргә сүзне 2 нче төркемгә бирәбез.

**2 нче төркемнән бер укучы.** Ямьле Мишә буенда урнашкан Агайбаш авылында Зәйнәп апа белән Хабул абый гаиләсендә 1951 елның 4 гыйнварында бер кыз бала дөньяга килә. Аңа җәннәт бакчасы мәгънәсен аңлатучы Фирдәвес дигән исем кушалар. Кышкы салкын көннәрнең берсендә дөньяга килсә дә, бик нечкә күңелле, йомшак табигатьле кыз булып үсә.

Беренче сыйныфка укырга Державино мәктәбенә керә. Ул вакытта авыл халкы Агайбаштан Державино авылына күчкән була. Сыйныфташлары арасында ул

тырышлыгы, белемгә омтылуы белән аерылып тора. Бу мәктәптә ул өч сыйныф кына укып кала. Аларның гаиләләре Казанга Мирный бистәсенә күчеп китә. Казанга киткәннән соң да, ул җәйге каникулларда авылга кунакка кайтып йөри.

Мәктәптә укыган елларда Ф. Хәйруллина татар теле һәм әдәбияты дәресләрен ярата. 5 нче сыйныфта укыганда, татар теле укытучысы аларны театрга алып килә. Ул көнне театрда «Татар хатыны нилә̄р күрми» дигән спектакль уйнала. Спектакль Ф. Хәйруллинага бик нык тәэсир итә. Тамаша беткәч тә, ул урыныннан селкенми, буш залда берүзе утырып кала. Шуннан ул артистка булырга хыяллана башлый. Урта мәктәпне тәмамлауга, театр училищесына укырга керә. Аны уңышлы тәмамлый.

**3 нче төркемнән бер укучы** *(Ф. Хәйруллина белән артистка буларак таныштыра).* 1970 елда ул, Казан театр училищесын тәмамлап, театрга эшкә килә. Чирек гасырдан артык татар халкына хезмәт итә. Шаян күңелле яшь кызлар ролен дә, катлаулы кичерешле хатын-кыз образларын да уйнарга туры килә аңа.

Кайчандыр театрга гашыйк иткән «Татар хатыны нилә̄р күрми» спектаклендә ул баш героиня – Гөлбану ролен башкара. Бер-бер артлы кызыклы рольләр китә: «Ир-егетләрдә» – Сайра, «Монда тудык, монда үстек»тә – Нурания, «Ташкыннар»да – Гөлчирә, «Кияү белән кәләш»тә – Кәләш. Алар бик күп. Ф. Хәйруллинаның татар сәхнәсе түрендә үз урыны бар иде. Ул образларына үз хисләре, үз кичерешләре аша җан өрә, рухы аша үткәрә, аларны үз халәте, үзенең аңлавы белән баета, уңай һәм тискәре геройлар арасында идеаль төгәллек эзли.

**Укытучы.** Укучылар, районыбызның әлеге танылган шәхесләре ничек шулай зур уңышларга ирештеләр икән? Төркемнәрдә уйлашабыз.

**Көтелгән җавап.** Аларның икесе дә талантлы, тырыш, икесе дә әлеге профессияне үзләштерү өчен белем алалар, хезмәтләрен яратып башкаралар. Халыкка хезмәт итәләр.

**Парларда эшләү**. Бирелгән сүзләрдән хезмәт турында мәкаль төзергә. Сүзләрне дөрес тәртиптә куярга.

*Хезмәтенә күрә хөрмәте.*
*Эш – кешенең көзгесе. Эш сөйгәнне ил сөйгән. Агач – җимеше белән, адәм – эше белән. Хезмәт төбе – хәзинә. Хөрмәт сөйсәң, хезмәт сөй.*

**Укытучы.** Яңадан үзебез өйрәнә торган әсәргә әйләнеп кайтыйк. Әсәрдә каршылык кемнәр арасында бара? Конфликт нидә? Әлеге сорауларга төркемнәрдә җавап әзерлибез. *(Җаваплар тыңлана. Нәтиҗә ясала.)*

**IV. Рефлексия**

Уку мәсьәләсенә кайту, аны искә төшерү.

– Дәрестә нәрсә эшләргә тиеш идек?

– Бу эшне ничек башкардык?

**Үзбәя.** Укытучы төркемнәр һәм укучылар эшенә бәя бирә.

**V. Өйгә эш**

**1 нче вариант.** Әсәрдән бер образга характеристика язарга.

**2 нче вариант.** Татар телендә «Беренче театр» буласын хәбәр итеп белдерү язарга.

*Гөлүсә Закирова фотосы*

10



# МОНОЛОГИК ҺӘМ ДИАЛОГИК СӨЙЛӘМ ҮСТЕРҮ БИРЕМНӘРЕ

*(Проект эше. Татар теле. 4 нче сыйныф. Рус төркеме)*

**Гөлшат ЗАРИПОВА,**

Казандагы М.С.Устинова исемендәге
102 нче гимназиянең
I квалификация категорияле
татар теле һәм әдәбияты укытучысы

Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә укучыларның иҗади эшләү сәләтләрен үстерү, балада чит телне өйрәнүгә теләк уяту – укытучының төп максатларыннан берсе. «Тел дигән дәрья бар, төбендә энҗе-мәрҗән бар, белгәннәр чумып алыр, белмәгәннәр коры калыр», – дип, бик белеп әйткән зирәк халкыбыз. Чыннан да, тел дәрьясының гаҗәеп кыйммәтле, хикмәтле хәзинәсен эзли, таба, күрә белергә өйрәтү бик мөһим.

Хәзерге шартларда сыйфатлы белем бирү төп бурыч булып тора. Ә рус телендә сөйләшүче балалар белән эшләүче татар теле укытучыларының төп бурычы – укучыларны татарча аралашырга өйрәтү, татар теленә хөрмәт тәрбияләү, бу телнең дәүләт теле буларак әһәмияте зур булуына төшендерү.

Милли мәктәптә рус телен өйрәтүне диалогик һәм монологик сөйләмнән башларга кирәк, дигән фикергә кушылып, без дә рус балаларына татар телен чит тел буларак укытуны сөйләм эшчәнлегенең нәкъ менә шушы төренә өйрәтүдән башлап җибәрергә кирәк дип саныйбыз.

Тел һәм сөйләм материалын тиешле дәрәҗәдә җиткерә белү шушы телне билгеләнгән күләмдә өйрәнүгә, белүгә китерә. Укучы алган белемне һәм формалашкан күнекмәләрне төрле аралашу ситуацияләрендә кулланырга сәләтле була башлый. Шулай итеп, өйрәнелә торган телдә информация алу һәм аны тапшыруга бәйле коммуникатив бурычларны хәл итү мөмкинлеге туа.

Мәктәптә диалогик һәм монологик сөйләм белән эшләгәндә, 4 нче сыйныф укучыларының яшь үзенчәлекләрен күрә белеп эш итү, укучыларга җиткерү өчен нәтиҗәле методик алымнар, чаралар куллануны таләп итә.

Рус балаларына татар теле укытуның **төп максаты** – аларны бу телдә сөйләшергә, тыңлап аңларга, укырга һәм язарга, сүзләрне дөрес әйтә белергә өйрәтү, сүз байлыгын арттыру. Моның өчен тиешле шартлар булдыру – укытучының мөһим бурычы.

**Проект эшебезнең максаты** – татар теле дәресләрендә рус телендә сөйләшүче укучыларның татар телендә аралашу осталыгын үстерү күнегүләренең әһәмиятен күрсәтү.

Максатыбызга ирешү өчен түбәндәге бурычлар куелды:

– диалог һәм монолог эш төренең укыту барышында тоткан ролен ачыклау;

– татар теле дәресләрендә диалогның күнегүләр системасында тоткан урынын ачыклау.

Укыту процессында рус телле укучыларны татар телендә аралашырга өйрәтү гаять катлаулы, шуңа күрә без рус телле укучыларга татар телен өйрәтүнең уңай юлларын тәкъдим итәргә булдык. Югарыда китерелгән фикерләр проект эше темасының актуальлеген дәлилли.

**Тикшеренү объекты** – рус телендә сөйләшүче укучыларның диалогик һәм монологик сөйләмгә өйрәтүдә дәреслекләр, уку-укыту әсбаплары, заманча технологияләрне чагылдыручы фәнни-тикшеренү чыганаклары.

**Тикшеренү предметы** – монологик һәм диалогик сөйләмгә өйрәтүдә коммуникатив технологияләр .

**Метод һәм алымнар.** Өйрәнелә торган материалның характерына карап, тикшеренүнең төп методы булып *күзәтү методы* сайланды. Әлеге метод үз эченә фәнни һәм

методик әдәбиятны туплау һәм анализлау, фактик материалны өйрәнү, педагогик тәҗрибәне гомумиләштерү, классификацияләү кебек эш алымнарын берләштерә.

**Проектның фәнни-гамәли әһәмияте**

Проект эшендә өйрәнелгән, тикшерелгән эш алымнары һәм эш нәтиҗәләре укыту процессында рус балаларына татар телен өйрәткәндә кулланыла ала.

**Проектта катнашучылар**: татар теле һәм әдәбияты укытучылары.

**Көтелгән нәтиҗәләр**. Без тәкъдим иткән эш төрләре татар теле дәресләрен нәтиҗәле һәм мавыктыргыч итәчәк. Алар ярдәмендә рус телле укучылар тел материалын тизрәк һәм яхшырак үзләштерәчәк.

**Рус телле балаларны монологик һәм диалогик сөйләмгә өйрәтү максаты һәм бурычлары**

Рус телендә сөйләшүче балаларны, татарча сөйләшергә өйрәткәндә, диалогик сөйләмгә өйрәтү зур урын алып тора. Билгеле булганча, телдән сөйләмнең ике формасы: диалогик һәм монологик формалары бар. Диалогик сөйләм киңрәк таралган. Телнең аралашу функциясеннән чыгып, диалогик сөйләмне төп һәм әйдәп баручы төр дип атый алабыз. Рус мәктәбенең башлангыч сыйныфларында татарча телдән сөйләмгә өйрәтүне диалогик сөйләмнән башлау дөресрәк.
Ни өчен шулай? Беренчедән, сөйләмнең башка формалары белән чагыштырганда, диалог киңрәк таралган. Икенчедән, аның өстенлекләре дә байтак: ул гадирәк һәм кыскарак төзелә. Чит тел өйрәнә башлаган балага, шул телдә бәйләнешле текстлар төзүгә караганда, сораулар бирү, я шуларга җавап бирү җиңелрәк.

Татар сөйләменең тышкы яңгырашы ике төрле: диалогик һәм монологик формада була. Диалог ул – ике яки берничә әңгәмәдәшнең кара-каршы сөйләшүе. Һәр әйтелгән сүз башка затларның җавабына бәйле. Диалогта бик күп ким җөмләләр, ситуатив характердагы әйтелмәләр, еш кына сорау, өндәү җөмләләр кулланыла. Яңгыраучы сөйләмнең әлеге формасы паралингвистик алымнар белән дә баетылган.

Телне өйрәнүчеләр тел һәм сөйләм компетенциясенә ия булырга тиешләр. Алар:

1) көнкүреш темалары буенча ирекле аралаша алырга, сөйләмне грамматик дөрес төзергә һәм әңгәмәдәшләрнең сөйләмен тулысынча аңларга һәм аның белән ирекле аралашырга;

2) бирелгән ситуация буенча татар этикетына караган тәгъбирләр кертеп, диалоглар төзи белергә;

3) бирелгән темага фикер туплап, телдән һәм язмача монологик текст төзи белергә;

4) дәреслектәге диалоглар һәм текстларны тулысынча аңлап укырга.

**Укучыларны диалогик һәм монологик сөйләмгә өйрәтүдә кулланылган эш төрләре**

Диалогик сөйләмгә өйрәтү һәрбер дәрестә дә булырга тиеш. Барлык лексик-грамматик материал диалоглар һәм аралашу ситуацияләре аша үзләштерелә. Беренче дәресләрдән үк укучылар татар теленә генә хас булган диалогик сөйләм үрнәкләре, аларда кулланылган этикет формулалары белән таныша. Һәр дәрестән соң аларның бу төр күнекмәләре арта бара, чөнки үрнәк диалог, аралашу

ситуацияләре аша бу эш нәтиҗәле оештырыла.

Диалог белән эшләү этабында түбәндәге биремнәрне тәкъдим итәргә мөмкин:

**1. Укылган текстның эчтәлеге буенча диалог төзү.**

*Менә 1 нче сентябрь җитте. Балалар мәктәпкә баралар. Укытучы апалар балаларны каршы ала. Бүген көн бик матур. Мәктәптә күңелле музыка уйный. Балалар бик шат, чөнки алар дуслары, укытучылар белән очраштылар.*

– Бүген көн нинди?
– Бүген 1 нче сентябрь.
– Сиңа бу көн ошыймы?
– Әйе, миңа бу көн бик ошый. Мин бик шат.

**2. Терәк сүзләр һәм рәсемнәр буенча диалоглар төзү.**



**Терәк сүзләр:** *әлбәттә, юк, бик, теләп, чөнки, шуңа күрә.*

**3. Бирелгән үрнәк буенча яңа ситуатив диалог төзегез.**

Твоя мама больна. Ты ухаживаешь за мамой. Предложи ей лекарство.

**Үрнәк:**
– Әни, мә дару.
– Спроси, надо ли ей лекарство.
– Спроси, нет ли у неё температуры.
– Предложи ей чай.
– Предложи чай с мёдом.

**4. Бирелгән үрнәк буенча яңа диалог төзегез.**

**Үрнәк:**
– Сиңа математика дәресе ошыймы?
– Әйе, бик ошый.
– Математика дәресендә нәрсәләр эшлисез?
– Без математика дәресендә мисаллар эшлибез, мәсьәләләр чишәбез, саныйбыз, бүләбез.

**Темалар:** а) Татар теле дәресендә. ә) Физкультура дәресендә.

**5. Рәсем буенча раслау яки инкяр итүче сүзләрне кулланып, диалог төзү.**



**6. Диалогик сөйләмне монологик сөйләмгә әйләндерегез.**

**–** Сиңа нинди ел фасылы ошый?
– Миңа кыш айлары ошый.
– Ни өчен?
– Чөнки кыш көне – минем туган көнем. Тагын мин тимераякта шуарга яратам.
– Ә сиңа нинди ел фасылы ошый?
– Миңа җәй ошый, чөнки каникуллар.

*(Укучылар, шушы диалогтан чыгып, «Минем яраткан ел фасылым» дигән темага хикәя төзергә тиеш.)*

Диалогик сөйләмгә өйрәтү белән беррәттән укучыларның монологик сөйләм күнекмәләрен үстерүгә дә игътибар итәргә кирәк. Моның өчен һәр дәрестә диярлек өйрәнелгән лексик-грамматик материалга нигезләнеп, үрнәк текстлар кулланам.

Текст дәрәҗәсендә укучыларның монологик сөйләм күнекмәләрен үстерүгә игътибар аеруча зур булырга тиеш, чөнки бу очракта гына алар теге яки бу темага карата

эзлекле рәвештә фикер йөртергә, мөнәсәбәтләрен белдерергә, бәя бирергә, дәлилләргә өйрәнәләр.

**7. Укытучы теманы тәкъдим итә һәм уйлар өчен вакыт бирә.** *(Укучылар шул темага туры килгән сүзләр яза, сүзләр кабатланырга тиеш түгел. Соңыннан шул сүзләрне кулланып, хикәя төзиләр. Тема. Шөгыльләр.)*

**8. Н.Максимовның «Сөйләм калыпларына нигезләнеп, татар теленә өйрәтү технологиясе» буенча эш төре.**

**Бәхетле көн**

Дуслар, бүген нинди көн,
Сез беләсездер, бәлкем?
Белмәсәгез, үзем әйтәм:
Бүген минем туган көн!

Шулай итеп, без татар теле дәресләрендә кулланылучы эш төрләрен карадык. Алар – барысы да рус балаларын аралашырга өйрәнү юлында актив кулланылырга тиешле биремнәр. Бу биремнәр сөйләмне яхшыртуга гына юнәлдерелмәгән. Алар зуррак мәгънәгә дә ия. Рус балаларына татар телен өйрәтүдә биремнәрнең төрлелеге әһәмиятле, алар үзләштерелүче материалны һәм чит телне өйрәнү процессын җиңеләйтә. Күргәнебезчә, сөйләм эшчәнлегенең төрләренә өйрәтүдә кулланыла торган язу күнегүләренең төрләре күп булса да, укытучыдан аларны иҗади сайлау сорала. Телдән актив рәвештә үзләштерелмәгән лексик-грамматик материалны дөрес язуны таләп итүнең мәгънәсе юк. Иң беренче чиратта укучыларны сөйләшергә өйрәтеп һәм параллель рәвештә аларның язу күнекмәләрен үстерү генә тел белүне камилләштерә. Аралашу вакытында укучылар күптөрле лексик-грамматик материалны, реплика төрләрен, сөйләм этикеты үрнәкләрен кулланырга мәҗбүр булалар. Бу очракта сөйләм эшчәнлегенең төрләре дә үзара тыгыз бәйләнешкә керә. Сөйләм эшчәнлегенең төрләренә өйрәтү тыгыз бәйләнештә оештырылырга тиеш. Укыту процессында кулланылган барлык күнегүләр, эш төрләре укучыларның тел күнекмәләрен генә түгел, фикерләү сәләтен, хәтерен, игътибарын да үстерә.

| **Кайчан?** | **Кем?** | **Кемгә?** | **Нәрсә?** | **Нишләде?** |
|---|---|---|---|---|
| Туган көнем<br>җиткәч<br>Туган көнемдә | әтием<br>әнием<br>әбием<br>апам<br>абыем һ.б. | миңа | машина<br>курчак<br>китап<br>телефон | бүләк итте. |
| Туган көнеңдә | әтиең<br>әниең<br>әбиең<br>апаң<br>абыең һ.б. | сиңа | | бүләк итте?<br>бүләк иттеме? |
| Туган көнендә | әтисе<br>әнисе<br>әбисе<br>апасы<br>абыйсы һ.б. | аңа<br>Маратка<br>Оляга | | бүләк иттеме?<br>бүләк иткәнме? |

11



# СИНГАРМОНИЗМ ЗАКОНЫ

*(Рус мәктәпләренең 5 нче сыйныфында татар теле)*

**Резеда САБИРОВА,**

Саба районы Шәмәрдәндәге «Үсеш» лицееның югары квалификация категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы

**Максат**

*Белем бирүдә:* татар теленең фонетикасы, сингармонизм законы турындагы белемнәргә ия булып, дөрес сөйләм оештыра һәм язуда дөрес куллана белү.

*Фикерләү сәләтен үстерүдә:* укучыларның сораулар куя белү, анализ һәм нәтиҗә ясый белү кебек фикерләү сәләтләрен үстерү, үз фикерләрен дөрес һәм матур итеп әйтүләрен камилләштерү, уртак эшчәнлекне үстерүгә ирешү.

*Тәрбияви:* фәнни танып белүнең кыйммәтен аңларга омтылыш уяту, табигатьне һәм табигатьтәге җан ияләрен саклау һәркемнең изге бурычы икәнлеген төшендерү, хезмәт эшчәнлеге нәтиҗәләренә хөрмәт хисе һәм әхлак сыйфатлары тәрбияләү.

**Дәреснең тибы**: яңа материалны өйрәнү.

**Көтелгән нәтиҗәләр**

***Предмет нәтиҗәләре:*** сингармонизм законын телдән һәм язма сөйләмдә куллана белү, сингармонизмга буйсынмаган сүзләрне тану күнекмәләрен булдыру, рәт һәм ирен гармониясенә буйсынган сүзләрне аерырга өйрәнү.

***Метапредмет нәтиҗәләр:***

*Регулятив:* дәреснең темасын, максатын мөстәкыйль таба белү; үз фикереңне дәлилләү; үзеңнең эш-гамәлләреңә үзгәреш кертү, үзеңнең һәм иптәшеңнең фикерен дөрес бәяли алу, сөйләм ситуациясен анализлап, башкаларның теләк-ниятләрен аңларга тырышу.

*Танып белү:* мәгълүмат белән эшли белү: сингармонизмга буйсынмаган сүзләрне мөстәкыйль рәвештә аерып ала белү, логик фикер йөртеп, сингармонизм законының ике төре буенча төркемнәргә, ягъни рәт һәм ирен гармониясенә бүлә белү, нәтиҗә чыгарырга өйрәнү; мәгълүматны системалаштыру һәм истә калдыру.

*Коммуникатив:* әңгәмә барышында тема буенча сораулар бирү һәм дустанә аралашуны саклап, үз фикерләреңне җиткерә белү; уртак эшчәнлекнең максатын кабул итү һәм аңа ирешү.

*Шәхескә кагылышлы:* дәрестә алган белемнәрне тормышта кулланырга өйрәнү, тикшеренү эшчәнлегенең төп күнекмәләренә ия булу, әйләнә-тирәгә зыян китерә торган эш-гамәлләрне кабул итмәү, бер-береңә һәм кеше хезмәтенә карата ихтирам, хөрмәт хисе тәрбияләү.

**Метод һәм алымнар:** әңгәмә, эзләнү-тикшеренү.

**Эшне оештыру төрләре**: фронталь, индивидуаль, төркемнәрдә һәм парларда эшләү.

**Җиһазлау:** электрон дәреслек: Туган тел (татар теле). 5 сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк: төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен). / М.М.Шәкүрова, Л.М.Гыйниятуллина, О.Р.Хисамов; [рәссамы Д. Нәүрузова]. – Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2022. – 172 б. : рәс. б-н; компьютер, смарт такта, презентация, рәсем, карточкалар: «Сингармонизм законына буйсынган һәм буйсынмаган сүзләрне аерып языгыз».

**Дәрес барышы**

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру**

**1. Дәресне оештыру.**
Исәнләшү, укучыларның хәлләрен сорашу, психологик уңай халәт тудыру.

**Укытучы.**
Хәерле көннәр дип эндәшәм
Һәммәгезгә мин сезгә.
Матур көннәр, яхшы кәеф
Телимен һәрберегезгә.

– Укучылар, бүген көн нинди? *(Дежур укучының чыгышы.)*

**Укытучы.** Әйе, укучылар, бүген көн болытлы, җилле, салкынча. Көзен бакчадагы бәрәңгеләрне җыеп алдык. Быел бәрәңге уңышы ничегрәк? Без дә бәрәңгене җыеп алдык. Тик, балалар, минем бәрәңгеләрне аермаган бит әле. Миңа ярдәм итмәссезме икән? Без аны нинди төрләргә аерабыз әле? Әйе, утырту бәрәңгесе, эре һәм вак бәрәңге.Тик минем бәрәңгеләрем тылсымлы, алар – сүзләр төзергә ярдәм итә торган авазлар.




Менә шул авазларны, сортларга аерып, капчыкларга тутырырга булышыгыз әле. Эшкә тотынганчы, кайбер кагыйдәләрне искә төшереп китик.

**II. Актуальләштерү**
1. Өй эшенең үтәлешен тикшерү: кагыйдәләрне искә төшерү. *(Экранда сораулар чыга.)*

– Нәрсә ул аваз? Нинди авазлар була? Татар телендә ничә сузык аваз бар? Алар нинди төрләргә бүленә?

Хәзер, парлашып, минем «серле бәрәңгеләр»емне үз капчыкларына тутырыйк әле. *(Беренче пар – арткы рәт, 2 нче пар – алгы рәт, 3 нче пар иренләшкән сузыкларны аера, 4 нче пар тактада **https://learningapps.org/** сайтында интерактив тактада эшли. Сылтамасы: https://learningapps.org/watch?v=p6qghywp522 )*

– Рәхмәт, менә сез нинди яхшылык эшләдегез. Яхшылыгыгызны истә тотармын. «Яхшылык эшләсәң, ул үзеңә кире кайтыр», – ди татар халык мәкале.

**III. Уку мәсьәләсе кую**

**Укытучы.** Димәк, укучылар, бүген безнең сөйләшү темасы нинди булыр, ягъни нинди темага сөйләшербез? *(Яхшылык турында.)*

– Нәрсә ул яхшылык? *(Җаваплар тыңланыла.)* Яхшылык эшләү җиңелме, балалар? *(Кемгәдер бик җиңел, ә кем өчендер ай-һай авыр...)*



– Экранга күз салыйк әле. Бу нинди әкият дип уйлыйсыз? Авторын беләсезме? (*Экранда «Өч кыз» әкиятеннән рәсемнәр бирелгән. «Логик чылбыр» буенча эчтәлекне искә төшерү.)*

– Әлеге әкият нәрсә турында дип уйлыйсыз? *(Минемчә, бу әкият яхшылык эшләү турында.)*

– Бу әкияттә кемгә яхшылык эшләү авыр, ә кемгә җиңел? *(Олы һәм уртанчы кызга яхшылык эшләү авыр, ә кече кызга һәм тиенгә җиңел.)*

– Балалар, әлеге әкият нәрсә турында уйланырга мәҗбүр итте? *(Әниләр – иң кадерле кешеләр, аларны рәнҗетергә ярамый. Һәрвакыт сүзләрен тыңларга, ярдәм итәргә кирәк һ.б.)*

**IV. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү**

**Укытучы.** Әйе, укучылар, кешеләргә, аларга гына түгел, ә барлык җан ияләренә ярдәм итәргә кирәк. Әйдәгез әле, тиеннең сүзләренә игътибар итик. *(Экранда түбәндәге җөмләләр чыга.)*

«И бала, гомер буе игелек күр, кешеләрне бәхетле ит, аларга куаныч бул. Кешеләр дә сиңа ихтирамлы булыр, синең яхшылыгыңны беркайчан да онытмаслар!»

**Сүзлек өстендә эш:** *игелек* – изгелек, яхшылык (доброта), *ихтирам* – хөрмәт (уважение), *куаныч* – сөенеч, шатлык (радость).

– Әйдәгез, шушы җөмләләрдән алгы рәт һәм арткы рәт сузыклардан гына торган сүзләрне язып алыйк. (*Вариантларда эш: 1 нче варианттагылар – алгы рәт сузык авазлардан торган сүзләрне, 2 нче вариантлар арткы рәт сузык авазлардан торган сүзләрне язып ала.)*

Эшләрне алмашабыз һәм тикшерәбез.

**Алгы рәт сузыклардан торган сүзләр:** игелек, күр, кешеләрне, бәхетле, кешеләр.

**Арткы рәт сузыклардан торган сүзләр:** бала, буе, булыр, яхшылыгыңны, онытмаслар.

**Нәтиҗә ясау.** Димәк, беренче рәттә – нечкә сузыклардан, ягъни алгы рәт сузыкларыннан гына торган сүзләр. Сузык авазлар бер-берсенә нечкәлектә ярашып килгәннәр. Икенче баганада калынлыкта ярашканнар, охшашканнар. Бу – сузыклар гармониясе дип атала. Икенче төрле сингармонизм законы. Димәк, сузыкларның я калынлыкта, я нечкәлектә ярашуы сингармонизм законы дип атала.

– Ике рәттән төшем килешендәге сүзләрне табыгыз әле. *(Кешеләрне, яхшылыгыңны.)*

– Нинди кушымчалар ялганган? *(Берсенә – нечкә, берсенә калын кушымча ялганган.)*

– Димәк, укучылар, кушымчалар сингармонизм законы нигезендә ялгана.

– Кабат экранга карыйк әле. Кайсы сүзләрне язып алмадыгыз? Ни өчен? Димәк, нинди сүзләр сингармонизм законына буйсынмый?

*Беркайчан* – кушма сүз.

*Ихтирам* – алынма сүз.

*Сиңа* – алмашлык, юнәлеш килешендә.

– «Яхшылык эшләү – матур гадәт» җөмләсендә сингармонизмга буйсынмаган сүз бармы? Ни өчен? (*Җаваплар тыңланыла.)*

**Нәтиҗә ясау.** Димәк, сингармонизм законы бары тик әйтелешкә карый.

**V. Белемнәрне беренчел үзләштерү**

1. Дәреслектә бирелгән текстны уку.

**Укытучы.** Ә хәзер дәреслектәге 20 нче күнегүгә күз салыйк. Сезгә «Аучы карт» тексты бирелгән, иң элек текстны рольләргә бүлеп укыйк

әле. *(Текстны рольләргә бүлеп уку.)*

– Балалар, текст нәрсә турында? *(Бабасының оныгына яхшылык эшләргә теләве турында.)*

– Бабай яхшылык эшләү өчен нинди гамәл башкарырга тиеш? *(Болан баласын алып кайтырга.)*

– Сезнеңчә, бу яхшылыкмы, әллә начарлыкмы? *(Минемчә, бабай оныгына яхшылык эшлим дип, боланга начарлык эшләячәк.)*

– Димәк, балалар, берәүгә яхшылык эшлим дип, башкаларга зыян китерү дә мөмкин икән.

2. «Сорау-җавап» уены.

**Укытучы**. Инде текст эчтәлеге буенча «Сорау-җавап» уены уйнап алыйк. *(Укучылар бер-берсенә:* «*Азат, әйт әле, аучы кем белән яшәгән? Асия, Миңлегәрәй нәрсә турында хыяллана?» кебек сораулар бирә.)*

3. Эзләнү эше башкару.

**Укытучы.** Укучылар, ә хәзер кечкенә генә эзләнү эше башкарып алырбыз. Сезнең максат: тексттан сингармонизм законына буйсынмаган сүзләрне табу һәм ни өчен буйсынмавын аңлату. (*Әлеге бирем төркемнәрдә башкарыла һәм бергәләп тикшерелә.)*

– Нинди сүзләрне язып алдыгыз? *(Бервакыт, Бикхуҗа, сиңа, сүзләре.)*

– Нәтиҗә ясап, нинди кагыйдә чыгарабыз инде?

– Димәк, сингармонизм законы саклансын өчен, сүздә я калын, я нечкә сузыклар гына булырга тиеш.

4. Ял минуты. (*Сыйныф бүлмәсенең диварларына сүзләр язылган кәгазь битләре эленгән, укучылар сингармонизмга буйсынган сүзләрне генә табып киләләр: бөтен, онык, гомер, табигать, экран, ашханә, бәхет*.)

5. Шул сүзләрне транскрипциядә язу. *(Укучылар тактада эшли.)*

[бөтөн] [онокъ] [гъөмөр] [бәхэт]

– Беренче иҗектә нинди сузык аваз? *(Алгы рәт, иренләшкән [ө] авазы.)*

– Икенче иҗектә нинди аваз ишетәбез? *([ө] авазы.)*

– Димәк, икенче иҗектә дә иренләшкән сузык ишетәбез. Сүзнең беренче иҗегендә иренләшкән [о], [ө] сузыклары булса, икенче һәм башка иҗекләрдәге [ы], [э] авазлары урынына [о], [ө] сузыклары әйтелә: [болот], [көмөш]. Бу күренеш ирен гармониясе дип атала.

Сингармонизм законының ике төре бар: рәт гармониясе һәм ирен гармониясе. Ирен гармониясе нинди сузыкларга карый? *(Дәреслектәге кагыйдәне уку һәм нәтиҗә ясау.)*

**Нәтиҗә:** ирен гармониясе [о] һәм [ө] сузыкларына карый. Беренче иҗектә [о] яки [ө] ишетелсә, икенче һәм аннан соңгы иҗекләрдә дә [о] яки [ө] ишетелә. Рәт гармониясе нечкә һәм калын сузыкларга карый. Беренче иҗектә нечкә яки калын сузык аваз булса, калган иҗекләрдә дә нечкә яки калын сузык ишетелә.

**VI. Яңа белемнәрне ныгыту**

1. Карточкалар белән эшләү.

**Укытучы.** «Яхшылык эшләү – матур гадәт», дидек. Әйдәгез, кабат бер изгелек эшләп алыйк әле. Безнең аучы Бикхуҗа карт оныгына болан баласы алып кайтырга дип чыгып китте. Ләкин ул барасы юлда «ташлар» ята. Юл кырыенда «чокырлар». Ташларны шул чокырларга алып ташларга

кирәк. Әлбәттә, «ташлар» язулы, «чокырлар»ның да исемнәре бар. Шул ташларны урыннарына алып куярга ярдәм итик инде. *(Укучыларга карточкалар таратыла, парларда эшли.)*

*Бер пар такта янында https://learningapps.org сайтында интерактив тактада эшли. Сылтамасы: https://learningapps.org/watch?v=pk0ow70zn22.)*

2. Рәсем буенча биремнәр э**шләү.**

**Укытучы**. Безнең аучы, юлдан бара-бара, болынга килеп чыкты. Ул нәрсәләр күрде икән? Рәсемгә карап, рәт һәм ирен гармониясенә буйсынган бишәр сүз уйлап әйтегез әле. *(Яфрак, үлән, аяк, чәчәк, агач. Болыт*, *болын, колын, төлке, койрык.)*

– Инде шул сүзләр белән бер-берсе белән бәйләнешле җөмләләр төзеп карыйк. *(Күктә ак болытлар йөзә. Болында колын йөгереп йөри. Агачлар янында кызыл төлке күренә. Болында төрле төстәге чәчәкләр үсә. Колынның койрыгы кечкенә.)*

– Укучылар, шушы рәсемгә карап, нинди яхшы гамәлләр эшләп була? (*Җаваплар тыңланыла. Мәсәлән, аучы күрмәсен дип, төлкене куркытырга. Төлке колынга тимәсен өчен, колынны куып җибәрергә.)*

**VII. Рефлексия**

1. Рефлексив кабатлау.

**Укытучы.** Укучылар**,** бүгенге дәрестә сез никадәр игелекләр кылдыгыз: миңа, аучы картка, бер-берегезгә ярдәм иттегез. Тик, балалар, бүгенге дәрестә безнең Азат катнаша алмады, ул авырып киткән. Әйдәгез, аңа шалтыратып, бүгенге дәрестә ниләр белүебезне җиткерик әле. *(Укытучы шалтырата (бу – уен формасында да, реаль дә булырга мөмкин) һәм балалар сыйныфташларына дәрестә өйрәнгәннәрне сөйлиләр.)*

**Укучылар.** Без бүген «Сингармонизм законы» дигән теманы өйрәндек. Сузык авазларның я калынлыкта, я нечкәлектә ярашуы сингармонизм законы дип атала. Аның ике төре бар. Ирен гармониясе [о], [ө] сузыкларына карый. Сингармонизм законы әйтелешкә генә карый, язылышка карамый. Кушма һәм алынма сүзләр законга буйсынмый.

**Укытучы.** Рәхмәт, балалар. Азат та бик канәгать калгандыр. Ә сингармонизм законы тормышта кирәкме? Ничек уйлыйсыз? *(Укучылар җавабы.)*

**Укытучы.** Әйе, сингармонизм законы телдән һәм язма сөйләмебезне камилләштерә. Без әлеге закон нигезендә авазларны, сүзләрне дөрес әйтеп, сөйләмебезне үстерәбез һәм сүзләрне дөрес язарга өйрәнәбез.

2. Белемнәрне бәяләү.

Укучыларга, дәрестә катнашканнарын бәяләп, билгеләр куела.

**VIII. Өй эше**

1. 16 нчы күнегү. Мәкальләрне туры китерергә, сингармонизмга буйсынмаган сүзнең астына сызарга.

2. «Хәйләкәр әтәч» әкиятеннән ирен гармониясенә 10 сүз язып алырга.

3. Иҗади эш. «Әгәр дә сез сингармонизм законы булсагыз, үзегез белән ничек таныштырыр идегез?»

12



# ЯЛГЫЗЛЫК ҺӘМ УРТАКЛЫК ИСЕМНӘР

*(Татар мәктәбенең 5 нче сыйныфы өчен татар теле дәресе)*

**Рания ГОМӘРОВА,**

Апас районы Апас урта мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы

**Максат:**
***Дидактик:***
*укыту-өйрәтү максатлары:*
– ялгызлык һәм уртаклык исемнәр төшенчәсе өстендә эш;
– ялгызлык һәм уртаклык исемнәрне дөрес билгели белү;
– ялгызлык исемнәрне дөрес язу;
*белем-күнекмәләрне үстерү-камилләштерү (актуальләштерү) максаты*: «Исем» темасы буенча белемнәрне камилләштерү.
***Психологик:***
– мөстәкыйль һәм төркемнәрдә эшли белүләрен, үз-үзләренә бәя куя белү күнекмәләрен үстерү;
– дустанә мөнәсәбәтләрне формалаштыру.
***Тәрбияви:***
– китапка карата мәхәббәт, сакчыл караш, пөхтәлек тәрбияләү;
– танылган, бөек шәхесебез белән горурлану хисе уяту.
**Җиһазлау:** дәреслек, мультимедиа системасы, тест, үзләштерү дәрәҗәсен тикшерү өчен махсус кәгазь битләре.
**Дәрес тибы:** уку мәсьәләсен кую һәм чишү.
**Дәрес барышы**
**I. Ориентлашу-мотивлаштыру этабы**
Дәрескә әзерлекләрен тикшерү.
**Укытучы.**
Хәерле көн телик барчабызга,
Аяз күкләр телик җиребезгә,
Яхшылыклар телик һәр кешегә,
Һәм иминлек телик җиребезгә.
**Укытучы.** Барчабызга да, яхшы кәефләр теләп, халкыбызның бөек шагыйре Габдулла Тукай юллары белән дәресебезне башлыйбыз.
**Укытучы.** Бөек шагыйребез укучыларына нәрсә әйтергә тели? *(Укучыларның җаваплары тыңланыла.)*
**Нәтиҗә.** Белемле булыр өчен китапны яратырга, хөрмәт итәргә һәм күп укырга кирәк.
**Укытучы.** Хәсән Шабанов шигыре белән дә танышып китик әле.
**Укытучы.** Бу шигырьгә сез нинди исем куяр идегез? Фикерегезне дәлилләгез.
– Автор шигырен «Анам сүзләре» дип атаган. Ни өчен?
**II. Актуальләштерү**
**Укытучы.** Бирелгән сүзләрне ике төркемгә бүлеп языгыз. *(Төркемнәрдә эшләнелә.)*
***Бакчалар, койма, урманнар, мәктәп, елгалар, яшьләр, көннәр, җил, төннәр, ашлыклар, җирләр, вакыт, кырлар, укучы.***
*(Төркемнәр бер-берсенә бәя куя.)*
**Укытучы.** Нинди нәтиҗә ясый аласыз? *(Исемнәр берлек һәм күплек саннарда була.)*
**Укытучы.** Нигә *кыр* сүзе күплектә *-лар* кушымчасы алган, ә *төн* сүзе – *-нәр*? Нинди нәтиҗә ясый аласыз?
**Нәтиҗә.** Татар телендә борын авазларына (м, н, ң) беткән исемнәргә күплектә *-нар/-нәр* кушымчалары ялгана.
**III. Уку максатын кую**
**Укытучы.** Слайдта бирелгән текстны карыйк.
**Укытучы.** Кайсы исемнәр дөрес язылмаган? *(Укучылар текстагы хаталарны төзәтә.)*
Без 5 нче сыйныфта укыйбыз. Минем **Лилия, Роза** исемле дус кызларым бар. Беркөнне без **Миләүшә апа** белән чәчәк бакчасына бардык. Без анда **миләүшә, роза, лилия чәчәкләре** күрдек.
**Укытучы.** Ни өчен бер үк язылышлы исемнәр кайсы баш хәрефтән, кайсысы юл хәрефеннән языла икән?
– Роза исемле кыз ничәү? *(Берәү.)*

– Роза чәчәге ничә? *(Роза чәчәкләре күп.)*

**Укытучы.** Кызларны бер-берсеннән исемнәре белән аерабыз. Ничек атыйбыз бу исемнәрне? Башлангыч сыйныфта сез бу теманы үткәнсез. Бәлки искә төшерерсез? *(Ялгызлык исемнәр.)*

**Нәтиҗә.** Ялгызлык исемнәр бертөрле әйберләрнең берсен атый, башкаларыннан аера, ә уртаклык исемнәр барысын да белдерә.

**Укытучы.** Дәресебезнең темасы нинди булыр? *(Ялгызлык һәм уртаклык исемнәр.)*

– Теманы үзләштерү өчен нинди максатлар куяр идегез? *(Ялгызлык, уртаклык исемнәрне аера белү һәм аларны дөрес язу.)*

**III. Белемнәрне адымлап үзләштерү этабы**

1. Уку максатына ирешү өчен яңа теманы өйрәнү алгоритмын төзү.

**Укытучы.** Беренче бирем. Төркемнәрдә эшләячәкбез. *(Илһам Шакиров башкаруында җыр яңгырый.)*

**Укытучы.** Текст кем турында? *(Халкыбызның танылган җырчысы Илһам абый Шакиров турында.)*

**Укытучы.** Бирем. 1 нче төркем – уртаклык исемнәрне, 2 нче төркем ялгызлык исемнәрне яза.

| **Уртаклык исемнәр** | **Ялгызлык исемнәр** |
|---|---|
| татар | Илһам |
| дөньясы | Илһам Шакиров |
| горурлык | |
| исем | |
| җырчы | |
| кинолар | |
| шигырьләр | |
| җырлар | |
| елда | |

**Укытучы.** Бирелгән бер уртаклык, бер ялгызлык исемне шушы тәртиптә тикшереп карыйбыз.

татар (уртаклык исем)

Илһам (ялгызлык исем)

(*Илһам* кем? соравына җавап бирә, затны белдерә. Бер генә затны атый.

*Татар* кем? соравына җавап бирә, затны белдерә. Күп затларны белдерә.)

**Укытучы.** Әйдәгез, нәтиҗә чыгарып карыйбыз: нинди сүзләрне ялгызлык исемнәргә, ә нинди исемнәрне уртаклык исемнәргә керттек.

**Нәтиҗә.** Ялгызлык исемнәр – кешеләрнең, предметларның, күренешләрнең **берсенә генә** бирелгән исемнәр. Уртаклык исемнәр – бер төрдән булган предметларның **барысына** да бирелүче исем.

**Укытучы.** Димәк, нинди сүзләрне ялгызлык исемнәргә кертәбез? *(Кеше исемнәре, фамилияләр.)*

2. Уку максатына ирешү өчен күнегүләр системасы.

**Укытучы.** «Исемен тап» дип аталган бирем тәкъдим итәм. Һәрберегез биремне дәфтәренә язып башкара.

1) Якташыбыз, Г. Х. Андерсен исемендәге Халыкара Почётлы диплом иясе.

2) Туфан Миңнуллинның әсәре «Авыл эте... ».

3) Татарстанның башкаласы.

4) Апас районында иң зур елга.

5) Чәчәк исеме белән аталган Муса Җәлил шигыре.

6) Районыбыз газетасы.

7) Җәйнең беренче атналарында үткәрелүче милли бәйрәм.

**Укытучы.** Эталон буенча, бер-берегезнең эшен тикшереп, билге куясыз. *(Парларда бер-берсенә бәя куялар.)*

**Укытучы.** Димәк, ялгызлык исемнәргә нинди сүзләр керде?

**Нәтиҗә.** Кеше исемнәре, хайваннар кушаматы, географик атамалар, газета-журнал исемнәре, бәйрәм исемнәре.

**Укытучы.** Кайсы ялгызлык исемнәр куштырнаклар эченә алынган?

**Нәтиҗә.** Шигырь, газета-журналлар исемнәре куштырнаклар эченә алына.

**Ял минуты**

**Укытучы.** Дәреслектәге 129 нчы күнегүне эшлибез.

– Белгәннәрегезне тагын бер тапкыр ныгыту һәм тикшерү өчен **тест** эшләп алырбыз.

**Тест**

1. Ялгызлык исемнәр дип нинди исемнәргә әйтәләр?

а) кешеләрнең, бер төрдән булган предметларның, күренешләрнең берсенә генә бирелгән исемнәргә;

ә) бер төрдән булган предметларның барысы өчен дә бирелгән исемнәргә.

2. Җөмлә эчендә ялгызлык исемнәр ничек языла?

а) юл хәрефеннән; ә) баш хәрефтән.

3. Ялгызлык исемнәрне тап.

а) урман, күл; ә) әни, дәфтәр;

б) Мәскәү, Идел; в) казан, савыт.

4. Түбәндә бирелгән сүзләрдән уртаклык исемнәрне тап.

а) Хәкимов, Зөя елгасы, Корбан бәйрәме, «Сабантуй» газетасы;

ә) фамилия, елга, бәйрәмнәр, күл, агач.

*(Тест аерым битләрдә эшләнелә һәм җыеп алына.)*

**IV. Рефлексия**

**Укытучы.** Дәрестә чыгарылган нәтиҗәләргә таянып, теманың моделен төзибез. *(Модельне төркемнәрдә төзиләр.)*

**Исем**

**Ялгызлык** ← → **Уртаклык**

***Ялгызлык исемнәр*** **–** кешеләрнең, күренешләрнең **берсенә генә** бирелгән исемнәр.

***Уртаклык исемнәр*** **–** бер төрдән булган предметларның **барысына да** бирелүче исем.

– исем, фамилияләр
– хайваннарның кушаматлары
– географик атамалар
– газета-журналлар
– мактаулы исемнәр
– бәйрәм исемнәре һ.б.

*(Крандагы модель белән чагыштырып, дөреслеге тикшерелә.)*

*(Үзләштерү дәрәҗәсен тикшерү битләре таратыла.)*

**Үзләштерү дәрәҗәсе**

| **№** | **Исемнәр** | **Үзләштерү** | |
|---|---|---|---|
| | | **Беләм** | **Кыенрак булды** |
| 1 | Исем | | |
| 2 | Ялгызлык исемнәр | | |
| **3** | Уртаклык исемнәр | | |

**V. Өй эше**

1. Әдәби әсәрдән, газета-журналлардан ялгызлык исемнәр кергән дүрт җөмлә табып язарга.

2. 131 нче күнегүне эшләргә.

13




# ДӘРЕСЛӘРДӘ ИННОВАЦИОН ТЕХНОЛОГИЯЛӘР КУЛЛАНУ

**Гөлназ КАМАЛОВА,**

Мамадыштагы академик К. Вәлиев исемендәге 2 нче лицейның югары квалификация категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы

Бүген укытучыдан бик күп нәрсә таләп ителә: үз фәненең бик яхшы белү, балаларны яратудан тыш, аларның фикерләү сәләтен үстерү, уку-танып белү эшчәнлеген оештыру, рухи һәм физик үсешен тәэмин итү. Ә моның өчен укытучыдан үз шәхесенә тәнкыйть күзлегеннән карау, яңалыкка омтылу, заман сулышын тоеп, белемне өзлексез камилләштерү, укыту-тәрбия процессына иҗади якын килеп эшләү сорала. Заман таләбе кушуы буенча, укучыларның компьютер технологияләренә булган кызыксынуларын истә тотып, «Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә инновацион технологияләр куллану» проектын тормышка ашыру өстендә эшлим. Проект эшемне академик Ә. Хуҗиәхмәтовның «Педагогик технологияләр» исемле фәнни эшенә нигезләнеп алып барам.

**Төп максатым**:

– белем сыйфаты белән идарә итү өчен төрле юллар һәм алымнар кулланып, киләчәктә илнең чын хуҗалары була алырлык белемле, акыллы, сау-сәламәт шәхес тәрбияләү.

**Бурычларым:**

– укучыларның белемгә булган омтылышларын үстерү; махсус белем һәм күнекмәләр формалаштыру; иҗади эшчәнлекне үстерү мөмкинлеген тудыру; укучыларның фикерләү сәләтен үстерү.

**Педагогик проектта катнашучылар:** укытучы, укучылар, ата-аналар,

**Проектны башкару вакыты:** 4 ел.

Ике ел эчендә «Татар теле һәм уку дәресләрендә инновацион технологияләр куллану» проекты буенча эш билгеле бер системага салынды. Ул параллель рәвештә дәресләрдә һәм сыйныфтан тыш эшләрдә тормышка ашырыла.

Шушы педагогик проект буенча үткәрелгән дәресләр уңай мотивация тудыра. Укучыларның танып белү эшчәнлеген активлаштыру һәм укучыларда уңай мотивация булдыру өчен төрле эш методлары һәм алымнары кулланып эшлим.

1. Уку материалын аңлатканда, сүз белән эшләү (сөйләү, сүзлек эше, әңгәмә һ.б.); гамәли методлар (күнегүләр, буклетлар, презентацияләр эшләү, электрон дәреслекләр чыгару) кулланам.

2. Фикерләү, уку эшчәнлеге белән идарә иткәндә исә проблемалы эзләнү методына (проблемалы сорау кую, проблемалы ситуация тудыру, үзаллы, парлы, төркемнәрдә эшләү, фәнни-тикшеренү эшләре) өстенлек бирәм.

Дәрестә дә, өй эше итеп тә эзләнү, тикшеренү, уйлану таләп иткән эшләр бирергә тырышам.

3. Уку эшчәнлеген активлаштыру өчен дәресләрдә эмоциональлеккә ирешү, танып белү уеннары, уңыш ситуациясе булдыру, үзара ярдәм оештыруны отышлы алым дип саныйм.

Эш ике юнәлештә алып барыла: дәрес вакытында халкыбызның телен, мәдәниятен, гореф-гадәтләрен, күркәм йолаларын, тарихи үткәнен теоретик яктан тирәнтен өйрәнсәк, сыйныфтан тыш эшләрдә иҗади эзләнү эшенә күбрәк игътибар бирәм. Шул рәвешле, балалар иркен, мөстәкыйль фикер йөртү дәрәҗәсенә ирешә.

Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә мәгълүмати технологияләрне куллануның өстенлекле яклары күп:

– материал югары күрсәтмәле дәрәҗәдә булуы белән отышлы;

– укучының шәхси сыйфатларын ачыкларга мөмкинлек була;

– контроль һәм үзконтроль

дәрәҗәсе югары;
– төрле дәресләрнең үзара бәйләнешен булдыру мөмкинлеге бар;
– укыту формаларын һәм ысулларын төрләндерү дәреснең эчтәлеген баерак һәм кызыграк итә.

Дәрес үткәргәндә, еш кына интерактив тактага мөрәҗәгать итәм, чөнки интерактив такта куллану дәресләрне тагын да мавыктыргыч, нәтиҗәле итә. Төрле темага күрсәтмә материаллар һәм укыту ресурсларын табарга һәм аларны кабат-кабат файдаланырга мөмкин. Бу алым укучыларның белем сыйфатын үстерергә, яңа материалны һәр укучыга җиңел, аңлаешлы итеп җиткерергә дә ярдәм итә.

Яңа стандартлар кертү сәбәпле татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә **проектлар методы**н куллану отышлы, чөнки бу метод – укучыларның билгеле бер нәтиҗәгә ирешүен максат итеп куя. Проектлар методы укучы шәхесенең белем алуга иҗади якын килүенә юнәлтелгән. Ул – теге яки бу проблеманы тирәнтен өйрәнү максатында, укытучы җитәкчелегендә эшләнә торган мөстәкыйль иҗади эш.

Проект методын куллануның уңай яклары:
1. Тел һәм әдәбият буенча материал белән таныштыру карала.
2. Укучы дәресләрдә төп белем ала, эш төрләре, кагыйдәләр белән таныша.
3. Бу метод кызыксынучанлыкны, һәр яңа эш төрен ихлас, дәртле итеп башкару теләген уята.
4. Проекттагы информация һәр дәрестә укучының күз алдында була, кирәк вакытта ул аңа мөрәҗәгать итә ала. Бу исә материалның хәтта йомшак укучылар тарафыннан да үзләштерелүен тәэмин итә.

Күпчелек очракта бу эш төркемнәрдә эшләнә һәм берничә этаптан тора.

**Проект өстендә эш этаплары:**
1. Проект темасын тәкъдим итү. Иҗади эшләрнең тематикасы дәрестә үзләштергән белемнәрне тирәнәйтү, актуальләштерү, гамәлдә куллануны таләп итәрлек итеп сайлана. Мәсьәлә кую.
2. Эш юнәлешен сайлау. Балаларны төркемнәргә бүлү. Информация җыю алымнарын сайлау һәм эзләнүне башлау. Беренче нәтиҗәләрне тикшерү.
3. Проектны презентацияләү, бизәү һәм яклау.
4. Йомгаклау, нәтиҗә чыгару.

Проект методикасы куллану түбәндәге бурычларны үти:
– Эш барышы телне өйрәнүгә теләк уята.
– Проект эшен оештыру барышында укучылар үзара аралаша, укытучы тикшерүче ролен түгел, киңәшче ролен үти.
– Укучыны билгеле бер тема өстендә иҗади эшләргә, төрле чыганакларны кулланып, үзаллы мәгълүмат табарга өйрәтә, уку эшчәнлеге активлаша.
– Бөтен уку процессы укучыга юнәлтелә, аның кызыксынуы, тормыш тәҗрибәсе, шәхси сәләтләре искә алына.

Гомумән, проектлау технологиясенең кулланылу даирәсе бик киң, аны дөрес һәм урынлы кулланганда (укытучы үзе кирәкле дип тапканда), укытучыга ышанычлы ярдәмче функциясен үти ала. Ә иң мөһиме шул: схема-проектны һәр дәрестә файдалану үзмаксат түгел, ә проект укучыларның белем алуда активлыгын тәэмин итү, предметка карата кызыксыну уяту, төпле белем бирү чарасы булуын истән чыгарырга ярамый.


Бүгенге көндә мәктәпләрдә төрле предметлардан компьютерлар өчен эшләнгән гамәли укыту программалары бар. Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә куллану өчен дә интерактив дәреслекләр чыгарыла башлады. Миндә видеоматериаллар карауның тәэсирен кабатлауның нәтиҗәле ягы белән берләштерү теләге туды. Һәм Movie Maker программасына нигезләнеп, «Сайланган сәхнә сынавы» проектын төзедем. Проект өчен 5 – 7 минутлык кыска гына өзек сайлап алына. Балаларга иң якын булган «Г.Тукай әкиятләре» темасын сайладык. «Кәҗә белән Сарык хикәясе», «Шүрәле», «Су анасы» әкиятләре буенча проектыбыз әзер инде. Гомумән, видеоязмалар карауның төрле алымнарын үз эшемдә кулланам. Мәсәлән, 5 – 7 минутлык өзекне алдан карау, аннан тавышны ябып кабатлау барышында укучылардан диалог төзетү яки, киресенчә, рәсемне аерып куеп, тавышка нигезләнеп, әсәрне уйнап күрсәтү. Әсәрнең өзеген карау барышында бирелгән язмадагы бер герой турында репортаж язу һ.б. Сөйләм телен үстерү дәресләрендә куллану өчен презентацион программалар бик кулай. Power Paint программасында укыган әсәргә иллюстрацияләр эшләргә, принтер аша чыгарып, һәр укучыга таратып та бирергә була. Бу эшләрне дә укучылар бик теләп башкара.
М. Җәлил, Г. Тукай, Г. Ибраһимов кебек шәхесләрнең тормышын, иҗатын өйрәнү дәресләре өчен эшләнгән презентацион программаларыбыз да бар.

Әлбәттә, сәләтле балаларга аеруча игътибар итәм. Бу эшнең әһәмияте – шәхеснең перспектив үсешен фаразлауда. Табигать тарафыннан бирелгән иҗат һәм сәләт чаткылары булган балаларны туплау һәм үстерү – төп бурычыбыз.

Мәктәп шартлары миңа дәресләрдә компьютерның мультимедиа мөмкинлекләреннән видеотехниканы уңышлы файдаланырга ярдәм итә. Кабинетым Интернет челтәренә тоташтырылган компьютер, принтер, сканер, медиапроектор белән җиһазландырылган. Ә бу мөмкинлекләр мине даими рәвештә укытуның яңадан-яңа алымнарын эзләргә этәрә. Укытуны интенсивлаштыру өчен тестларны нәтиҗәле кулланам. Укучыларның теманы үзләштерү дәрәҗәсен тикшерү, белемнәрен бәяләү, ялгышларын ачыклау, аларны анализлау һәм төзәтү юлларын билгеләү өчен тестлар бик уңайлы. Тестны эшләп бетергәч, компьютер, нәтиҗә ясап, билге куя. Укучылар үзләре дә төрле презентацияләр ясыйлар, белемнәрне тикшерү дәресләрендә файдалану өчен Excel, Point программасында тестлар әзерләүдә дә ярдәм күрсәтәләр. Татар теле дәресләре өчен басма күрсәтмә материаллар бик аз, шуңа күрә укучылар, Интернет челтәренә чыгып, татарча сайтлардан төрле кызыклы материаллар бастырып ала.

«Шәкертләрне гыйлем белән тәрбияләү, изге шәригатьтә аңлатылган күркәм холыклар белән таныштыру һәм гадәтләндерү – укытучының беренче эше булыр», – дигән Р. Фәхреддин. Бүгенге укучыларның төпле белем, яхшы тәрбия алырга тулы мөмкинлекләре бар. Безгә бары тик гыйлем алуга тырышлык, теләк һәм омтылыш тәрбияләргә кирәк. Безнең кулларда – балалар язмышы. Укучыларыбыз, Р.Фәхреддин теләгәнчә, бөтен яктан да үрнәк балалар булып үссеннәр һәм милләтебез горурланырлык шәхесләр булсыннар иде.

14



# ТАТАР ТЕЛЕНДӘ ҺӨНӘР АТАМАЛАРЫ

**Ләйсән ИБРАЕВА,**

Казандагы 167 нче урта мәктәпнең
югары квалификация категорияле
татар теле һәм әдәбияты укытучысы

Кешенең билгеле бер һөнәр вәкиле булуы – аның төп характеристикаларыннан берсе. Теләсә кайсы өлкәдәге терминнар күләм һәм сыйфат ягыннан даими үзгәреш кичереп тора. Бер терминнар искерә, кулланылыштан чыга, яңа төшенчәләргә атама булган яисә иске төшенчәләрнең эчтәлеген төгәлрәк ачып бирә торган яңа терминнар хасил була. Фән һәм техника, бизнес, хезмәт күрсәтү өлкәләре киңәюгә бәйле рәвештә бүгенге көндә күп кенә яңа һөнәрләр барлыкка килде, һәм шуның нигезендә татар теленә күпләгән яңа һөнәр атамалары керде. Мөгаен, якын киләчәктә кешеләрне һөнәр буенча атаучы тагын күп кенә яңа сүзләр барлыкка килер. Атамаларның гел үсештә булуы аларны өйрәнеп, тикшереп торуны сорый. Шуны истә тоткан хәлдә, без укучылар белән татар телендәге һөнәр атамаларына игътибар юнәлтергә тиешбез.

Һөнәр кешелек җәмгыятенең һәр этабында шәхеснең мөһим характеристикасы булып тора. Татар телендәге бүгенге көндә актив кулланыла торган һөнәр атамаларыннан *актёр, хакер, официант, риелтор* кебекләрне атап үтә алабыз. Шулай ук телебезгә соңгы елларда гына үтеп кергән яңа сүзләр саналган һөнәр атамалары да бар. Шулар рәтендә *блогер, ютубер, фрилансер* лексемаларын теркәп үтәргә мөмкин. Татар телендәге һөнәр атамалары кулланылу дәрәҗәсе ягыннан гына түгел, ә килеп чыгышлары ягыннан да төрле. Төрле тарихи элемтәләр нәтиҗәсендә телебезгә гарәп-фарсы (*мөхәррир*), рус (*врач*) телләреннән дә һөнәр атамалары үтеп кергән. Европа телләреннән, бигрәк тә инглиз чыгышлы алынмалар актив. Мисалга *фрилансер, риелтор* һ.б.ларны китереп үтә алабыз. Моннан тыш, телебездә латин (*секретарь, доктор*) теленнән үзләштерелгән һөнәр атамалары бар. Аерым очракларда, атаманың кайсы телдән керү мәсьәләсе бәхәсле. Әйтик, «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *инженер* сүзе француз теленнән дип күрсәтелсә, рус теленең универсаль сүзлеге аны латин сүзе дип таный.

Укучылар белән эзләнү нәтиҗәсендә түбәндәге фикергә килдек: татар телендә һөнәр атамалары арасында гарәп-фарсы телләреннән үтеп кергәннәре дә, рус-Европа телләреннән үзләштерелгәннәре дә бар. Сан ягыннан инглиз теленнән кергән атамалар күбрәк.

Яңа һөнәрләр барлыкка килгән саен, аларның атамаларын фәнни өйрәнү ихтыяҗы да алгы планга чыга. Телдә кулланылган атамаларны өйрәнү гаять мөһим, алар, гомумән, телдәге үзгәрешләр турында фикер йөртергә, киләчәктә тел үсешендәге аерым тенденцияләрне фаразларга мөмкинлек бирә.

15



# ӘМИРХАН ЕНИКИНЕҢ «ӘЙТЕЛМӘГӘН ВАСЫЯТЬ» ХИКӘЯСЕН ӨЙРӘНҮ

*(9 нчы сыйныфта татар әдәбияты дәресе)*

**Ләйсән БАҺАВИЕВА,**

Кайбыч районы Олы Кайбыч урта мәктәбенең I квалификация категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы

**Максат:**
– язучының биографиясен искә төшерү, әсәр өстендә эшләү; укучыларның иҗади һәм фәнни фикерләү күнекмәләре үсеше өчен шартлар тудыру; гореф-гадәт, йолаларга хөрмәт тәрбияләү.

**Бурычлар:**
– укучыларның фикерләү активлыгын, сөйләм телен үстерү; укучыларда УУГ (танып белү, регулятив, коммуникатив, шәхескә кагылышлы) формалаштыру.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**
*Шәхескә кагылышлы:* активлыкка, мөстәкыйль фикер йөртүгә, акыл һәм рухи эшчәнлеккә өйрәтү.

**Метапредмет нәтиҗәләре:**
*Регулятив УУГ:*
– мөстәкыйль рәвештә дәреснең проблемасын (тема) һәм максатларын формалаштыру; максатка ирешү юлларын билгеләү; укытучы белән бергәләп, үз эшен, иптәшләренең җавапларын бәяләү.
*Танып белү УУГ:*
– үзенә кирәкле мәгълүматны төрле формада бирелгән чыганаклардан туплау; үз фикерен дәлилләү.
*Коммуникатив УУГ:*
– төрле фикерләрне исәпкә алып эш итү; күмәк эш вакытында бер фикергә килә белү.

**Предмет нәтиҗәләре:**
– автор карашын, мөнәсәбәтен аңлау;
– укыган текст буенча сорауларга җавап бирү.

**Предметара бәйләнеш:** тарих.

**Җиһазлау:** дәреслек, компьютер, экран, проектор, PowerPointда презентация, Әмирхан Еники портреты, карточкалар, сүзлекләр.

**Эшчәнлекне оештыру формасы:** парлап, төркемнәрдә эш.

**Дәрес барышы**

**I. Оештыру**

**Укытучы.** Хәерле көн, укучылар! Хәерле көн, кунаклар!Хәерле эш көннәре теләп, бүгенге эш көнебезне дәвам итик.

Сәлам, дустым,
Хәлең ничек?
Мин сагындым
Син килдең.
Мин бик шат.

**II. Белемнәрне актуальләштерү**

**Укытучы.** Бүгенге дәресебезгә эпиграфы итеп «Учагыңда ут сүнмәсен» дигән сүзләрне алам. Ни өчен икәнен дәрес азагында фикерләрегезне әйтерсез дип уйлыйм.

– Укучылар, сез кайсы язучының биографиясен укып килдегез?
*(Әмирхан Еникинең.)*

**III. Танып белү эшчәнлеге.Фронталь эш**

**Укытучы.** Яраткан язучыбызның тормыш юлы ничек үтте икән? Моны ачыклар өчен даталар буенча күзәтү үткәреп алыйк. *(Даталар тәкъдим ителә.)*

**Укытучы.** Күргәнегезчә, язучы озын гомер юлында төрле сынаулар аша үткән. Бөек Ватан сугышында катнашуы гына да үзе ни тора! Туган туфракны, җирне ярату аңа тормыш тәҗрибәсе аша килгән. Ямьле Дим буенда үскәнгәме, ул табигатьне, туган илен яраткан. Иҗатының тематикасы: авыл, сугыш, туган туфрак, йолалар.

Ә хәзер сезнең игътибарга видеотасма тәкъдим итәм. *(Видеоязма тыңлыйлар.)* Әйтегез әле, видеотасма белән безнең бүгенге дәресебез арасында нинди бәйләнеш булыр икән?

**Укучы.** Уйлавымча, без бүген Ә. Еникинең «Әйтелмәгән васыять» әсәрен тикшерәчәкбез, Акъәби турында фикер алышачакбыз.

**Укытучы.** Әйе, Булат, син хаклы. Барыгыз да әсәр белән таныш, тулы вариантын да укып чыктыгыз.

– Нәрсә соң ул васыять? *(Укучылар җавабы.)*

– Ә ни өчен әсәр «Әйтелмәгән васыять» дип атала? *(Укучылар җавабы.)*

**IV. Уку эшчәнлеген чишү. Парларда эш**

**Укытучы.** Укучылар, ә сезгә әсәрне укыган вакытта аңлашылмаган сүзләр очрамадымы?

**Укучылар.** *Кәфенлек* сүзе.

**Укытучы.** Тексттан әлеге сүз турында барган урынны табып укыйк әле. *(«Һай, кәфенлегемне оныткамнмын бит!» – диде әни кеше. «Куйсана, әсәй!» – диде кыз.)*

– Ни өчен Гөлбикә әнисенең борчылуын аңламый? *(Чөнки кыз үз милләтенең йолаларын белми, оныткан.)*

– Әйе, бу бик кызганыч. Тагын башка аңлашылмаган сүзләр булмадымы?

**Укучылар.** Кылганнар.

**Укытучы.** Моңа җавапны сез сүзлекләрдән таба аласыз.

– Укучылар, Акъәби шәһәргә килә. Биредә оныклары белән очрашу ничек үтә, алар ничек сөйләшәләр? Искә төшерегез әле.

**Укучылар.** Кызлар, әбине сырып алып: «Здравствуй, дорогая бабушка!» – дип күрешәләр. Папаларына мама тиешле әби – карчык.

**Укытучы**. Монда нинди мәсьәлә күтәрелә?

**Укучылар.** Туган телне белмәү.

**Укытучы.** Укучылар, ни өчен әбинең исеме Акъәби? *(Укучылар җавабы.)*

– Ә сезнең шундый әбиләрегез бармы? *(Укучылар җавабы.)*

– Әбинең өс-башы нинди*? (Рәсем чыга.)* Алъяпкычына игътибар итегез әле, бу бит милли киемнең бер элементы. Бөрмә-бөрмә тегелгән, изүе чигүле.

– Ә болар ни? *(Элгечтә милли киемнәр эленгән.)* Әлбәттә, милли киемнәр. Сезгә боларның бары да таныш.

– Әйтегез әле, Акъәбинең сандыгынданиләр бар иде соң? *(Укучылар җавабы.)* Калпак бүрек – ул ни? Ничек ясала? Җавапны шулай ук сүзлекләрдән таба аласыз.

– Бүген сезгә калпак бүрекне күреп тә, тотып та карау бәхете елмая.

– Тагын сандыгында ниләр бар иде? *(Хәситә. Аны да күрсәтү мөмкинлеге табылды.)* Боларның барысы да – милли киемнәр, безнең рухи байлыгыбыз.

**Ял минуты**

**Укытучы.** Хәзер урыннарыбыздан торабыз һәм диварга беркетелгән рәсемнәр янына барып басуыгызны сорар идем. *(Йорт, чулпы.)*

– Ралинә, ни өчен син чулпы рәсемен сайладың?

– Булат, ә син нишләп йорт рәсемен сайларга булдың? *(Барысы да үз фикерләрен әйтеп чыга.)*

– Яхшы. Фикерләрегез кызыклы, шул ук вакытта урынлы да дип саныйм.

– Ә хәзер мин сезгә парларда эшләргә эш тәкъдим итәм. Моның өчен мәкальләр таратып чыгам, ә сез аны аңлатып китәргә тиеш буласыз. *(Җаваплар.)*

**V. Рефлексия**

**Укытучы.** Янәдән эпиграфка кайтыйк әле. Учакта ут сүнмәс өчен без ниләр эшләргә тиеш? Моның өчен учак рәсеме төшкән кәгазь битләренә фикерләрегезне язып, безгә укып, тактага беркетүегезне сорыйм. *(Җаваплар.)*

**VI. Өй эше**

**Укытучы.** Укучылар, өй эше итеп сезгә сайлап алу мөмкинлеге белән өч бирем бирелә.

1. 107–108 нче битләрдәге сорауларга җавап бирергә.
2. Әсәрнең планын төзергә.
3. Акъәбинең балаларына үз исемеңнән хат язарга.

Ә хәзер, кулга-кул тотынышып, күңел түреннән чыккан җылылыкны бер-беребезгә өләшеп, әби-бабаларыбыз кабызган учак гел балкып, җылытып торсын, буыннар арасында бәйләнеш өзелмәсен дигән теләктә дәресебезне тәмамлыйбыз. Игътибарыгыз, дәрестә актив булганыгыз өчен рәхмәт.

16



# ӘНГАМ АТНАБАЕВ ӘСӘРЛӘРЕНДӘ ТУГАНЛЫК ХИСЛӘРЕ, ГАИЛӘ КЫЙММӘТЛӘРЕ

**Валентина САЛИКИЕВА,**

Казандагы 169 нчы урта мәктәпнең татар теле һәм әдәбияты укытучысы

**Люция КОРБАНОВА,**

Казандагы 169 нчы урта мәктәпнең татар теле һәм әдәбияты укытучысы

Бу тема, балалар тәрбияләгәндә, мөһим бер урын алып тора. Язучыларның әсәрләре, шагыйрьләрнең шигырьләре аша без туганлык хисләре, гаилә кыйммәтләренең кеше өчен нинди урын алып торганын балаларга җиткерергә тырышабыз.

Дәрестән тыш тәрбия сәгатьләрендә Әнгам Атнабаевның иҗатын өйрәндек. «Атнабай» дигән китапны алып, шигырьләренә күзәтү ясадык.

Ә. Атнабаевның әсәрләре бик күптөрле, үзенчәлекле, тәрбияви. Автор шигырьләрендә лирик геройның эчке хис-тойгыларын, күңел түрен бай итеп күрсәтә. Шигырьләр кешеләрнең күңеленә үтеп керә, уйландыра, үткән көннәрнең төрле мизгелләренә алып керә, йөрәк түрендә урын ала.

Аның шигърияте бай, җор телле. Нинди генә шигырен алып укысаң да, милләте белән горурланып язганы күренә. Ул бервакытта да татарлыгыннан курыкмаган. Бу аның иҗатында чагылыш таба.

Шагыйрь зур талант иясе булу өстенә, үз халкының сөекле һәм тугры улы да иде. Башкортстанда татарча язу һәм үз әсәрләреңне сәхнәләрдән ана телендә уку хупланмаган элекке елларда да Әнгам Атнабаев бары тик татар телендә генә иҗат итте һәм шигырьләрен дә фәкать татар телендә генә яңгыратты. Үзенчә бер каһарманлык билгесе бу.

Туганлык хисләренең мәңге саклануы, җылы мөнәсәбәт, әти-әнигә ихтирам, аларны олылау – боларның барысы да мәңгелек тема. Бу темага мөрәҗәгать итмәгән бер генә язучы да, шагыйрь дә юктыр ул. Бу темалар бүгенге көндә дә актуальлеген югалтмый, киресенчә, кискенләшә генә бара.

Заман үзгәрә, заман белән кешеләр дә үзгәрә. Хәзерге вакытта тормышта байлык, акча күбрәк урынны ала. Кешеләрнең, туганнарның, хәтта бер гаилә әгъзаларының да бу проблемага карашлары төрле булуы мөмкин. Менә шуннан инде гаилә таркала, гаилә кыйммәтләре югала. Бүгенге тыныч, мул тормышта үзләренең газиз балаларын ташлап калдырган әниләр бар. Шулай ук күз нурларын түгеп үстергән әти-әниләрен картлар йортына итеп куйган балалар да очрый.

Әнгам Атнабаевның иҗатын өйрәнгәндә, аның әсәрләре ярдәмендә гаилә кыйммәтләренең барлык нәрсәләрдән дә өстен икәнен исбатларга тырыштык.

Әниләр – безнең мәңге сүнмәс кояшыбыз. Аның шигырьләренә һәм сәхнә әсәрләренә ана образы очраклы гына килеп кермәгән. «Үзем турында ике сүз», «Әниемә», «Әнкәй, синең йомшак кулларың…» дигән шигырьләрен Ә. Атнабаев әнисенә багышлый:

*...бик күп куллар күрдем,*
*Ләкин, әни, синең куллардан да гадел куллар юк!*

Бу юллардан күренүенчә, шагыйрь, олы яшьтә булуына карамастан, әнисенең кулларына, карашына, киңәшенә мохтаҗ, аның өчен башка гадел киңәш юк. Никадәр җылы сүзләр,

ярату, горурлану, ихтирам ул шигырьләрдә.

Шагыйрьнең әнисенә булган сөю һәм рәхмәт хисләре шигырьләренә генә сыеп бетми. Драматургның «Балакайларым», «Юллар өзелгән вакыт», «Ул кайтты» драмаларындагы ана образларының прототибы булып Мәрзия апа – Әнгам Атнабаевның үз әнисе тора.

Шагыйрь әтисен ихтирам белән һәрчак искә ала, сагына, аның юклыгын берни белән дә алмаштыра алмый. Инде үзе дә – әти кеше, малай үстерә һәм аның киләчәге өчен дә кайгыра.

«Солдат көндәлеге» дигән әсәрендә өченче бүлекне ул «Соңгы хат» дип атый. Анда мондый юллар бар.

*Өчпочмаклы гади солдат*
*хаты…*
*Ул саклана инде күптәннән…*
*Инде аның кайбер хәрефләре*
*Танымаслык булып беткәннәр.*
*Хатның соңгы юлы кыска гына:*
*«Кайтып күрешкәнче»*
*диелгән…*

Шагыйрьнең әтисе Касыйм абый Ленинград фронтында һәлак була.

*Шул китүдән әти кайта*
*алмады,*
*Васыятен кирәк үтәргә.*

Бу юллар белән шагыйрь әти-әниләрнең васыятьләрен үтәргә, авыр чакларда туганнарыңа ярдәм итәргә кирәклеге турында әйтә. Ул ятимлек газабын гына түгел, туганнары өчен, тормыш өчен олы җаваплылык тойгысын да татып үсә.

Атнабаевлар гаиләсендә берсеннән-берсе кечкенә җиде бала һәм Мәрзия апа. Сугыш, ачлык еллары. «Без, абыемнан кече алты бала, аны «әти» дип йөрттек. Әти кеше шулай була икән, дип үстек. Ә аңа нибары 14 яшь иде», – дип хәтерли Зинира Атнабаева. Кышкы кичләрдә сәке өстендә концерт, пьеса куюлар аларны тагы да ныграк бәйли, туганлык җепләрен ныгыта.

Әнгам Атнабаев биш туганына да атап язган шигырьләре белән йөрәк җылысын да язып калдырган.

*…болыннарда колын кебек*
*Бер аунап ятсаң иде,*
*Балачакның бер җиләген*
*Бер өзеп капсаң иде,*
*Кирегә кайтсаң иде!*

Шагыйрьнең бу юлларында балачакка кире кайтып, туганнары белән болыннарда аунап-шаярып аласы килүе күренә.

Туганнарына аталган шигырьләрендә аларның туганлык җепләренең нинди нык икәнлеген күрәбез. Ул аларның барысын да ярата, кайгы-шатлыкларын да бүлешә. Алар – тату, бер-берсе өчен өзелеп торган туганнар. Әнгам Атнабаевның тормыш иптәшенә багышланган шигырьләре дә бик күп. Ул – шагыйрь өчен таяныч, олы терәк, аны илһамландыручы да. Без шигырьләрдә Сәүия апаны олы йөрәкле, сабыр, уңган, тугры хатын итеп күрәбез.

Без дә балаларда әнә шул сыйфатларны тәрбияләргә, әти-әниләргә, туганнарга карата игътибарлы, кешелекле, аларны яратырга, тугры, ярдәмчел, рәхмәтле булырга тиешбез.

17




# ТАТАР ТЕЛЕН ӨЙРӘТҮДӘ КОММУНИКАТИВ ТЕХНОЛОГИЯЛӘРНЕ КУЛЛАНУ

*(Мастер-класс)*

**Гүзәл ЗИННӘТУЛЛИНА,**

Югары Ослан районы Печище төп мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы

**Максат**: катнашучыларны УУГ формалаштыручы эш алымнары белән таныштыру.

**Бурычлар:**

– катнашучыларны мастер-классның планы белән таныштыру;

– УУГ формалаштыручы алымнар аша мастер-классның эчтәлеген ачу;

– укытучыларга әлеге алымнарның практик әһәмиятен күрсәтү.

**Җиһазлар:** компьютер, проектор, экран, презентация, карточкалар, рәсемнәр.

**Көтелгән нәтиҗә**: мастер-класста катнашучылар УУГ формалаштыруның төрле алымнарын үз тәҗрибәләрендә дә куллана алалар.

**Мастер-классның барышы**

– Хәерле көн, хөрмәтле коллегалар! Бүгенге минем мастер-класс кызыклы, файдалы булыр дип өметләнеп калам. Барыбызга да уңышлар телим. Хәзер мин сезгә бер гыйбрәтле хикәя сөйлим.

Эзоп философ Ксанфның колы булган. Бервакыт Ксанф кунаклар чакырырга уйлаган да Эзопка табынга иң яхшы нәрсә пешереп китерергә боерган. Эзоп, ит базарына барып, тел сатып алган һәм аннан өч төрле ризык әзерләгән. Ксанф, бу хәлгә гаҗәпләнеп, Эзоптан:

– Ни өчен син һаман тел генә китерәсең? – дигән.

– Син миңа иң яхшы нәрсә алырга куштың, – дигән аңа каршы Эзоп. – Ә дөньяда телдән дә яхшырак нәрсә бар?! Тел ярдәмендә шәһәрләр төзелә, халыкларның мәдәнияте үсә. Тел ярдәмендә без белем алабыз, фәннәр өйрәнәбез. Тел ярдәмендә кешеләр бер-берсе белән аңлашалар, киңәшәләр, шатлык-сөенечләрен уртаклашалар, сөю-мәхәббәт хисләрен белдерәләр. Менә шуңа күрә дә дөньяда телдән дә яхшы бер нәрсә дә юк!

Хөрмәтле коллегалар, сез Эзоп белән килешәсезме? Аның хаклылыгына дәрес барышында тагын бер тапкыр инанырбыз.

Татар телен чит тел буларак өйрәткәндә, коммуникатив принципны беренче урынга куярга кирәк, чөнки тел укытканда төп бурыч – укучыны иркен аралашырга, ул телдә дөрес итеп сөйләшергә, сөйләргә һәм язарга өйрәтү. Рус телле укучыларны татарчага өйрәтүдә уңышка нәкъ менә коммуникатив принципка нигезләнгән методика белән эшләүче укытучылар ирешәләр дә инде.

**Коммуникатив метод** – аралашуга, җанлы сөйләмгә таяна торган методик алымнар комплексы. Бу метод беренче планга укучыларны сөйләшергә өйрәтүне куя, ә теоретик белешмәләр сөйләм процессында, текстны анализлау нәтиҗәсендә чыгарыла. Сөйләмгә өйрәтү фикер эшчәнлеген үстерү белән бергә үрелеп барырга тиеш. Чөнки фикер йөртү сөйләм ихтыяҗын тудыруга ярдәм итә. Коммуникатив методның төп максаты – сөйләмгә мотивация тудыру ярдәмендә өйрәтү. Укытучы укучыларда кызыксыну уятуны нигез итеп алырга тиеш. Күнегүләрнең күптөрле, мавыктыргыч, балалар өчен кызыклы һәм бигрәк тә сөйләмгә ихтыяҗ тудырырга сәләтле булуы шарт итеп куела. Бу метод биш төп принципка нигезләнә: сөйләм-фикер активлыгы, функциональлек, индивидуальләштерү, ситуативлык, яңалык. Дәресләрдә шушы методны төп юнәлеш итеп алу телне өйрәнүдә бик нәтиҗәле.

Бүген методик стандарт итеп кабул ителгән коммуникатив технология укучыларның фикерләү дәрәҗәсен, сөйләм дәрәҗәсен контрольгә алуда иҗади характердагы эшләрне, алымнарны тәкъдим итә. Аларга без төрле темалар буенча изложение, инша, укучыларның үзләренең кечкенә

хикәяләр төзеп язуларын кертә алабыз. Мондый характердагы эшләр укучыларны төп фикерне сайлап ала белергә, логик рәвештә хикәяләргә өйрәтә. Ә иң мөһиме – укучы, үз фикерен җиткерү өчен, татар телендә тел чараларын үзе җыя, анда эчке сөйләм эшчәнлеге бара. Ә бу – аралашу процессына өйрәтүдә бик мөһим алым.

Федераль дәүләт стандартларында дүрт эшчәнлеккә өстенлек бирелә: шәхси, регулятив, танып белү һәм коммуникатив. «Коммуникатив эшчәнлек хезмәттәшлекне оештыруга һәм гамәлгә ашыруга юнәлтелгән. Ул партнёрны тыңлый һәм аңлый белүдән, мәгълүматны тулы һәм төгәл кабул итә һәм тапшыра, үзеңнең эш-хәрәкәтеңне партнёр эш-хәрәкәте белән чагыштыра белүне үз эченә ала», – дип ассызыклана дәүләт стандартларында һәм укучыларның уку эшчәнлеген үстерүдә төп ысулларның берсе булып тора. Димәк, федераль дәүләт стандартларына ярашлы рәвештә, татар теле укытучысының төп максаты – укучыларда коммуникатив компетенция формалаштыру.

Хөрмәтле коллегаларым, мин сезне коммуникатив технологияләрнең бер эш ысулы буларак «Пресс» методы белән таныштырып китәсем килә.

**«Пресс» методы.** Бу күнегү билгеле бер дискуссия соравы буенча әйтемнәрне кысылган формада, сәнгатьле, аргументлар белән кыска итеп әйтә белүне үстерә. «Пресс» методы – әдәбият дәресләрендә иң уңышлы методларның берсе. Ул әсәрне укыганнан соң кулланыла. Бу метод 4 этаптан тора.

1. Үз фикереңне әйт. «Минем фикеремчә...» *(Тезис.)*
2. Фикереңне дәлилләә. «Чөнки...» *(Комментарий.)*
3. Фикереңне расла. «Мәсәлән, ...» *(Аргумент.)*
4. Гомумиләштерү, нәтиҗә. «Шулай итеп, ...» дигән нәтиҗәгә киләбез. *(Нәтиҗә.)*

Бу алым, укучыларның иҗади фикерләү сәләтен үстереп, сөйләмгә этәрә.

Хикәяләрне анализлау өчен һәрвакыт кереш сүзләр дә кулланыла. Без аны 6 нчы сыйныф дәреслегендә булган «Әхмәт» һәм «Уллар» хикәяләре нигезендә карап китик.

**«Ачкыч сүзләр» алымы** *(терәк сүзләр)*.

Бу алым да аралашуга нигезләнгән. Укытучы, тактага тексттан алып, 4–5 ачкыч сүз яза. Укучылар бирелгән ачкыч сүзләр ярдәмендә хикәя төзеп карарга тиешләр. Мәсәлән, «Әхмәт» хикәясендәге ачкыч сүзләр: *кое, чишмә, ерактагы, ялкау, эшчән, хезмәт ярата, эш яратмый.*

В. Осееваның «Уллар» хикәясенә ачкыч сүзләр: *мәтәлчек атыла, җырлый, сандугач кебек, әллә нәрсә эшләми.*

**Ф. Яруллин. «Кояштагы тап» әсәреннән өзек. «Әхмәт» хикәясе.**

Әхмәт әнисе белән генә яши. Аның әнисе бик күп эшли: кер юа, тәмле ашлар пешерә, өй җыештыра, су алып кайта. Әлбәттә, әнисе иртә тора, ерактагы чишмәдән сап-салкын су алып кайта. Чөнки Әхмәт чишмә суын бик ярата. Әхмәт урамда уйный, әнисенә бик аз булыша.

Кызганыч, беркөнне аның әнисе нык авырды, урыныннан тормады.Ул Әхмәтне үз янына чакырды да:

– Улым, чишмәдән су алып кайт әле, салкын чишмә суы эчсәм, терелермен кебек, – диде.

Ул көнне урамда бик эссе иде. Ә чишмә ерак. Әхмәт суны урамдагы коедан гына алып кайтты. Әнисе сизмәс дип уйлады. Әнисе суны

эчте дә:

– Рәхмәт, улым. Ләкин бүген су нигәдер салкын да, тәмле дә түгел, үзем авырыймдыр инде, – диде.

Әхмәт кып-кызыл булды, елап җибәрде.

**В. Осеева. «Уллар» хикәясе.**

Ике хатын коедан су ала иде. Алар янына өченче хатын килде. Бер карт бабай да алар янына утырды.

Менә хатыннарның берсе икенчесенә әйтә:

– Минем улым үзе җитез, үзе көчле.

– Ә минем улым сандугач кебек матур җырлый.

Ә өченче хатын бер сүз дә әйтми.

– Нигә син улың турында берни дә сөйләмисең? – диләр аңа.

– Минем улым искитәрлек берни дә эшләми.

Менә хатыннар кайтып киттеләр. Ә бабай алар артыннан атлады. Кинәт аларның каршысына өч малай йөгереп чыкты. Аларның берсе мәтәлчек ата, икенчесе кычкырып җырлый. Ә өченчесе әнисе янына йөгереп килә дә аның авыр чиләкләрен ала.

– Әйт әле, бабай, безнең улларыбыз ничек? – дип сорыйлар хатыннар.

– Ә кайда соң алар? Мин берегезнең генә улын күрдем, – дип җавап биргән карт.

**Укытучы.** Ә хәзер, коллегаларым, бу ике хикәяне «Пресс» алымы белән анализлап карыйк. Игътибар белән тагын бер кат карап чыгыгыз һәм үз фикерләрегезне әйтегез.

**«Фаразлау» алымы.** Ул – булачак вакыйгага үз фаразларыңны белдерү. Бирелгән әсәрләрнең дәвамын ачыклау максатыннан «Бу хикәяләр ничек үзгәрер иде?» дигән сорау куела. Яки хикәянең бер өлеше укылганнан соң, «Укучылар, вакыйгалар ничек үстерелер?» – дип сорап була. Кайбер хикәяләрдә, «Ачык финал» алымы кулланыла. Монда да укучылар финалны төрлечә фаразларга мөмкин. Бу алым уйлау, күзаллау сәләтен арттырырга, үзеңнең фаразларыңны дәлилләргә өйрәнергә ярдәм итә.

**«Дискуссия» алымы** да бик нәтиҗәле булачак. Укучылар дисскуссия, бәхәснең төп кагыйдәләре белән дә танышалар. Тема сайланыла. Сөйләшү вакытында темадан читкә китмичә, уртак фикергә килергә кирәк.

Укучыларның тәкъдим ителгән вариантлары чыганак текст белән чагыштырыла. Яки үткән материалны кабатлау өчен укылган әсәрләрдән ачкыч сүзләр китерелә (телдән укыла), укучы сүзләр нигезендә әсәр турында сөйли белергә тиеш.

Коммуникатив компетенция формалаштыру юлларын дөрес оештырганда, ул укучыларның тел өйрәнүгә карата мөнәсәбәтләрен уңай якка үзгәртә, белемнәрнең аңлылыгына этәрә, мөстәкыйльлеккә өйрәтә, иҗади фикерләүне үстерә.

– Әйдәгез, хәзер эшебезгә нәтиҗә чыгарыйк. Димәк, коммуникатив технология ярдәмендә без укучыларыбызны сөйләшү этабына чыгара алабыз.

**Йомгаклау**

– Дәрес барышында нинди уку гамәлләре формалашты дип уйлыйсыз**?**

***Регулятив****: УМ кую, чишү, үз эшчәнлегеңә үзбәя;.*

***Танып белү:*** *проблемалы ситуация аша кирәкле ысулны сайлап алу, эчтәлекне модельләштерү.*

***Коммуникатив:*** *төркемдә эшли белү, тыңлый, ишетә, үз фикереңне яклый белү.*

***Шәхси:*** *гомумкешелек кыйммәтләренә уңай мөнәсәбәт формалаштыру.*

– Без үзебезнең алга нинди максат куйган идек, максатыбызга ирештекме?

Миңа сезнең белән эшләү бик ошады. Барыгызда да уңышлар телим.

18



# СӘЛӘТЛЕ БАЛАЛАР БЕЛӘН ЭШ АЛЫМНАРЫ

**Алсу ЖИҺАНГИРОВА,**

Казандагы 184 нче урта мәктәпнең югары квалификация категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы

Сәләтлелек билгеләре дигәндә, без, иң беренче чиратта, кешедәге акыл үсешенең югары дәрәҗәсен күз алдында тотабыз. Психолог-галим И. Дубровина сәләтле балаларны өч төркемгә, өч категориягә бүлеп карый. Аларның беренчесенә зыялылык сәләте кече яшьтән ачылганнар (вундеркиндлар); икенчесенә аерым фәннәрне бик яхшы үзләштерүчеләр; өченчесенә сәләтлелек билгеләре ачык сизелә торганнар керә. Ә менә психология фәннәре докторы Ю. Гильбух фикеренчә, билгеле яшьтәге аңлылык дәрәҗәсе акыл сәләтен билгеләүгә хезмәт итә. Акыл үсешенең югары темпы – сәләтле балага хас сыйфат. Аңлы, белемгә омтылучан балалар тумыштан сәләтле яисә тиешле тәрбия алу нәтиҗәсендә үзләренең иптәшләреннән камилрәк акылга ия булулары белән аерылып торалар. Укытучы өйгә биргән эшләр белән генә чикләнмичә, өстәмә әдәбият һәм өстәмә күнегү-биремнәр үтәүче балаларны аеруча сәләтлеләр рәтенә кертергә була. Ә дәреслектәге уку материаллары исә күләме һәм тирәнлеге буенча уртача дәрәҗәдәгеләргә исәпләнелгән. Әгәр дә бала сәләтле булса, ул тәкъдим ителгән мәгълүматларның саны һәм сыйфаты белән генә канәгатьләнергә теләми һәм андыйлар үзләренә югарырак таләпләр куя торган мәктәпләрдә тырышыбрак укырга омтылалар.

Белгечләр исбатлавынча, сәләтле балаларның нәрсәгә сәләтле булулары билгеле бер шартларда ачыклана. Сәләтле булу нәселдәнлеккә генә бәйле түгел, монда баланың тирә-ягындагы кыйммәтләр системасы да зур әһәмияткә ия. Билгеле бер шартлар булдырганда, укучыларның күбесендә теге яки бу сәләтне үстерергә мөмкин.

Мөгаллимнәргә һәм тәрбиячеләргә балаларның ни дәрәҗәдә сәләтле булуын белү бик мөһим. Алардан сәләтле балаларның күңелен аңлау, аларның үсешенә көч-куәт бирерлек эшләр башкару, шәхси якын килү таләп ителә.

Мөгаллимнәрне гадәти мәктәптә сәләтле балалар белән эшләү, аларга ничек итеп шәхси якын килү, малайлар һәм кызларны индивидуаль программа белән укыту мәсьәләләре кызыксындыра.

Бу юнәлештә эшләгәндә, берничә мәсьәләне хәл итәргә кирәк була. Аларның беренчесе – укучыларның белем үсеше дәрәҗәсен бик тиз һәм төгәл билгеләү һәм шуның белән бәйләнешле рәвештә дәресләрнең тема һәм формаларын планлаштыру вариантларын төгәл фәнни нигезләп сайлап алу, ягъни методиканы төгәл бер төркем, сыйныф яки укучы үзенчәлекләре белән килештерү механизмын булдыру.

Икенчесе – дәрестә дифференциаллы укытуны фәнни нигездә гамәлгә ашыру, үсеш дәрәҗәләре һәм әзерлекләре төрлечә булган укучыларның тиешле белем алуына ирешү, дәресләрдә нинди алым һәм эш формалары кулланырга кирәклеген билгеләү.

Өченчесе – дәрестә укытучы-укучы дуслыгын тагын да нәтиҗәле итү юлларын табу.

Акыл сәләтен эшкә җигү – шулай ук хәл итәсе мәсьәләләрнең берсе. Бу – туктаусыз алга бару мөмкинлеге тудыру дигән сүз.

Сәләтле балалар белән эшләгәндә нинди алымнар кулланыла һәм аларның нәтиҗәлелеге нинди?

Терәк схемалар (конспектлар) – үзара нык бәйләнештәге сораулар яки тема буенча кыскача нәтиҗәләр системасы ул. Алар укучыларга

теманы аңлату алды өлешеннән һәм балаларга укытучы сөйләгәннәрдән җавап эзлиләр яки тема нәтиҗәләрен таба баралар. Әлеге конспектларда көчлерәкләр өчен текстлы биремнәр яки өстәмә сораулар бирелә. Мондый укытуның уңай нәтиҗәсе бар. Сәләтле балалар да, уртача белем алучылар да биремнәрне бик теләп үтиләр, сорауларга җавап табалар. Шулай итеп, аларның белеме тирәнәя.

Текстлы биремнәр, шулай ук тестлар да киң кулланыла. Укучы үзе дөрес дип санаган җавапның берсен сайлап ала. Сәләтле балаларга катлаулырак, эзләнә торган сораулар яки җаваплар тәкъдим итәргә мөмкин.

Балаларның ни дәрәҗәдә сәләтле булулары укучыларның бер-берсенең белемен тикшерү, проектларны яклау, дәрес-конференцияләрдә, семинарларда ачык күренә. Мәсәлән, дәрес-семинарларны алыйк. Һәр баланы актив катнаштыру – дәреснең төп таләбе. Алардан өстәмә әдәбият белән җитди мөстәкыйль эш (яңа чыганакларны уку, материалларны чагыштыру, кызыклы мәгълүматлар сайлап алу) таләп ителә.

Олимпиадалар уздыру – укучыларның иҗади һәм танып белү сәләтен активлаштырырга, талантлы балаларны ачыкларга мөмкинлек бирә, белем туплау белән кызыксынуны арттыра. Олимпиадаларга әзерләнгәндә, төрле эш алымнары кулланыла. Укытучы белән укучы арасындагы әңгәмәләр, фикер алышулар, тест биремнәрен үтәү, яңа чыккан фәнни китаплар, методик кулланмалар белән танышып, өйрәнеп бару зур әһәмияткә ия. Дәресләрдә бу укучыларга, темаларны үткән вакытта, өстәмә чыганаклардан файдаланырга, иҗади эзләнергә кушыла.

Фәнни конференцияләргә әзерләнүнең дә укучылар сәләтен үстерүдә зур әһәмияте бар. Бирелгән тема буенча укучы өстәмә чыганаклардан файдаланып әзерләнә. Үзен кызыксындырган сорауларга җавап эзли. Теманы тулысынча ачып бирү өчен, берничә чыганактан файдалана. Үзенең дәлилләрен берничә галимнең фикерләре белән ачыклый. Монда укучының мөстәкыйль фикер йөртүен, эзләнүен, нәтиҗә ясавын ассызыклап үтәргә кирәк.

Укучыларның иҗади сәләтен үстерүдә иҗади дәресләр, иҗади биремле күнегүләр, биремнәр зур роль уйный. Мәсәлән, сочинение язу, шигырь, хикәя, әкиятләр уйлап чыгару укучыларның иҗади фикерләү дәрәҗәләрен үстерә, сүзлек запасын баета, сөйләм телләрен үстерә. Укучылар бу төр эшләрне бик теләп башкаралар, шәһәр, республика бәйгеләрендә бик теләп катнашалар, призлы урыннар яулыйлар.

Укучыларның җыр, бию, артист-сәхнә остасы булу сәләтләрен дә үстерергә мөмкин. Моның өчен махсус түгәрәкләр оештырырга була: театр, яшь иҗатчылар, нәфис сүз түгәрәкләре һ.б.

Йомгаклап шуны әйтәсе килә: дәресләрдә кулланылган төрле эш алымнары – барысы да укучыларның сәләтләрен үстерүгә юнәлтелгән. Бары тик сәләтле балалар белән эшләгәндә генә, мөгаллим үзе дә күп нәрсәгә өйрәнә, белемен тирәнәйтә, тәҗрибә туплый. Дәресләрдәге мәгълүмат – белемгә, ә белем күнекмәгә әверелә. Укытучы һәм укучыларда үз көченә ышаныч туа, алар үзләрен туплаган тәҗрибәләре белән көчле итеп сизәләр. Әгәр дә без җәмгыятьнең алга таба үсүен теләсәк, һәр укучының, һәр шәхеснең үсешен тәэмин итәргә тиешбез.